



# КӘРИМ ТИНЧУРИН



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Т95

Төзүчеләре
РАБИТ БАТУЛЛА, ВЕНЕРА КАМАЛИЕВА

Рәссамы
РУШАН ШӘМСЕТДИНОВ

**Коллектив**

Т 95 Кәрим Тинчурин: Истәлекләр, шигырьләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. — 159 б., рәсемнәр белән.

Бу китапка халкыбызның мәшһүр драматургы һәм режиссеры Кәрим Тинчурин турында истәлекләр, галимнәрнең, иҗат әһелләренең фикерләре, шигырьләр һәм фоторәсемнәр тупланды.

ISBN 5-298-01284-1


© Татарстан китап нәшрияты, 2003

*Кәрим Тинчурин күпкырлы талант иясе булуы белән замандашларыннан аерылып тора. Ул – актер, режиссер, драматург буларак татар театрын ныгыткан сәнгатькәр, әмма шулар өстенә Кәрим Тинчурин проза остасы да, ул «Мәрҗәннәр» романы белән әдәбиятыбызның олы классигы булып тарихта калган зат...*

**Минтимер Шәймиев**



# РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН



**Әйләнә сәхнә, әйләнә...**

Баш исәк тә даһи җанның
сәнгатьтәге көченә,
Тик ул да каршы торалмый
сәхнә әйләнешенә.

...Күренешләрне алыштырып,
әйләнеп кереп китә.
Гомерләрне, бәгырьләрне
кискәләп, телеп китә.

Менә шушы әйләнештә
кемнеңдер соңгы роле.
Соңгы алкышлануы,
иң соңгы алган гөле.

Кемдер Зөһрә, кемдер Таһир,
кем әле Хәлил бүген.
Ялга чыккан карт артистның
үз хәле хәлдер бүген...

*Татар театры артистлары. Уртада – Кәрим Тинчурин. 30 нчы еллар*



Әйләнә сәхнә, әйләнә,
сибелеп кала еллар.
Сибелеп кала язмышлар,
режиссерлар, геройлар...

Сибелә... Әйләнә сәхнә.
Булмый шул каршы торып.
Изге җиргә була икән
табынып тик, баш орып.

Тоела кайчак, сәхнә ул
агачтан түгелдер күк.
Күз яше белән юылган
көзгедер, күңелдер күк.

Анда иңләп йөрүчеләр
илаһи затлар кебек.
Алар гаҗәеп якын да,
һәм бераз ят та кебек.

...Әйләнә сәхнә, әйләнә,
шуышып кереп китә.
Гомерләрне, бәгырьләрне
кискәләп, телеп китә.

*1973*



*«Кандыр буе» спектакленнән күренеш. Кәрим Тинчурин төшергән рәсем. 1932*





# УЙНАКЛАШЫП КҮТӘРЕЛӘ ҖЫРЛАР
# БЕЗ ЯШӘГӘН ЯКТЫ БУ ЧОРДАН...



## РИЗА ИШМОРАТ

### Соңгы очрашулар



Шундый олы талант иясе, оста драматург, күренекле артист, барыннан да бигрәк тирән акыллы педагог, режиссер да булган К.Тинчурин белән озак еллар буе бергә эшләп үткән гомерләрне иң бәхетле көннәремнән саныйм. Алар күп, бик күп.

Г.Камал театрында мин баш режиссерлык вазифасын алып барган утызынчы елларда оригиналь пьесалар күп кенә очракта драматургларга махсус заказ биреп яздырыла иде. Тинчуринның «Кандыр буе» әсәре дә, Кави Нәҗми белән бергә язылган «Булат бабай семьясы» да, Ф.Сәйфи-Казанлы белән язган «Корыч орчык» пьесасы да шулай барлыкка килде. Ф.Бурнаш, Т.Гыйззәт һ.б. кайбер авторларның да пьесалары махсус заказ белән туды, һәм, ниһаять, К.Тинчуринның соңгы әсәре дә махсус заказ белән язылды. Дөресен әйткәндә, бу җитәкче оешмаларның теләге һәм киңәше буенча да иде. Әсәрнең төп темасы илебездә социализмның җиңә баруы, халкыбызның патриотик рухын җимерү турында хыялланган мәкерле дошманны фаш итүгә


*Каләм ияләре киңәшә. Уңнан сулга: Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми, ..., ..., Гомәр Гали, Шәриф Камал. 1932*



корылган спектакль күрсәтеп, һөҗүм була калса, халкыбызны дошманга каршы җавап бирү өчен әзер булырга чакыру иде. Кәрим абый бу пьесаны вәгъдә иткән вакытында тәмамлады, һәм без аны, Партия өлкә комитетындагы иптәшләрнең теләге буенча, театрда түгел, өлкә комитетының культура-пропаганда бүлеге мөдире Гариф иптәш Яушев кабинетында укыдык. Укучылар арасында Яушев, аның ярдәмчесе, инструктор Камай Кәримов, Татарстан язучылар союзы вәкиле Кави Нәҗми, Мәскәүдә Театр институты тәмамлап яңа гына режиссер булып килгән Ширияздан Сарымсаков һәм мин булдым. Ул чагында «Юкә чәчәк атканда» дип матур исем белән аталган һәм тирән мәгънәле сүзләр белән язылган бу пьеса безгә бик ошады. Аны кычкырып укучы автор Кәрим абый үзе булганга, ул, билгеле, безгә, тыңлаучыларга, әсәрнең бөтен характерын, эчке мәгънәсен дөрес һәм тулы аңлатырлык итеп укыганга, без әсәрне дулкынланып кабул иттек.

Ара-тирә артык зур булмаган җитешсезлекләрне төзәткәннән соң, әсәрне театр репертуарына кертеп, сәхнәгә куярга мөмкинлеге һәм бүгенге бик кирәкле мәсьәлә күтәрелүе турында уңай фикер әйтелде.

Пьесадагы персонажга чит илдә яшәгән бер татар эмигрантыннан почта аша шунда чыгарылган журнал килеп төшә. Бу эпизодка карата арабыздан берәү: «Шундый хәл булырга мөмкинме?» – дип сорау бирде. К.Тинчурин моның булган хәл икәнлеген үз мисалында аңлатып: «Заманында мин үзем чит илдән пакет алган идем. Бу Гаяз Исхакый җибәргән «Милли юл» журналы иде, мин аны «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә илтеп бирдем», – диде. Бу сүзләрне ишетеп, без беркадәр аптырабрак калдык. Бу бит шәхес культы афәтләре иң нык канат җәйгән, Г.Исхакый кебек эмигрантларны телгә алырга да ярамаган чор – 1937 ел иде.



*Казан. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең бинасы*



*Гаяз Исхакый*

Тынлык...

Белмим, күпме вакыт сузылгандыр бу тынлык, өлкә комитетыннан Яушев, тынлыкны бозып: «Шулай, иптәшләр, – диде, коры гына, – пьеса укылды, бәя бирелде, алдагы язмышын автор белән менә режиссерлар, – ул миңа һәм Сарымсаковка күз төшереп алды, – театрда хәл итәрләр. Ә бүген шуның белән әңгәмәне тәмамлыйбыз», – дип китәргә әзерләнде. Арабызга салкын су сибелгәндәй булып, өйләребезгә таралдык.

Пьеса укылып, күпмедер вакыт үткәч, контрреволюцион милләтче, халык дошманы дип аталып, 1937 елның сентябрендә, нәкъ илле яше тулган көннәрдә, Кәрим Тинчурин кулга алынды.

Озак та үтмәде, татар театр сәнгате өлкәсендә контрреволюцион тинчуринщинаны гамәлгә ашыручы халык дошманы саналып, Партия өлкә комитетыннан килгән Камай Кәримовның актив катнашуы белән, мине дә партия сафыннан, шулай ук театрдан да чыгардылар.

Моннан бер атна элек кенә Татар дәүләт академия театрында контрреволюцион тинчуринщинаны «фаш иткәндә» актив катнашкан Кави Нәҗминең мине партиядән чыгарганда булмавына гаҗәпләнгән идем, ул да инде бу көннәрдә кулга алынган булып чыкты. Сүз уңаеннан шуны да әйтим, өлкә комитеты вәкиле Камай Кәримов та соңрак «халык дошманы» саналып, төрмәгә ябылды. Бу хәвефле хәлләрдән Гариф Яушев иптәш тә котыла алмады.

Болар Гаяз Исхакый журналы китергән фаҗига түгел, ә миллионнарча гөнаһсыз кешеләребезне – татарны да, русларны да, азәрбайҗан белән әрмәнне дә, үзбәк белән грузинны да, шул исәптән үзенең якын дусларын да һич аяусыз һәлак иткән кансыз Сталин эше иде.

Күп бәла-казалар кичерә-кичерә, Партиянең район, шәһәр һәм өлкә комитетларының ишекләрен кага-кага, газаплы хәлләрдән соң, 1938 елны мин партия сафына, шулай ук Татар дәүләт академия театрына режиссер һәм әдәби бүлек мөдире итеп кире кайтарылдым. Ә менә татар театрының гына түгел, милли мәдәниятебезнең җаны-рухы булган Кәрим абый Тинчуринның язмышы фаҗигале булды. Аның кайчан, ничек кулга алынуы һәм язмышы турында иң төгәл, дөрес хәбәрне без соңгы елда гына ишеттек. Ул 1938 елның 15 ноябрендә Пләтән төрмәсеннән ерак түгел генә җирдә судсыз-нисез атып үтерелгән.

– Аның соңгы әсәре «Юкә чәчәк атканда» белән эш ничек булды соң? – дип сорарсыз.

Кәрим абыйның хатыны Заһидә ханымның әйтүенә караганда, Тинчуринны кулга алган чагында ук, аны һәм башка кулъязмаларын да зур гына чемоданнарына тутырып алып киткәннәр...

*«Социалистик Татарстан». 1 июль, 1990*

## ШӘРИФ БАЙЧУРА

### Әдип турында кайбер хатирәләр

Кәрим Тинчурин – 1905–1907 еллардагы революция чорында Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һәм башка алдынгы эшлекләләр белән берлектә, Казандагы шәкертләр хәрәкәтендә актив катнашучыларның берсе. Ул 1906 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ташлап чыккан 82 шәкерт арасында да була. Педагог Мирза Гозәиров бу вакытны искә төшереп болай сөйләгән иде: «Мәдрәсәне ташлап чыгучылардан бер төркем шәкертләр Арча кырында бер агач йортка урнаштырылды. Мәдрәсәдә минем урындашым булган Кәрим Тинчурин да шунда иде. Без урнашкан йортның капка төбендә һәрвакыт бер полицейский тора иде». Монда тору шартлары ничек булуын сөйләгәннән соң, ул тагын Кәрим турында тукталып, аның мәдрәсәдә чакта ук театр кую белән



*Театр «йолдызлары» – Кәрим Тинчурин һәм Габдулла Кариев. 1913*

*«Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән куылган шәкертләр. Икенче рәттә сулдан дүртенче – Кәрим Тинчурин. 1906*





*Шәриф Камал*



*Галиәсгар Камал*

мавыгып йөргүен, мәдрәсә подвалындагы ашханәдә простынялар белән бүлеп, сәхнә ясап, берничә һәвәскәргә җитәкчелек итеп, спектакльләр оештыруын хикәя итә.

Минем хәтеремдә: 1907 елда, инде реакция башлануга да карамастан, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә «әдәбият кичәсе» исемендәге легаль булмаган җыелышлар әле дәвам итә, анда илнең политик хәленә бәйләнешле чыгышлар да була иде. Илдәге хәл төрле кинаяле сүзләр белән очерк, хикәя яки шигырь формаларында әйтеп бирелә. Шундый чыгыш ясаучылар арасында Кәрим Тинчуринның да булганлыгын хәтерлим.

1911 ел. Җәй айлары. Бу вакытта мин элекке Әрмәнски (хәзерге Спартак) урамында бер рус гимназисты белән берлектә хосусый квартирада бүлмә алып яши идем. Үзем бер типографиядә корректор булып эшлим һәм шул ук вакытта русча учительлеккә әзерләнәм.

Беркөнне кичкә табарак өйгә кайтып барганда, танышым Якуб Байбурин белән очраштык һәм бер юнәлештә китеп бардык. Сөйләшеп бара торгач, хәзерге Такташ урамына килеп җиттек. Шунда ул миңа: «Әйдә, безгә кереп утырыйк», – диде һәм без Такташ урамындагы хәзер 10 нчы номерлы ике катлы агач йортның өске катына барып кердек. Өч бүлмә һәм кухнядан торган бу квартирада Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Якуб Байбурин һәм Фатихны күтәреп йөртүче бер егет тора икән. Якуб мине «русча укучы егет» дип таныштырды. Гәрчә мин моңа кадәр дә Фатих һәм Кәрим белән очрашкалаган булсам да, болай өй шартларында турыдан-туры утырырга туры килмәгән иде әле. Аларның буш вакытлары булды, ахры, төрле темаларга шактый озак вакытлар сөйләшеп утырдык. Шуннан соң мин якын күрше булган бу өйгә еш кына кергәли торган булдым. Алар янына Г.Тукай, Х.Ямашев, Г.Камал, Г.Коләхметов, Г.Кариев һәм башкалар килеп йөри иде. Кәримнең дә язучы һәм драматурглык нигезләре әнә шул шартларда, шул даирәдә салына. Озакламый «Кояш» газетасы һәм «Аң» журналы чыга башлый. Кәримнең «Ак чибрик» дигән хикәясе басыла. Минем белүемчә, бу аның беренче әдәби хезмәте иде. Шул ук чорда Кәрим «Сәйяр» труппа-



*Хөсәен Ямашев*



قوياش

ЕЖЕДНЕВНАЯ ГАЗЕТА

„КОЯШЪ"

ТЕЛЕФОНЪ

*«Кояш» газетасы*

сында да артист буларак актив катнаша, ул анда Үзбәк-Тинчурин дигән исем белән йөри. Октябрь революциясен «Сәйяр» труппасы Максим Горькийның «Мещаннар» пьесасын кую белән каршылый, Кәрим бу әсәрдә төп рольләрнең берсен башкара.

1918 елның көзендә, Казан чехлардан азат ителгәч, Галиәсгар Камал, Ибраһим Кули һ.б.лар белән берлектә Кәрим Тинчурин да «Эш» газетасында эшли башлады. Бу чорда квалификацияле журналист кадрларга ихтыяҗ зур иде. Татар журналистларының бер төркеме чехлар белән киткән, калганнарының да күбесе совет-партия матбугатында эшләүдән тартынып тора. Кәрим белән бер очрашкан вакытыбызда аның совет газетасында эшләүдән бик канәгать булуын, кайвакытларда үзенә газетага баш мәкалә дә язарга туры килүен аерым бер горурлык белән сөйләве исемдә калган.

1919 елның язына таба, Колчак бандалары Идел буйларына якынлашкан вакытта, Кызыл гаскәрләргә спектакльләр кую өчен артистлар труппасы төзелде. Труппаның режиссеры итеп Кәрим Тинчурин билгеләнде.

1922 елның җәй башларында мин Кәрим Тинчуринны Ташкентта очраттым. Ул монда Идел буе хәрби округы политик идарәсе янындагы театр студиясен тәмамлаган кадрлардан төзелгән татар театр труппасына җитәкчелек иткән хәлдә, шул политик идарәнең командировкасы белән килеп, беркадәр вакытлар Оренбург шәһәрендә эшләгәннән соң, ул чакта Төркстан республикасы мәгариф комиссары булып эшләгән Шәһит Әхмәдиев иптәшнең чакыруы буенча 1921 елда килгән икән.

Бу вакытта мин Төркстан Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты тарафыннан үзбәк телендә чыгарыла торган әдәби, иҗтимагый һәм политик «Инкыйлаб» журналында секретарь булып эшлим, ә журналның редакторы Партия Үзәк Комитетының беренче секретаре Нәзер Тюракулов иде. Шул вакытларда Тюракулов өендә булган бер чәй мәҗлесе минем исемдә бик ачык сакланып калган. Бу мәҗлестә Төркстан Үзәк Башкарма комитеты секретаре Мөстәкыйм Юмакаев, Свердлов исемендәге университетның Урта Азия филиалында укытучы Искәндәр



*Казан. Дәүләт үзәк көнчыгыш китапханә-музее. Хәзерге Г.Тукай урамы. 20 нче еллар*

Мөстәкыймов, соңыннан Ташкент университеты профессоры булган күренекле этнограф Булат Салиев, мәгариф комиссариатының гыйльми советы председателе Госманхан Ишанхуҗаев һәм Кәрим Тинчурин булды. Бик җанлы һәм бик күңелле үткән бу мәҗлестә сүз башлыча сәнгать һәм театр эшләре турында барды. Тюракулов соңыннан миңа җибәргән бер хатында: «Тинчуриннарга сәлам. Таудан зур, хурдан чырайлы бер театр сәнгате ясавына һәр заман дога итәр идем. Авызны тулдырып-тулдырып театрдан сөйләгәнен янә ишетәсем киләдер. Гаҗәпнык вә таза егет», – дип яза.

1925 елда иптәш Тюракулов Казанга килгәч, мин аны Кәримнең үтенүе буенча аларның өенә алып бардым. Кәримнең якын туганнарыннан гына торган бу мәҗлестә сүз тагын да театр, сәнгать һәм әдәбият мәсьәләләре турында барды. Анда Кәримнең татар совет театры үсешеннән канәгать булуын, киләчәккә тагын да зур өметләр баглавын бик бирелеп сөйләве әле дә бик ачык хәтеремдә.

*«Социалистик Татарстан». 14 сентябрь, 1967*



ФАТЫЙМА ИЛЬСКАЯ

## Сокландыргыч Кәрим ага

Кәрим Тинчурин исеме телгә алынуга, аны һәркем драматург, режиссер, артист итеп күз алдына китерә. Кәрим ага моннан тыш гаҗәп сөйкемле, саф күңелле, холкы һәм эчке табигате, тышкы кыяфәте, үзен-үзе тотышы белән чын интеллигент иде. Ул – талантлы артистлар коллективын тәрбияләгән кеше. Безнең күңелләрдә ул шулай яши.

Менә ул театрга килеп керә. Без барыбыз да, ирексездән, аның тирәсенә җыелабыз. Күңел үзеннән-үзе аңа тартыла, чөнки аның нинди дә булса яңалык алып килгәнен белеп торасың.

– Менә яңа пьеса алып килгән идем әле, – ди ул. – Акка күчереп чыкканчы, бергәләп укып чыксак, ничек булыр икән?


Без, «Сәйяр» труппасының барча кешеләре, аның тирәсенә түгәрәкләнеп утырабыз һәм аның укыганын йотлыгып тыңлыйбыз. Без үз фикерләребезне әйтәбез. Тинчурин һәр сүзне бик җитди кабул итә. «Мин моны уйлармын әле, бу җөмләне чыннан да карарга кирәк икән», – дип, кульязмасының читенә билге куя иде.

Зәйни Солтанов



Ул пьесаларында кайбер рольләрне аерым артистларга атап яза иде. Әйтик, «Җилкәнсезләр» пьесасындагы Оркыя – Нәфыйга Арапованы, Дилбәр роле мине күздә тотып язылса, «Зәңгәр шәл»дәге Ишан ролен Зәйни Солтанов өчен язган иде.

Шуннан соң репетицияләр башлана. Режиссер Габдулла Кариев һәм Кәрим Тинчурин белән бергә иҗат итү үзе бер бәхет иде. Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Кайчак репетициягә киләсең, рольгә кереп булмый. Берни эшлисе килми. Һичнәрсәгә күңел бармый. Шулчак Тинчурин күренә, дөнья кинәт яктырып киткәндәй була. Ничә еллар бергә эшләп, мин Тинчуринның чытык йөзле чагын, ачулы карашын күрмәдем. Ул һәрвакыт якты чырайлы



*«Ревизор» (Н.Гоголь) спектакленнән күренеш: Хлестаков – Кәрим Тинчурин*

була иде. Сиздерми генә сиңа рольнең асылын, образның характерын ачып бирә иде.

Кәрим Тинчурин сәхнәдә еш кына үзе дә уйный иде. «Җилкәнсезләр»дә Батырханны уйнады. Хәер, уйнады дип әйтү төгәл үк булмас, ул сәхнәдә яши иде. Образга шулчаклы бирелеп керә, аның чын Батырхан икәненә бернинди шигең калмый. Син дә аңа ияреп онытылып китәсең – Дилбәр булып кына каласың. Аның белән иҗат итүе үзе бер бәхет, бу иҗади рухлану бирә иде.

Аның «Ревизор»да иҗат иткән Хлестаковы бигрәк тә истә калган. Ул – ялганчы; үз ялганына, үз уйдырмасына үзе ышанган, кешене ышандырып уйный, шулкадәр бирелеп, ихластан, ышандырып сөйли. Тамашачы буларак, Хлестаковка ышанып утырасың. Аның ягымлы, дәртле Хлестаковы шундук сине биләп ала.

Ул сүзгә бай, аның башында – бетмәс-төкәнмәс хикәяләр. Ул нindидер вакыйгаларны искә ала, кешеләрне сурәтли, нindидер фикерләрне гомумиләштерә. Болар барысы да артистка иҗади азык, иҗади хыялга юнәлеш бирә. Шуңа күрә аның театрга килүен һәркем зарыгып көтә иде.

Тинчурин – үзенең күңел байлыгын юмарт өләшүчән кеше иде. Аның бөтен хәрәкәтендә, йөрешендә, кешегә мөрәҗәгать итүендә, артистларга күрсәтмәләр бирүендә кешегә зур хөрмәт сизелә. Ул һәрвакыт якты йөзле. Уен-көлке ярата. Менә ул репетициядән соң күзлеген эзләргә тотына. Күзлеге исә маңгаена күтәрелгән була. Ул моны белә, ләкин шаярта: «Күзлегем кая соң?..» Менә

җыелыш бара. Берәү урынсыз һәм күңелсез сөйли башласа, Кәрим ага бик әдәпле генә, сөйләүчегә сиздермичә генә кәгазьдән күгәрченнәр ясап, шуларны очырта башлый.

Ул үзе күргән, тормышында очраткан кешеләрдән, ишеткән, күргән вакыйгалардан сюжетлар кора, образлар тудыра. «Җилкәнсезләр» комедиясендә Кәрим Тинчурин иске дөнья вәкилләренең һәлакәтен ачы көлү белән тасвирлый һәм гади, гадел кешеләргә үзенең зур мәхәббәтен белдерә. Безгә, артистларга, «Җилкәнсезләр»дәге күп кенә образларның прототиплары таныш иде. Без аларның күбесен күреп белә идек. Дилбәр образында, мәсәлән, гимназиядә укыган безгә таныш бер туташның язмышын чагылдыра.

Кәрим ага шат күңелле, эшкә бирелгән кеше иде. Ул шул яклары белән артистларда хезмәт дәрте, иҗат уты кабындыра иде. Хатын-кызларга аеруча игътибарлы иде. Артистларның хезмәтенә ул югары бәя бирде. Һәр кешенең хезмәтен, урынын ихтирам белән билгели белде.

Зур педагог Антон Макаренко үзенең шәкертләренә, иң авыр профессия – чын кеше булу, дигән фикерне әйткән. Кәрим ага турында сүз кузгатканда, шушы фикер искә төшә. Кәрим ага чын кеше, олы йөрәкле кеше иде. Бу аның драматургиясендә, нәтиҗәле режиссерлык, актерлык эшендә чагылыш тапты. Без, өлкән буын артистлар, аны онытылмас, сокландыргыч Кәрим ага, дибез.

*«Социалистик Татарстан». 19 декабрь, 1976*

*Кәрим Тинчурин (икенче рәттә сулдан икенче) чордашлары – сәнгать әһелләре арасында*





# ГАЛИЯ КАЙБИЦКАЯ

**Кәрим Тинчуринга карата истәлекләрем**

Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Таҗи Гыйззәт, Мирхәйдәр Фәйзи, Фәтхи Бурнаш һәм башка, һәм башка шундый кыйммәтле сәнгать эшлеклеләрен искә алдым исә, минуты белән узган гомерем матур булып күз алдыма килеп баса. Инде шул рәсемгә дикъкать белән бераз тукталсаң, бөтен гәүдәң тетрәп, йөрәгең белән шатланып, сөенеп куясың. Бу бер дә гаҗәп түгел. Шундый бөек кешеләребезнең исемнәрен искә алып, күз алдында җанландыра аласың икән, йөрәгеңнең сөенүе үзе бер зур бәхет булырга тиеш, дип аңлыйм.

Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшевләр белән фикерләребез бер булып, бер театр эчендә күп еллар бергә иҗат итәргә туры килде миңа. Шул бергә иҗат итү дәверен мәңге оныта алмас дәрәҗәдә сагынып һәм зур горурлык белән искә алам.

Без, ягъни 1923 елдан 1934 елгы сезондагы артистлар, сөекле драматургыбыз Кәрим Тинчуринның яңа язган әсәрләрен икешәр, өчәр йөз мәртәбә уйнау бәхетенә ирешкән артистлары булдык. «Зәңгәр шәл» пьесасының үзе генә дә бер сезонда йөздән артык уйналган вакытлары булды. Тирән хисле, сүзгә үткер, үзенең алтын каләме аша тормышның ачысын-төчесен таный алган тугрылыклы, киң күңелле драматургыбыз Кәрим ага Тинчурин безнең остазыбыз да, юлдашыбыз да, артист һәм режиссерыбыз да иде.

Кәрим Тинчуринның режиссер буларак бервакытта да, репетиция булсын, башка вакыт булсын, үз



*Иҗатташ дуслар – Салих Сәйдәшев һәм Кәрим Тинчурин*

артистларына тавыш күтәреп сөйләшә торган гадәте булмады. Әгәр репетиция вакытларында аның теләге буенча бер эш килешмирәк торса, ул якыныбызга килеп басар иде дә: «Мөмкин булса, шул җирен кабатлыйк әле», — дип, җай белән генә әйтер иде. Аннан һәркайсыбыз аның әйткәненчә кабатларга тырыша идек. Ул шунда чиктән тыш кәефе килеп: «Мине тиз аңлавыгыз өчен рәхмәт сезгә!» — дип, кулыбызны кысар иде. Бик тә соклана идек без Кәрим ага Тинчуринның ягымлы кеше булуына.

1923 ел. Уральскидан Казан театр техникумына укырга килүгә, Кәрим Тинчурин белән танышу бәхетенә ирештем. Ул техникумның сәнгать бүлегендә укыта иде. Аның дәресләренә чиксез яратып йөри идек. Һәркайсыбыз үзебезгә бирелгән рольләрне өйрәнеп, дәрес вакытларында остазыбыз каршына килеп образ иҗат итә идек.


*Фәтхи Бурнаш*

1924 елны техникумның берьеллык уку отчетына Кәрим Тинчурин белән хәзерләндек. Ул миңа Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» әсәреннән Галиябану ролен башкарырга кушты. Хәлил роле Хәким Сәлимҗановка бирелде. Безнең рольләр җыр белән барасы булгач, Кәрим Тинчурин безне композитор Салих Сәйдәшевкә беркетте, берьеллык отчет кичәбезне зур уңыш белән уздырды.

Ул кичәдә уңыш бәйрәме белән тәбрикләп сәхнә артына керүчеләр арасында К.Тинчурин белән С.Сәйдәшевләр үзләре дә безне «беренче карлыгачлар» дип мактап чыктылар. Кәрим ага Тинчурин минем киләчәктә артистка булуыма, җырчы булачагыма нык ышанды һәм шул өмет белән минем беренче адымнарыма илһам көче биреп, тиз арада Казан сәхнәсендә аякка бастырып җибәрүгә беренче сәбәпчем булды.

1924 елны театр техникумының отчет күргәзмәләре узганнан соң, Кәрим Тинчурин мине үз янына чакыртып, мине театр составына артистка итеп алу турында сүз кузгатты. Мин бу хәбәрне үз остазымнан кинәт кенә ишеткәч, ничектер сискәнеп, яшьлегемнән куркыпмы, андый зур эшкә чакыруларына аптырап калдым. Кәрим ага, минем аптырап калуымны сизеп, сүзне болай дип дәвам итте: «Билгеле, Сез яшь әле, театр эше авыр, әлбәттә. Аңа җиңел карап булмый. Сезнең тавышыгыз бар, театрның репертуарында музыкальный әсәрләр елдан-ел артачак, дип уйлыйм. Шуны искә алып, сезнең театрда эшләвегез кирәк булыр. Әмма җырчы булыр өчен уку кирәк. Уку белән эшне алып баруга Сезгә дә җиңел булмаслыкны аңлап, уку юлыгызга зыян китермәскә тырышырбыз. Укуны Сез дәвам итәрсез, ярдәм итү ягын мин үз өстемә алам», — диде.

Менә шул гариза биргән көннән опера театры ачылган дәвергәчә мин Татар академия театрында Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшевләр ярдәме белән укуны һәм эшне дә берьюлы алып бардым. Өч ел театр техникумында укып, янә музыка училищесына күчеп, анда дүрт ел укып чыктым.

Театрга беренче аяк басу көненнән Кәрим Тинчурин миңа: «Мин Сезгә бер роль бирәм. Сез шуны Ленинград шәһәреннән атаклы җырчыбыз Ситдыйк Айдаров килүгә өйрәнеп куйсагыз, яхшы булыр иде. Сез Ситдыйк Айдаров белән җырлый башларсыз», — диде.



*К.Тинчуринның Г.Камал театрында үткәрелгән 100 еллык юбилееннан соң. Алда – Заһидә Тинчурина һәм Рабит Батулла, артта – Галия Кайбицкая, Туфан Миңнуллин. 1987*



*Мирхәйдәр Фәйзи*



*Таҗи Гыйззәт*

Роль шактый җаваплы, Кәрим Тинчуринның үз әсәре – «Сүнгән йолдызлар»дан Сәрвәр роле иде. Бу кадәр калын дәфтәр зурлыгындагы рольне ничек өйрәнеп бетерергә икән дигән уй минем күңелгә шик төшерде. Җитмәсә, тагы мәшһүр җырчы килергә тиеш, рольне өйрәнүгә вакыт та аз куелды.

Шуңа борчылып, киңәшкә дип, Салих Сәйдәшев янына йөгердем. Ул миңа: «Курыкма, Галия! Үзем сиңа булышырмын, җырларны үзеңә якын булган көйләрдән сайларбыз, янә минем яңа язган көйләрне алырбыз, борчылма, үзем өйрәтермен», – дип киңәш биргәч, күңелем бераз җиңел сулап куйды. Янә икенче юанычым – «Сүнгән йолдызлар» пьесасы спектакль булып театр сәхнәбездә куела башланган иде инде. Мин үзем уйныйсы булгач, ул спектакльне куелган саен зур игътибар белән карап йөрүем үземә дә зур дәрес булды, Сәрвәр образын үземчә аңларга зур ярдәм итте. Көне-төне йокы күрмәстән, зур тырышлык аркасында, Салих Сәйдәшев янында Сәрвәр җырлыйсы көйләрне өйрәнеп, мизансценаларын Кәрим Тинчурин белән үтәп, Ленинградтан киләсе Ситдыйк Айдаров кайтуга тулысынча хәзерләнеп өлгердек.

Ситдыйк Айдаров килү белән берничә репетиция ясап, спектакльдә мин – Сәрвәр, Ситдыйк Айдаров – Исмәгыйль, Мәхдүм образында Кәрим ага Тинчурин үзе уйнап, халкыбыз каршында зур уңышларга ирештек.

Беренче чыгышымда Кәрим Тинчурин сәхнә артына, минем янга кереп уеныма һәм тавышыма зур бәя биреп, үземне тәбрик итте. Һәм шул рольне башкарганнан соң, ул үзенең һәрбер язган яңа әсәрендә миңа баш рольләрне биреп бара торган булды.

Кәрим ага кул астында аның күп әсәрләрендә уйнадым: «Ак калфак», «Асылъяр» яшьли уйнаган рольләрем булса, аннан соң «Яшь йөрәкләр», «Ил», «Зәңгәр шәл», соңрак «Наемщик», «Кандыр буе», «Казан сөлгесе» уйналды. Һәммәсендә дә миңа баш роль иде, һәммәсе дә күркәм иде.



*Музыка училищесы*

Бу кадәр күп рольләрне уку белән бергә бәйләп бару, һичшиксез, остазларым аркасында җиңеләйтеп, сәхнә осталары янында үрнәк алып, өзлексез уйнап, эшнең һәм укуның авырлыкларын сизми үткәрдем.

Кәрим ага Тинчуринның миңа башка җәһәттән дә ярдәме күп булды. Аның кешелекле булуы иҗади эштә генә кайгырту түгел, тормышта килеп чыккан барлык читенлекләргә дә күз салып, ярдәм кулын сузарга әзер иде. Минем шәхси тормышымда читенлекләр тугач, мин икенче шәһәр театрына китеп эшләргә булган идем. Шуны Кәрим ага Тинчурин Сәлих Сәйдәшев аша белеп, китү юлымнан туктатты. Минем хәлләрне сорашып алганнан соң, ул: «Юк, юк, китмисең, син Казан театрында эшләргә тиеш», – дип, мине җибәрмәстән, Әстерхан театры белән сөйләшелгән килешүне бозып, юлга дип алынган акчаларын кире

җибәреп, мине Казанда тотып калды. Шуның белән бергә үзе торган йорттан С.Сәйдәшевнең фатирын бушаттырып, Сәйдәш үзе Тукай урамына күчеп, мине Салихның өч бүлмәле фатирына балам белән икебезне урнаштырып куйды.

Миңа опера театрында шулай ук күп еллар эшләргә туры килде. Татар композиторларының һәрбер яңа әсәрләрендә һәм урыс-европа классик әсәрләрендә – «Травиата», «Риголетто», «Севильский цирюльник», «Снегурочка» кебек операларда баш рольләрне башкардым. Шундый катлаулы һәм җитди хезмәт башкарганда, бөек остазларым Кәрим ага Тинчурин, Салих Сәйдәшевләрнең йогынтысы миңа гаять нык ярдәм итте.

*1978*



*Хәким Сәлимҗанов*

*Заһидә ханым Тинчуринаны 90 яшь тулу көне белән котларга килгән шәхесләр. Беренче рәттә (сулдан уңга): Риза Ишморат, Заһидә ханым, Рабит Батулла; икенче рәттә: Рәйсә ханым Ишморатова, Кәрим Тинчуринның якын дусты Заһит Нуркин кызы Үлмәс ханым, Заһидә ханымның укучысы Мәрзия ханым, Рузия ханым. 1987*





# РӘШИДӘ ҖИҺАНШИНА

**Тинчуринның соңгы омтылышлары**

Ул елларда «Беренче чәчәкләр», «Алар өчәү иде» әсәрләрен сәхнәгә режиссер Р.Ишморатов куйды. Кәрим ага Тинчурин репетицияләрдә була, үзенең төзәтмәләрен ясый иде. Аның җиңел адымнар белән сәхнәгә сикереп менүләре, режиссер һәм актерлар белән булган әңгәмәләре әле дә булса күз алдымда тора. Без, дәресләрдән качып, иң өстәге балконда посып кына бу күренешләрне йотылып карап утыра идек. Бу көннәр, бу минутлар К.Тинчуринның соңгы омтылышлары булган икән, без моны соңыннан гына аңладык.

...1937 елның 8 мартын театрда искиткеч зур итеп уздырдылар: сарыклар суелды, аш-суны өйдәгечә тәмле итеп хатын-кызлар үзләре пешерде, театрның кече фойесына зур-зур өстәлләр куелды, сый-хөрмәт бик шәп иде. Ул бәйрәм өстәле көндез әзерләнде һәм шунда барчабыз гөр килеп җырлап-биеп күңел ачтык. Бу чын мәгънәсендә бер зур гаилә бәйрәме булды. Безгә, яшьләргә, чиксез күңелле булды, без өлкән артистларны якыннанрак белдек шикелле.

Менә шул ваемсыз матур тормышны ниндидер болыт каплый башлады, нәрсә булды соң ул елларда? Нәрсә сәбәп булды ул явызлыкның тууына? Әлбәттә, бүген без аны бик ачык аңлыйбыз. Илнең бөтен тармакларына астыртын рәвештә богау салучы сталинизм чире безгә дә килеп җиткән иде.

Илдә аңлашылмаслык дәрәҗәдә репрессияләр бара, кешеләрдә бер-берсенә ышаныч бетә, көн дә кемдер безнең арабыздан китеп югала...



*«Беренче чәчәкләр» спектакленә декорация*

Халык дошманы! Нинди авыр сүз. Безнең арабыздан К.Тинчурин, М.Мутин беренчеләрдән булып шул «дошман»га әвереләләр, аларны кулга алалар.

1937 елда көзгә таба театрда озакка сузылган җыелышлар уздырыла, көн дә арабыздан «халык дошманнары» эзлибез. Кешеләр бер-беренә шикләнеп карый башлады, хәтта үткәндәге кайбер хәлләрне ачыклау өчен, Ижевск шәһәреннән мөхтәрәмә Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская да чакырылды. Ул да үпкәләрен сөйләде. Мин ул вакытта театрның комсомол оешмасы секретаре идем, баштарак бу хәлләр, бик үк аңлашылмаса да, кызык булып тоелды, ләкин үземнең акылым, йөрәгем белән ул сүзләрнең күбесе хаксыз-нахак икәненә ышана бардым. Тик әлеге агымны туктатып булмый, сталинизм чире ташкын булып ярларны җимерә, сәнгатьне, мәдәниятне корытуга алып бара. К.Тинчурин, М.Мутиннар артыннан Г.Ильясов, ә тагы да соңрак Г.Исмәгыйлевләр безнең арадан китеп югалдылар. Театрның бөтен тарихын чагылдыручы музей бар иде, аның җитәкчесен дә шулай юкка чыгардылар һәм музейдагы тарихи материаллар пыран-заран килеп таралып беттеләр...



*Мохтар Мутин*



# БАЯН ГЫЙЗЗӘТ

**Таләпчәнлек үрнәге**

К.Тинчурин үз иҗатына гаять таләпчән булу үрнәген күрсәтте. Әсәрләре уйнала башлаганнан егерме биш ел үткәннән соң гына, ул үз пьесаларының беренче җыентыгын чыгарырга булды. Бу уңай белән аның түбәндәге сүзләре бик гыйбрәтле: «Сәхнә әсәрләре нихәтле озак һәм күп сәхнәдә уйналсалар, шулхәтле аларның кимчелекләре авторга ачыграк күренә башлый. Менә шул кимчелекләрне күрү һәм аларны бетерү өчен вакыт кирәк, әсәрнең фикер һәм сәнгать тирәнлегенә авторның үзенең ышанып җитүе дә кирәк. Менә шул сәбәпләр аркасында бу җыентыкка кергән кайбер пьесаларымны матбугатка чыгарырга тиеш тапмаган идем». Үз әсәрләренә карата булган фикерләргә һәм теләкләргә игътибар белән колак салып, К.Тинчурин аларны камилләштерү өстендә армый-талмый эшләде.



*Кәрим Тинчурин. 1917*

*Театрның элеккеге бинасы. Хәзерге Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы*



Үзенең чыгышларында К.Тинчурин һәрвакыт сәхнә сәнгатенең зур актуаль мәсьәләләрен күтәрде. Аларның төп пафосы социалистик тормышны дөрес һәм һәрьяклап чагылдырырга, замандашыбызның тәэсир итәрлек образын иҗат итүгә чакыру иде. Ул әсәрләрнең идеялелек мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирде, совет драматургларын халык тормышы белән яшәргә, үзләренең хәзерге бөек көн замандашлары булуларын онытмаска чакырды.

К.Тинчурин иҗаты нигезләнгән принципларның заман сынавын уңышлы үткәнлеген басым ясап әйтергә кирәк. Алар хәзер дә актуаль, әһәмиятле һәм бүгенге көн өчен дә зур кыйммәткә ия.

К.Тинчурин – драматург, үзенчәлекле режиссер, талантлы актер, теоретик театр эшлеклесе һәм оста хикәяче. Аның күпкырлы иҗаты бөтен татар культурасы үсешенә тирән эз салды.



# ВӘЛИ ХАҖИЕВ

**Бердәнбер рәсем**

Минем яшьлек елларым Кәрим Тинчурин иҗатының чәчәк аткан чорына туры килә. Һади Такташ белән якыннан аралашсам да, Кәрим ага Тинчурин белән андый аралашу бәхете тимәде. Әмма мин аның спектакльләрен якыннан белә идем. Архивымда Тинчурин һәм аның хатыны Заһидә ханымга кагылышлы фотолар бар. Менә бу рәсем (сүз түбәндәге рәсем турында бара. – *Мөх.*) миндә генә сакланадыр, мөгаен. Кәрим Тинчурин бөек әдибебез Фатих Әмирханның җәсәден җирләү комиссиясе рәисе буларак катнаша. Чалма ураганы – Борһан Шәрәф. Фатих Әмирханны гүргә иңдерәләр: Җамал Вәлиди, Габдулла Нури. Кулын кесәсенә тыккан, козыреклы башлык кигәне – Кәрим ага Тинчурин.

*8 май, 2002*

*Фатих Әмирханны җирләү вакыты. 1926*



# МӨНИР СӘЛӘХЕТДИНОВ

## Истәлекле хат



*Татар театры. 20 нче еллар. Элеккеге Сәүдәгәрләр клубы, хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасы*

Мин Кәрим Тинчуринны 1911 елдан бирле беләм. Ул вакытта мин Галиуллла исемле бер егет белән өс киеме һәм тамак ялына Садыйк Мусинның мануфактура магазинында (хәзерге Париж Коммунасы урамындагы 3 нче номерлы тегү фабрикасы урнашкан йортта) «өйрәнчек» булып эшли идем. Ә Кәрим абый монда конторщик вазифасын үти иде. Ул иртәнге якта гимназия күләмендә өлгергәнлек аттестаты өчен имтиханга әзерләнә, эшкә көннең икенче яртысында гына килә иде. Кичләрен «Үзбәк» кушаматы белән «Шәрык» һәм Яңа клубларда «Сәйяр» труппасы составында спектакльләрдә катнаша һәм аларны карарга Галиулла белән мине дә алып баргалый иде. Аның өстендә кара костюм, җәйге пальто, башында эшләпә, муенында һәрвакыт бер үк галстук була. Чәче җитү.

Кәрим абый бу чорда шигырьләр языштырды. Мин, иртән килеп, идәнне себергәндә аның кәрзингә йомарлап ташлаган кәгазьләрен алып укый торган идем. Шигырь язылган ике кәгазе миндә сакланып та калды. Соңыннан мин аларны Кәрим абыйның үзенә бирдем.

Кәрим абый ачык чырайлы, мәзәк яратучан кеше иде. Безнең кибет подвалының бер өлеше ашау-эчү урыны булып хезмәт итә. Мин Рамазановлар харчевнясеннән самовар кайнатып чыгам, кибетчеләргә чәй эчерәм, ә Кәрим абый мине: «Безнең Мөнир бар иде, чәйне бик сөя иде. Чуди-чуди, чудиса, чәйне бик сөя иде...» – дип үрти иде. Мондый чәй мәҗлесләрендә бай өйдә булмаган вакытлар-



*Париж Коммунасы урамы*



*Фатих Әмирхан*



*Габдулла Тукай*

да Габдулла Кариев, Габдулла Тукай, Гафур Коләхметов, Хөсәен Ямашев, Мөхәммәт Идрисов, Галиәсгар Камал, Закир Сәетзадә, Ибраһим һәм Исмәгыйль Айтугановларның да катнашулары хәтеремдә.

1912 елның җәендә булса кирәк, Кәрим абыйны Газиз Гобәйдуллин Кырымга курортка алып китте. Шуннан соң инде ул конторада эшләмәде.

1936 елда, Кәрим абыйның иҗат эшчәнлегенең 25 еллыгы уңае белән, мин аңа котлап хат язган идем. Шул елның 16 июнь числосы белән ул миңа түбәндәге хатны җибәрде:

*«Хөрмәтле Мөнир иптәш!*

*Сезнең минем 25 еллык хезмәт бәйрәмемне искә алып, котлап дусларча язган хатыгызны укып бик куандым...*

*Сез: «Эшләп укырга миңа юл күрсәтүче сез булдыгыз», – дисез.*

*Минемчә, сезгә дә, миңа да юл күрсәтүче, безгә бүгенге матур тормышны тудыру өчен ул чакта ук көрәшүче батыр большевиклар булган. Чөнки алар ул заманнарда да, үзләре идән асларында яшәсәләр дә, кыйммәтле фикерләре белән хезмәт ияләренең аңнарын яктыртулары белән минем исемдә. Ул сезнең дә исегездәдер. Ләкин без ул чакларда бүген алар безгә якынлашкан төсле якынлаша алмаган идек. Кайда җитте шунда, өметсезлеккә чумган шигырьләр язып кына маташа идек. Булган хәл булган да үткән. Аның каравы хәзерге көндә без Советлар иле, социализмның җиңүе өчен барлык көчебезне биреп, үткәндәге казаларны бүгенге эшебез белән капларга тиешбез.*

*Искә алуыгыз һәм хатыгыз өчен тагын бер кат дусларча рәхмәт.*

*Хөрмәт белән К.Тинчурин.*

*16 июнь, 1936».*

*«Социалистик Татарстан». 6 август, 1967*

## ЗӨЛФӘТ



**Теге чак**

Тинчуринның «теге чагын» күрдем,
Күрдем аны «секрет дело»да –
Передача илтеп, хәл белешеп,
Йөрер булганмын ла мин аңа!
Хәер, еллар бүтән, дивана!
Юк, сүнмәде... астан пыскый һаман
Явызлар ут төрткән бу учак! –
Ә «Зәңгәр шәл» дисәң, сискәндереп,
Һаман искә төшә «теге чак»!
«Булат, Булат кайткан!» – сизмәдекме
Ул Булатның каян кайтканын?
Мәйсәрәгә дигән зәңгәр шәл, дип,
Кайда гына җаннар атканын?
«Теге» дигән шул чак баласы без...
Булдык мәллә илдә бер курчак?
Юкса күптән инде «булакта» без?
Әмма...
ник ычкындырмый
Теге чак?

*Дзержинский урамындагы НКВД бинасы*



Истә Сибгат Хәким сөйләгәннәр:
– Кайтты Хәсән абый... тегеннән.
Күргәч әйтте: «Бергә икән!» –
Нигә әйткәнлеген мин беләм...
«Сүндермичә утны саклагансыз!» –
Дигәне ул шулдыр иде лә! –
Окопларда сау саклаган башны
«Халык дошманы»на и менә!
...Безнең язмыш язылгандыр инде
Бөек илгә ялгыш тегелеп,
Эзәрлекли безне гомер буе
«Безнекелек» түгел,
        «тегелек»!..
И туганкай, сереңяшермичә
Ачыктан да ачык әйт инде,
Бу җан өчен Тинчурин безнекеме,
Әллә инде
        «тегенекеме»?
Аларның бит җәсәдләре хәтта
Качып-посып кына күмелгән...
Тинчурин, дим... Үзебезгә язган
Сәер язмыш килә күңелгә...
...Күрдем Тинчуринның
        «тегендәге»
Төшерелгән яман сурәтен...
Шуннан бирле һич тә аңлый алмыйм
Тыңлаусыз бу сәер йөрәкне.
...Бер сорау бар – нигә сүнми һаман
Ул тергезгән гүзәл бер учак?
Әйттем. Беттем. Мин имзамны куям,
Һәм датаны куям –
        «теге чак»...

*Партиягә ышаныч белән караганнар иде дә бит...*





# БЕР-БЕРСЕН ЭЗЛӘҮЧЕ ИКЕ ЙОЛДЫЗ...





# РАБИТ БАТУЛЛА

## Җимерелгән бәхет*

***Заһидә ханым белән беренче очрашулар***

*3.10.1983.*

Кәрим Тинчуринның тол хатыны Заһидә ханым белән күрешеп, сөйләшергә күптәннән җыенып йөри идем, ләкин аның кайда торганын, телефонын белми идем. Шагыйрь Акъегет миңа Заһидә Тинчуринаның телефонын бирде. Очрашырга ризалык алып, Заһидә апа белән сөйләшергә киттем: Зайцев урамы, сигезенче йорт, бишенче фатир.


Ишекне Заһидә ханым үзе ачты. Ул ялгыз иде. Сиксән яшәр карчыкларның бу төре бик тере, көр тавышлы була. Аяклары авыртмаса, Заһидә апа йөгереп йөрер иде. Күренеп тора, аның аягы ойый, бер урында озак утырса, тиз генә кузгалып китә алмый, күрәсең.

---

* Шул исемдәге әсәрдән бүлекләр.



*Заһидә Тинчурина язучы Рабит Батуллага хатирәләр сөйли. 1987*



*Кәрим Тинчуринның китап киштәсе*

— Ә-ә, сезмени инде ул Батулла? Узыгыз! — диде хуҗабикә.

Ул ике кулын сузды, без татарча күрештек. Мин аяк кабын сала башладым.

— Җук, җук, салмагыз, зинһар, идән бик суык, аяк астында берни дә җук, юкса аягыгыз туңар. Сезгә кигезергә башмагым да җук минем. Салмагыз! — дип, Заһидә ханым шактый озын итеп сөйләргә тотынды.

Беренче җөмләләреннән үк мин шуны аңладым: Казанда туып-үскән татар зыялыларының ул вакыттагы балалары ана телен мөкәммәл белгән. Заһидә Тинчурина да акцентсыз «ю», «е» авазлары урынына «жу», «же» дип сөйли.

Тавышы көр, калын, чиста тавыш. Әгәр дә каршымда карчык торганын күрмәсәм, берәр ир кеше сөйләшә, дип уйлаган булыр идем.

Минем аякта әни бәйләгән йон оекбаш иде, каталарымны салып, бүлмәгә уздым. Чыннан да, идәнгә һични җәелмәгән. Шунысына игътибар иттем: өе суык, идәне шәрә булса да, хуҗабикәнең аягында базар оегы, таушалып беткән өй башмаклары. Аның өстендә дә җәй көне кия торган кыска җиңле ситса күлмәк. Бүлмәсендә тун киеп, мамык шәл бөркәнеп утырырлык салкын.


Өстәл янына утырдык.

— Сез якынрак утырыгыз, — диде Заһидә ханым. — Мин колакка каты. — Мин урындыгымны бераз тартып куйдым. — Җә, — диде Заһидә апа. — Сез кем? Таны-шыйк.

Мин үземнең укытучы, пьесалар язучы икәнемне сөйләдем.

— Ә-ә, сез дә киң интереслы кеше икән, — дип куйды хуҗабикә.

Әйләнә-тирәгә күз салдым. Өч шкаф. Берсендә китаплар: Көнбатыш классиклары белән рәттән Такташ, Камал һәм башкалар турында хатирә китапла-



*Кәрим Тинчуринның тәмәке төрепкәсе һәм тартмасы*

ры, Гомәр Галинең 1959 елда чыккан калын китабы, Гомәр Толымбай китабы, Тинчуринның 1928 елда чыккан «Җилкәнсезләр»е, «Казан утлары» төпләмәсе h.б. Шкаф өстендә кызыл бәрхеткә язылган, Тинчуринның бәйрәменә бүләк ителгән котлау язуы. Шкаф киштәләрендә язу әсбаплары, Кәрим абыйның сабы сынык төрепкәсе. Бер җай табып, мин төрепкәне алып, иснәп карадым. Баллырак тәмәке исе килә иде. Икенче шкаф киемнеке булса кирәк. Өченчесе буфет хезмәтен үти торган шкаф. Буфетта Кытайда эшләнгән борынгы ташаяк савыт-саба, кувшинга охшаш савытлар. Мохит ярлы. Ләкин бу ярлылыктан бай рухлы Кәрим Тинчурин карап тора кебек. Ярлы кеше өенә керә алмый торган кечкенә әсбаплар элеккеге хуҗаның да, бүгенге хуҗабикәнең дә кем икәне турында сөйли. Бу өйнең хуҗалары зыялы нәселдән

*Антиквар савыт-саба*



һәм алар кайчандыр бай булган, ләкин алар бөлгән. Минем уйларыма дәлил сымак итеп, Заһидә ханым әйтеп куйды:


— Кәрим үзе алган савыт-саба, — диде. — Бераз акча юнәтсә, ул гел антиквар, комиссион кибетләргә кереп, шундый борынгы савыт-саба алып кайта иде. Күбесе ватылып бетте. Бар калганы шушылар. Кәримне алгач, кешедән кешегә күчеп җөрергә туры килде. Чит шәһәргә дә куып чыгардылар. Күбесе юлда ватылды.

— Заһидә ханым, боларны тотып карарга ярыймы? — дидем.

— Ярый, әлбәттә! — диде хуҗабикә.

Кечкенә музейда кебек, мин Кәрим Тинчуринның кулы тигән әйберләргә сак кына кагылам. Аның җанын, рухын, аның чорын, аның талант нурларын тотып карарга теләгәндәй, тын гына әйберләрне назлап сыпырам.

Музейчыктагы бу әйберләргә карaганда, күбрәк сөйли торган, Тинчу-



ринның рухын яхшырак аңлата алырдай җан иясе Заһидә ханым иң кадерлеседер. Ул исән, Аллага шөкер, ул зиһенендә, хәтере яхшы. Хәле бар. Бу каһарман хатынга сокланып, сөеп карыйм.

– Мин сезгә нәрсә сөйләргә дә белмимен инде, – диде Заһидә ханым.

*Бу стаканны Кәрим Тинчуринга театр коллективы иҗат бәйрәме белән котлап бүләк иткән, көмеш балкашыкны – Габдулла Кариев. Балкашык тоткасында гармунчы аю басып тора. Кариев Тинчуринны «Аю» дип шаяртып йөрткән. 1917*

*Татар дәүләт театрының беренче составы. 1922–1923 ел театр сезоны*





*Кәрим Тинчурин сатып алган кытай сервизлары. 1930*





*Кытай панносы*



*Япон савыт-сабасы*

## Бер-берсен эзләүче ике йолдыз

Шаһбазгәрәй Әхмәров (Заһидә Тинчуринаның атасы) 1853 елда туган, 1900 елда вафат булган. Бик зур гыйлем-белем алгач, галим булгач, мәгърифәтче, актив зыялыларның берсе булып китә. Заһидәнең анасы Хәдичә ханым Алкин исемле алпавыт нәселеннән чыккан Арсаевның кызы. Хәдичә ханым ун бала таба. Шуларның өчесе сабый чакта ук үлә, җидесе: өч угыл, дүрт кыз гомерле була. Заһидә туташ тәрбия күреп, белем алып үсә, фикерле торган алдынгы юнәлештәге кыз

*Заһидә Тинчуринаның әти-әнисе – Хәдичә һәм Шаһбазгәрәй Әхмәровлар*



була. Гимназия тәмамлый. «Шәрык» клубына, Мәдәният йортына әдәбият кичәләренә атлыгып йөри. Бу мәҗлесләр өчен һәр җегет, һәр кыз иллешәр тиен акча җыешып, конфетлар, тәм-том алып, чәй эчәләр. Аракы-шәраб юк. Таңнар атканчы, сәгать дүртләргә кадәр уйнап-көлеп, җырлашып утыралар. Мәдәният идеясенең бик куәтле заманы була ул.

...Мәдинә Терегулова үзенең туена Заһидә туташны да чакыра:

– Кил, зинһар, туебызга Кәрим әфәнде Тинчурин да чакырулы. Мин сезне таныштырырмын. Гаять мәһабәт җегет, зыялы нәселдән.

Туй башлана. Тинчурин юк.

– Хәзер килеп җитәр, – ди Мәдинә ханым.

Кызлар инде ашап-эчеп туйган, җырлашып утыра. Заһидә туташ Тинчурин килүгә өметен өзеп, яшьләргә кушыла. Гитарачы студент Янбулатов янына утырып, ул да җырлый башлый. Туй азагында гына Кәрим әфәнде мәҗлескә килеп керә.

– Тинчурин килде, Тинчурин килде! – диләр барысы да.

Тинчурин, пианинога таянып, һичкемгә һични әйтмичә, шулай озак кына басып тора да, бер җай табып, юкка чыга. Ул чыгып китүгә үк, Заһидә туташ Мәдинәгә:



*Кәрим Тинчуринның булачак тормыш иптәше – гимназистка Заһидә. 1915*

– Шушы да булдымы инде синең Тинчуриның? – ди. – Бик интересный җегет икән, сөйләшә дә белми.

– Юк, юк, – ди Мәдинә ханым. – Һәйбәт кеше ул. Бүген әллә ни булган аңа.

– Ошамады миңа синең Тинчуриның! – ди Заһидә туташ.

Чынлыкта исә Тинчуринга да Заһидә ошамаган икән: әллә нинди кызыл авыз гитарачы җегеткә елышып утырган да, авыз күтәреп җырлый да җырлый.

## Икенче күрешү

Әшрәф Синяева исемле туташ Петербургта Югары драматик курслар тәмамлап кайта да Татар театрына эшкә керә. Беренче эше итеп, аңа «Соколы и вороны» исемле пьесадан мәхәббәт гүзәлен уйнарга тапшыралар. Ләкин пьесадагы икенче хатын-кыз ролен уйнар өчен театрда актриса булмый. Заһидә Әхмәрованы шул рольне уйнарга кыстый башлыйлар. Мутин да, Кариев та кызны үгетлиләр. Ләкин Заһидә ханымның артистка булырга уйлаганы да юк. Ул укытучы булачак. Көннәрдән бер көнне Кариев үзе, өйгә килеп:

– Заһидә туташ, милләтебез өчен, зинһар, риза бул! – ди.

«Милләт өчен» дигән тәгъбир ул вакытта тылсым көченә ия була. Заһидә туташ ризалаша. Шулай итеп, Заһидә Әхмәрова артистка булып китә. Аннан соң ул «Кан» пьесасында катнаша. Кәрим Тинчурин драмаларында уйный.

Бер тапкыр, кыш көне шулай репетиция ясап азапланганда, кемдер серле итеп:

– Кәрим абый кайтты! – дип пышылдый. – Тинчурин үзе кайтты!

Чыннан да, театрга кондыз якалы кыска тун кигән, башына модный кәтилүк салган Тинчурин аю кебек алпан-тилпән атлап килеп керә. Керә дә спектакльне үзгәртергә кушып чыгып та китә.

Ул вакытта Тинчуринга инде утыз ике яшь тулып килә. Буйдак тормышны шуннан да ары сузарга ярамый. Өйләнергә кирәк. Нигә өйләнмәскә? Заһидә туташ начар хатын булмас шикелле. Белеме дә, акылы да бар, диләр. Хәл ителде, карар кылынды.

*Театр гүзәлләре: Гөлсем Болгарская, Заһидә Тинчурина, Әшрәф Синяева. 1919*





*Кәрим белән Заһидәгә никях табыны әзерләүче Маһи тәтә. 1913*

## Тинчуринның өйләнүе

1919 елда Кәрим Тинчурин белән Заһидә Әхмәрова өйләнешәләр. Шулай итеп, дөньяда Заһидә Тинчурина исемле хатын пәйда була.

Заһидә үзе Аурупа, урыс культурасына ныграк тартылса да, туганнарының:

– Никях укытабыз! – дигәненә каршы килми.

Гәрчә Тинчурин да әйтеп куя:

– Мин дә никях укытырга атлыгып тормыйм, синең өчен, туганнарың күңеле өчен укытсак та булыр, – ди.

Зур туйлар ясап тормыйлар, авыр вакыт. Тары ярмасыннан ботка, өйрә пешереп, мулла чакырталар. Никях мәҗлесен Заһидәнең олы апалары Маһи тәтәсе, Фатыйма тутакае, әнисе хәзерлиләр. Никях вакыты килеп җитеп, узып китсә дә, мулла да юк, Кәрим кияү дә юк. Йорттагылар борчуга төшә. Нишләргә инде? Кәрим никяхтан качса? Бөтен татар дөньясына, бөтен Казанына оят, валлаһи!

Менә берзаман, көпчәкле арбага утырып, мулла белән Тинчурин кайтып килә. Кәрим күп итеп чәчәк бәйләмнәре алган – кәләшенә бүләк. Чин чином, никях бөтен тәртибенә китереп укытыла.

«Кәрим Тинчурин морза кызына өйләнгән!» дип, бөтен Казан шаулый.

Заһидә ханым ихластан көлә:

– Ә ул морзаның ашарга әпәе дә юк! Икенче көнне Кәримнең кесәсендә сукыр тиене дә калмый. Муллага, чәчәкләргә ул соңгы акчасын тотып бетергән икән. «Никях укытырга атлыгып тормыйм» дигәне дә аңлашыла. Олылап никях укытса, ашарга акчасы калмый.

Шулай итеп, Кәрим Тинчурин гаиләле тормыш корып җибәрә.



*Бер-берсен тапкан ике йолдыз. 1919*

## Килен кайта

1922 елда Заһидә ханым ире Тинчуринга әйтә:

– Кәрим! Без өйләнешкәнгә ничә ел?

– Өчтән артты, – ди Тинчурин.

– Синең туган авылыңа кайтып килик инде. Атаң-анаңны күрәсем килә. Аларның да килен күрәселәре киләдер бит инде?

Бүләк-санак алып, юлга чыгалар болар. Тарбиевка ыстансасына чаклы поезд белән кайталар. Ыстансада аларны Кәримнең атасы Гали абзый ат җигеп каршы алырга килгән. Такта арбага печән салган, печән өстенә түшәк түшәгән. Ыстансадан Тинчурин туган Таракан авылына кырык чакрым икән. Бик озак кайта торгач, Кәрим, кулын алга сузып:

– Ә-нә алда тау күрәсеңме, Заһидә? Шул тау астында безнең авыл булыр, – ди.

Шулай дигәч, Заһидә тиз генә калфак киеп, әйбәт чачаклы-чуклы шәльяулык бәйләп, төзәтенә башлый. Моңарчы дәшмичә кайтучы каената:

– Рәхмәт, килен! – ди. – Рәхмәт! Ату анагыз алдына, авыл халкы каршына шулай тузган баш белән кайта икән, дип кайгыра идем.

## Бимазалар

1921 ел. Ачлык башлана. Театр, тамак хакына уйнарга дип, Ырынбурга гастрольгә китә. Кәрим белән Заһидәнең бимазалы тормышы дәвам итә. Кәримнең гаиләсе ач булса да, Тинчурин аркасында тамак туйдыручылар табыла. Кайбер суфлерлар Тинчурин пьесаларын яттан белә, шулар, пьеса сорап килүче булса, астыртын гына Кәримнең пьесаларын күчереп, һәвәскәр театрларга сата башлыйлар. Ләкин Тинчурин борынын төшерми. Челем тарта-тарта төннәр буе пьесалар яза.

– Кәрим абыегыз артистлар белән дә, режиссерлар белән дә бик дус яшәде ул, – ди Заһидә ханым. – Баш режиссер булса да, кәпрәйми, башкаларга ихлас ярдәм итә. Башкаларның уңышына сөенә, уңышсызлыкларына көенә торган киң күңелле кеше иде Кәрим абыегыз. Бүгенге көндә дә миндә сакланган алтын сәгать әнә шул иҗади дуслык билгесе. «Беренче чәчәкләр» премьерасында Кыям ролен Габдулла Кариев уйнады. Шушы уңай белән Кариев Тинчуринга алтын сәгать бүләк итте.

*Алтын сәгать – Габдулла Кариев бүләге*



Заһидә ханым, алдан ук хәзерләп куйган булса кирәк, әллә каян гына бер төргәк чыгарды да, сүтеп, минем алга алтын сәгать китереп куйды. Сәгатькә кагылырга куркып, мин озак кына кыймылдамый утырдым. Сәгатьнең ак җирлегендә Рим саннары... Сак кына сәгатьне әйләндердем һәм... гүя тарих кылларына кагылдым. Үземнең күңел кыллары да тибрәнеп куйды... Соклану да, аяныч хисләр дә, Кариев белән Тинчурин һәм Заһидә апа алдында баш ию дә, күңел тулу галәмәте дә бар иде бу тибрәнештә. Сәгатьнең капкачында нәфис итеп уелган гарәп хәрефләре ярылып ята. «Беренче чәчәкләр. Мөхәррир-артист К.Тинчуринга бүләгем. 19.3.30. Г.Кариев» дип язылган иде. Мин, күземне алалмыйча, сәгатьне алай итеп карыйм, болай тотып карыйм. Заһидә апа дәвам итә:



*Сулдан беренче алтын сәгатьне Кариев бүләк иткән; уртадагы асма алтын котыйчык – татарның алдынгы бае М.Мусин бүләге. Аның икенче ягында «Үзбәккә М.Мусиннан» дигән язу. Уң яктагы сәгатьне Тинчурин Заһидә ханымга бүләк иткән*




– Габдулла Кариев Казаннан китеп тә йөргәләде инде ул. Янә кайтуы аның 1919 елның ноябрендә иде, ул безгә килеп кунды. Кәрим Кариевка атап «Сакла, шартламасын» пьесасын язды. Шул пьесаны куярга йөргәндә, Кариев авырып китте. Аның бавыр-бөере сафтан чыккан була. Тавышы карлыкты бичараның. Кемнеңдер әйтүенә ышанып, ул җылкы мае эчә башлады. Җылкы мае аны савыктырмады, тәмам эштән чыгарды. Кәрим белән без аның янына бик еш бара башладык. Колмәмәт, Ишмиләр чиратлап кизү торалар авыру Кариев янында.



*Язучыларның I корылтае. Лилия Сәйфуллина, Александр Серафимович татар язучылары уртасында. Мәскәү, 1934*

*Корылтай вакыты: Кәрим Тинчурин белән янәшәдә Заһидә ханым. 1934*





*Делегатлар Мәскәүгә корылтайга барышлый. 1934*



*Корылтайда тәнәфес вакытында: Кәрим Тинчурин, ..., Александр Серафимович, Гомәр Толымбай. 1934*

Аның хәле начарайганнан-начарая барып, соңгы килүебездә бөтенләй хәле киткән иде инде, ул Кәримне үз янына дәшеп алды да, бармагындагы хризолит кашлы йөзеген салып, Тинчуринга тоттырды: «Сакла, югалмасын! Терелгәч, кире кайтарырсың!» – диде. 1920 елның гыйнвар азагында ул вафат булды. Беренче февраль көнне без аны җирләдек. Йөзек Кәримдә калды. «Нишләтергә инде бу йөзекне?» – ди Тинчурин. «Үзең киеп йөр! Эстафета булыр!» – дидем. Шуннан соң Кәрим ул йөзекне бер дә салмыйча киеп йөрде.

1934 елда мин, Кәримгә ияреп, язучыларның Беренче корылтаена бардым. Бер генә көн дә калдырмыйча, җыелышларына йөрдем. Миңа кызык. Горькийны, Фадеевны, Серафимовичларны күрдем. Кәрим мине соңгы банкетына да алып барды.



*Драматург Кәрим Тинчурин. 1937*

**Зиндан**

– 1937 елда Кәримнең юбилее булды. Җәй көне без бергә булмадык. Обкомнан аңа колхоз темасына пьеса язарга заказ бирделәр. Хәтта аңа бераз гына аванс та тоттырганнар иде. Ул Сәйдәш белән авылларга, Мамадыш якларына чыгып китте. Мин Малиевкага ял итәргә киттем. Кәрим сирәк кенә миңа хат язгалый иде. Материал җыйдым. Ләкин келтемәчен табып булмый әле, дип яза. – Заһидә ханым көр тавышы белән көлеп куйды. – «Келтемәч» дигәне пьесаның «формасы, сюжеты» дигән сүзе инде. Келтемәче табылса, пьеса тиз языла ул, ди торган иде. Соңгы хатында: «Яза башладым, келтемәче табылды, язып бетерәм инде», – дип куйган. Көзен күрештек. Мин дә, ул да Казанга кайттык. Кәрим яңа пьесасын артистларга, язучыларга укыды. Аннан соң аның илле еллык юбилее булды. Бик олылап уздырдылар. Кәрим бик популяр иде бит. Популяр булса да, ул тыйнак булды. Борынын югары тотмады. Ул котлаулар, ул чәчәкләр, ул бүләкләр. Өй тулы чәчәк, мин чәчәк уртасында калдым. Шул кичне ул бик арып кайтты да йокларга ятты. Мин яңа пьесага урысча аңлатма язып, аны машинкада басып утыра торгач, төн уртасы җитте. Бу аңлатма сүзне иртәгә иртән Кәрим обкомга Пенхасик исемле кешегә илтеп бирергә тиеш иде. Ул чагында безнең квартира өч бүлмәле иде. Ишетәм: ишектә кеше бар. Ачсам, бер офицер, капитан бугай, ике боец. Ул чакларда солдатларны «боец» диләр иде. Ике боец, рөхсәт сорап тормыйча, мине бер кырга төртеп, өйгә керделәр. 1937 елның 15 сентябреннән 16 сына каршы төндә булды бу хәл. 15 сентябрь көнне театрда бик тә хантамалы бәйрәм ясадылар. Шул төнне алдылар да. Театр уйныйлар. Әзерләнгән юбилейны уздырырга мөмкинлек бирәләр дә, бәйрәм табыны узгач та, килеп алалар.



— Заһидә ханым, «хантама» дидегез, анысы нинди сүз? — дидем.
Хуҗабикә тагын көлде:
— Хантамасы биек, һо-о, аның хантамасы бик югары, дип сөйләшәләр иде. Ягъни мактанчык, артык горур, борынын күтәргән, үзен югары куя торган кешеләргә карата шулай әйтәләр иде... Кулга алу өчен прокурор санкциясе дә, ордер да юк килеш, хәрби киемле өч кеше өйгә басып керә дә, капитан әйтә: «Сез Тинчурин Кәрим буласызмы? Киенегез, тиз булыгыз!» — дип боера.
Йокы аралаш Кәрим башта берни дә аңламый тора. Ике боец идән уртасында кәгазьләр актара. Нидер эзлиләр. Үзләре ни өчендер бик ашыга. «Тиз булыгыз!» — дип кычкыра капитан боецларга. Һәм үзе дә эшкә тотына. Кәрим киенгән арада, капитан күн чемоданны тартып чыгарды. Ул чемодан эчендә Тинчуринның кульязмалары иде. Ни өчендер капитан шул чемоданга ябышты. Стенага эленеп куйган ау мылтыгын «конфискацияли». Күренеп тора: документ, ордер юк, исемлек төземиләр, кул куйдырмыйлар. Кычкыртып талау барганын мин хәзер аңлыйм инде. Бу мылтыкны Тинчуринга дивизия командиры бүләк иткән иде. Именной мылтык. Көмеш калайга Кәрим Тинчуринның исеме чүкеп язылган. Боецлар немецкий язу машинкамны алдылар. Бик сирәк, кыйбат машинка иде. Капитан келәмдәге алтын хәнҗәрне кесәсенә салды. Бу хәнҗәр инкрустация белән эшләнгән чын сәнгать әсәре иде. Кәримнең юбилеена кемдер, Кавказ кунакларымы бүләк иткән иде. Азәрбайҗаннар бугай. Ул арада Тинчурин киенеп бетте. Тегеләр һаман актарыналар, тентиләр. Кәрим мине тәрәзә төбенә утыртты да, иң өстемә кулын салып: «Әйдә, Заһидә, соңгы тапкыр тыныч кына бергә утырып калыйк әле», — диде. Без икәү тегеләрнең өй актарганнарына игътибар итмичә генә соңгы мизгелләрне уздырдык.
Боецлар икенче бүлмәдә актарыналар. Капитан капчыгына Кәримнең фотоаппаратларын тутыра. Шулчак Кәрим миңа ымлады. Идәндә, караватастында,





*Кәрим Тинчурин торган йорт. Хәзерге Профсоюз һәм М.Җәлил урамнары кисешкән урын*

яртылаш чыгарылган кара чемодан күренеп тора иде. Чемоданда — Кәримнең язылып бетмәгән романы. Иң яраткан, иң кадерле әсәре. Мин, кухнәгә узган булып, чемоданны аягым белән караватастына тибеп керттем дә, кухнәдән әйләнеп, Кәрим янына килдем.

Ниһаять, немецкий сигез фотоаппаратны да капчыкка салгач, капитан:

— Ирегезгә алмаш күлмәк-ыштан бирегез! — диде.

Мин, тиз генә кирәк-ярак төреп, Кәримнең кулына тоттырдым.

— Атлагыз! — диде капитан.

Заһидә ханым, тиз генә киенеп, ире артыннан бармакчы була. Ләкин капитан аның юлын бүлә:

— Сез кая?

— Иремне озата барам, — ди ханым.

— Ярамый! — ди капитан.

— Миңа урамга чыгып йөрергә дә ярамыймыни инде? Мин бит әле сезнең тарафтан кулга алынмадым шикелле? — дигәч, капитан хуҗабикә белән артык сүз куертып тормый, туздырылган кәгазьләр арасында тәртипсез рәвештә казынучы ике боецка:

— Булды, җитте, ташлагыз аларны! — дип кычкыра.

Шулчак Кәрим бармагындагы йөзеген салып, миңа бирмәкче булды:

— Сакла, кайткач, үземә бирерсең, — диде.

Ләкин йөзек салынмый. Ничә еллар йөреп, Кәримнең бармаклары юанайган, йөзек эчкә батып тора. Кәрим тешләре белән дә тартып карый — юк. Шуннан соң кухнәгә барып сабынлап, Кәримнең бармагын каната-каната көчкә салдырдык. Йөзек миндә калды.



*Кәрим Тинчуринны шушы кара капка аша 1937 елда алып чыгып китәләр*

– Быстрее! Чего там замешкался? – дип кычкыра капитан.

Тинчуринны алып чыгып китәләр. Заһидә ханым урамга чыкканда инде алар байтак ара китеп өлгергән була. Алда бер боец, уртада, ике кулын артка куеп, Тинчурин бара, аның артыннан икенче боец мылтыгын Тинчуринга төрәп үк атлый. Ян якта капчык күтәргән һәм уң кулына Кәримнең кыйммәтле мылтыгын тоткан килеш капитан атлый. Ашыгалар.

Заһидә ханым сөйләүдән туктады. Бераз уйланып утырганнан соң, үзалдына сөйләнгәндәй әйтте:

– Ни өчен шулай ашыктылар икән алар, дип уйладым мин гомер буена. Артларыннан кумыйлар лабаса. Караклар, йорт басучылар кебек кабалана иде алар. Капчыкка төяп, таланган әйберләрне күтәреп барганны кешеләр күрмәсен дипме? Белмим. Ихтимал, алар гаделсезлек кылганнарын күңелләре белән сизенгәннәрдер. Ярамаган эшне тизрәк, кабаланып башкаралар бит җинаятьчеләр. Мин урамның икенче ягына чыгып, аларны куып җиттем. Кәрим турыннан атлыйм. Каерылып аңа карыйм. Ул тыныч. Сүз дә ката алмыйм. Якын килергә дә ярамый. Төнге урам буйлап шулай дәшмичә генә атлыйбыз. Таш урамнар. Шомлы урамнар, шомлы таң алды. Мылтыклар тоткан өч сакчы Америка шпионы Джеймс Бондны тотканнармыни, Кәрим Тинчуринны шулай каты сак астында алып баралар. Чебенне дә рәнҗетми торган Кәрим, ата җинаятьче рәвешендә, сак астында йөри. Сирәк кенә каршыга очраган кешеләр куркып читкә атыла. Байтак шулай баргач, Кәрим кул ишарәсе белән миңа калырга кушты, артка куйган кулларын селки: Заһидә, йөрмә, кал, өйгә кайт, дигәнне аңлата иде ул ишарә. Мин туктадым. Дүрт шәүләнең караңгылыкка кереп югалганына кадәр карап тордым да өйгә таба борылдым, – Заһидә апа тирән көрсенде дә дәвам итте. – Өй эче



*Кәрим Тинчуринны Казанның бөтен төрмәләрендә дә йөрттәләр*





тузган. Ике зур шкафтагы китаплар чәчелгән, кулъязмалар тапталган, умырылган. Погром булган өйдә ялгыз калудан да шомлырак нәрсә бармы икән? Өйне җыештыра башладым. «Мәрҗәннәр»не яшердем. Бик теләп, куанып язды ул бу әсәрен. Сөләйман шәкертнең туганыннан алып бүгенге көненә кадәр язмакчы иде. Мин өй җыештырып бетергәндә, таң атты. Иртән нишлим? Вәгъдә ителгән пьесага урысча аңлатманы тотып, Пенхасик янына киттем. Кәрим аны үзе иртән тугызга китерергә тиеш иде. Обкомга барсам, Пенхасик юк. Аны да төнлә кулга алганнар икән. Аңлатманы бирәү дә алмады. Аңлатма салынган букчамны тотып кайтып киттем.

Кара көннәр башланганын Заһидә ханым шунда гына аңлый...

***Очрашулар дәвам итә***

*9. 01. 1984.*

– Безнең өйгә Сәйдәш бик еш килә иде. Килгән саен ул, рояль янына утырып, Чайковскийның «Сентиментальный вальс»ын уйный торган иде. Минем шул вальсны яратканымны сизенепме, әллә үз гадәте идеме, белмим, ләкин өйгә килеп, аның шушы вальсны уйнамыйча киткәне булмады. Сәйдәш, бәгырь, бик шәп кеше иде, яхшы кеше иде. Музыкасы да гаять моңлы, халыкчан. Чын мәгънәсендә талантлы кеше иде Сәйдәш.

– Заһидә апа, Нәҗип Җиһановның иҗатын сез яратасызмы?

– Әллә ниләр әйтсәләр дә, Нәҗип Җиһанов зур музыка кешесе, чөнки ул зур белемле кеше. Татарның олы композиторы ул Җиһанов! Бу турыда минем шигем юк!.. Нәфига Арапова да бик талантлы артистка иде. Фатыйма Ильская да зур талант иясе иде.

Хаклы булган Тинчурин, чыннан да, «вакытлыча гына булган аңлашылмаучылык» ике дистә елга гына сузылды. Шуңа сөенәме халык? Үтерелгән ирләре акланганга сөенеп, толлар җылый.

Бик җылар иде Заһидә Тинчурина, сөенеченнән рәхәтләнеп җылар иде, юк шул, андый рәхәтлек аңа бирелмәгән, күңел каткан. Бар ул бәхетле хатыннар. Алар, ичмасам, кайгыдан да, шатлыктан да җылый алалар. Андыйлар кайгыларын да, шатлыкларын да дусларына, хәтта чит-ят кешеләргә дә рәхәтләнеп сөйләп бушаналар. Егерме ел эт типкесендә яшәде ул, җыламады. Хәзер дә җылый алмый. Җылап утырырлыкмыни! Кәримнең әсәрләрен барлыйсы, яшергән урыннарыннан аның «Мәрҗәннәр»ен чыгарасы бар. Эш! Эш! Эшләп кенә эретеп була ул бәгырьдәге ачуташны.

*Артистлар 1 май демонстрациясендә. 1935*



*9. 05. 1984.*

– Самарада татарлар өчен студия ачканнар иде. О-о, ул студиянең әһәмиятен бәяләп кенә бетермиләр. Шул, әһәмиятле булганга, күрәсең, ул студияне яптылар. Ачлык, ил тыныч түгел, янәсе. Студиядә илле биш кеше иде. Шуннан безне Ырынбурга җибәрделәр. Анда да ачлык, тиф таралган. Халык кырыла. Артистларга, кеше башына илле грамм икмәк. Дәүләтшин исемле бер артистыбыз тиф белән авырып сәхнәдә үлде. Артистларыбыз тарала башлады. Шул вакытта Кәрим Ташкенттан хәбәр алды. Анда, Ташкентта, наркомпрос Шәһит Әхмәдиев иде. Шул язган: «Нигә анда ачка үлеп ятасыз? Ташкентка килегез! Үзем урнаштырырмын!» Шуннан Кәрим, кырык биш кешене алып, Ташкентка китәргә карар кылды. Труппаны алыр өчен бер вагон кирәк. Вагон алу һич мөмкин эш түгел. Труппаның директоры булып алмазлар алып-сату белән шөгыльләнүче Хәсән исемле кеше эшли иде. Ул булдыра алмаган эш юк дөньяда. Һәрхәлдә, шундый сүз йөри иде артистлар арасында. Хактыр да. Ачлык елны шул Хәсән ага Кәрим белән мине, Исмәгыйль Рәмине үз өенә кунакка чакырды. Табынданиләр генә юк иде, Ходаем! Дөньяда нинди тәмле ризык булса, барысы да бар иде шикелле. Мин күп ашый алмыйм. Ну, Кәрим белән Исмәгыйль Рәми рәхәтләнде инде, шартлаганчы ашадылар. Әнә шул Хәсән ага труппаны Ташкентка җибәрергә аерым вагон тапты. Кырык биш кеше, шул вагонга төялеп, ачлыктан, тифтан качып, Ташкентка киттек. Кәрим кешеләрне юата:



*Утырганнар: Хөсәен Уразиков, Кәрим Тинчурин; басканнар: Таҗи Гыйззәт, Зариф Закиров. 1931*

– Ташкентта минем якын дустым нарком булып утыра, Шәһит Әхмәдиев! Безнең эшләрне ул җайлар, иншалла, тамагыгыз тук, өстегез бөтен булыр, – ди.

Халык шатлана. Ләкин поезд барган саен, шатлыклар сүнә бара. Дөресрәге, поезд акрын бара. Туктый-туктый егерме ике тәүлек бардык. Ачыга башлады халык. Өчәр-дүртәр тәүлек дала уртасында торабыз. Күңелләр боек. Менә шул чакта Кәрим әкият сөйли иде. Дөм караңгы дала уртасында поезд тора. Чыгарга, берәр җиргә барып килерлек түгел. Ач. Хәл китмәсен өчен бөтен кеше сузылып ята, йокларга тырыша. Кәрим, әкият сөйләп, ачлык хисен оныттырырга тырыша иде.

– Кәрим абый, әкият сөйлә инде! – дип йөдәтеп бетерәләр иде артистлар.

– Юк, сөйләмим! – ди Тинчурин. – Ату җылыйсыз.

– Җыламыйбыз, сөйлә, зинһар, – дигәч, Тинчурин әкият башлый.

Ул үзе шундук уйлап чыгарып сөйли иде. Куркыныч, кызганыч әкиятләр иде алар. Кичләр буе, төннәр буе әкият сөйли Тинчурин артистларына. Ул фантазиягә бик бай иде. Ач кешеләрнең күңелен күтәрә белә иде. Психолог иде ул. Бик оста сөйли иде әкиятне.

Бер тапкыр вагоныбызны составтан өзеп, шыр дала уртасында калдырдылар. Тирә-якта авыллар-кышлаклар да юк. Разъездда бер кеше. Шуның әйтүенә караганда, еракта, әллә ничә чакрымда, бер татар авылы бар икән. Өч тәүлек ач утыр-

гач, артистлар түзмәде, шул татар авылына барырга, ни дә булса юнәтергә булдылар. Габрахманова, Баембәтова, Бадамшина – өчәү шул авылга чыгып китте. Корбан гаете вакыты иде. Бер көн юк болар, ике көн юк. Борчыла башладык инде. Берзаман күп итеп ризык төяп кайтып җиттеләр. Ат белән китереп куйдылар боларны. Ул авылда наданрак халык яши икән. Абыстайлары да, муллалары да юк икән. Әмма дини бәйрәмне корбан чалып бәйрәм итәләр ди. Безнең кызлар, табын янына утыргач, алмаштилмәш Коръән укып җибәргәннәр. Шаккаткан авыл халкы. Аштан ашка йөреп арып беткәннәр. Без тагын ач үлемнән котылып калдык.

Шулай итеп, Ташкентка барып җиттек. Безне күреп, Шәһит Әхмәдиевнең коты очты. Бер читкә алып китеп, Шәһит Кәрим белән миңа:

– Мин бит бөтен труппагызны чакырмадым, икегезне генә чакырган ием! Кая куеп бетерим мин сезне? – диде.

Без коелдык та төштек. Көчкә җан саклап килеп тә, монда чакырылмаган кунак булып, үги булып, урамда калу коточкыч хәл иде. Шәһит Кәримне наркомпроска урнаштырды. Тамак ялгарлык спектакльләр куйгалыйлар иде. Кая, ул кадәр кешенең тамагын туйдырырга спектакльдән кергән акча гына җитәмени?! Шулай итеп, труппа таралды. Без Кәрим белән Ташкентта калдык. Тора-бара Шәһит Әхмәдиев Казанга күчте һәм шунда үлде, мәрхүм.




*Чыгыш алдыннан*

Хәсән ага ТурЦИКның хастаханәсенә урнашты. Шәһит Кәримне наркомпросның сәнгать бүлегенә, мине Мәгариф институтына уку-укыту эшләре мөдире итеп куйды. Бер үк вакытта мин урыс теле һәм әдәбиятын да укытырга тиеш идем. Акча эшләре җайланып китте. Суфлер Хәсән Исхаков, Гаяз Исхакыйның энесе, әйтә миңа:

– Заһидә ханым, бик зур үтенечем бар иде, – ди. – Аяз әзинең кызы Сәгадәтне авылдан Ташкентка китерделәр. Аны ничек тә булса урысчага үрәтергә иде, – ди.

Аны-моны уйлап тормастан, мин ул кызны укытырга алындым. Минем профессиям мөгаллимлек, кемне укытсам да, миңа барыбер. Врач, кемнең кем булуына карамастан, авыру кешегә ярдәм итәргә тиеш. Шуңа күрә алар авыруларны чарасыз калдырмаска Гиппократ анты эчәләр. Укытучы да наданнарга белем бирергә бурычлы, дидем. Исхакый кызы Сәгадәткә мин ярты ел буе урыс теле һәм әдәбияты укыттым. Яраттым мин ул кызны! Бик матур, мөлаем кыз иде ул. Белем өчен янып тора. Телне бик тиз өйрәнеп алды. Ташкентта ул вакытта татар миллионерлары бик күп иде. Ташкентта гына түгел, бөтен Русиядә күп иде ул татар миллионерлары. Ташкенттагы шул бер миллионерның кызы әйтә:



*Төркия. Истамбул*

– Заһидә ханым, миңа олы бәхет инде бит әле, – ди туташ. – Мине, Сәгадәтне, тагын дүрт-биш кешене Мостафа Кемал иленә, Төркиягә алып китәләр.

Шулай итеп, Сәгадәт Төркиягә китте.

...Кәрим тиф белән авырый башлады. Хәсән ага аны үз янына алды. Бик озак чирләде Кәрим, саташа-саташа нык көрәште чир белән. Шул чакны ачлар файдасына «Таһир-Зөһрә»не ике тапкыр уйнадык. Тинчурин тора алмый, авыр хәлдә, ләкин спектакльне өзмәскә кирәк. Кәрим янында утырып торыр өчен бер шәфкать туташы калдырдык. Кәримнең тәне 40 градуска җитеп кызыша иде. Спектакль уйнап кайтуыбызга, Кәрим Хәсән абый белән мине ачулана башлады.

– Нигә сез мине шул мәгънәсез кызга ташлап киттегез?! Үтерәсегез киләмени?! – ди.

– Саташа бугай, – диде Хәсән абый.




*Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт*

– Саташмыйм! – ди Тинчурин. – Ул кыз миңа кич буе тифтан үлгәннәр турында сөйләде. «Кәрим абый, сез Бадамшина апаны беләсезме?» – ди. «Беләм», – дим. «Ул кичә тифтан үлде», – ди туташыгыз. «Сез төгән кешене белә идегезме?» «Юк, белми идем», – дим. «Ул да сезнең кебек тиф белән авырый иде, өченче көн җирләделәр», – дип, теңкәмә тиеп бетте.

Кәрим тифтан савыкты. Ләкин шул авырудан соң аның бөерендә таш калды. Интегә иде. Ел саен ул Ессентукига барып, шуннан әйбәтләнеп кайта иде. Ләкин бераз вакыттан соң авыруы кабат башлана иде.

Ташкентка Фәтхи Бурнаш килеп төште.

– Мин сезне Казанга алып кайтырга килдем! – диде. – Миңа әйттеләр, Тинчуринны Казанга алып кайт, диделәр. Казанда дәүләт театры ачыла, Тинчурин Казанда кирәк, диделәр.



*Әтисе Гали Тинчурин. Кәрим Тинчурин төшергән рәсем*

*Әнисе Мәхмүдә Тинчурина*



Бер ел Ташкентта яшәгәннән соң (1921 елның август урталарыннан 1922 елның көзенә чаклы), Казанга кайтып киттек.

...Атасы белән Кәрим дус түгел иде. Әнисе мулла кызы. Тәрбияле, укымышлы хатын иде, мәрхүмә. Кәримнең атасы белемсезрәк, ләкин хәлле крәстиян иде. Каралты-кура нык. Ләкин ялчы тоткан кеше түгел. Үзе эшли бөтен эшне. Үз көче, балаларының көче белән көрәйгән хуҗалык иде ул. Шуңа күрә ул Кәримне хуҗалыкта калыр, эшче-ярдәмче булыр, дип үстергән, өметләнгән. Каенанам исә Мәхәммәткәрим бик зиһенле бала, аны укытырга, Казанга җибәрергә кирәк, дигән фикердә тора. Атасы моңа бик тә каршы була, эшче кул хуҗалыктан китә ләбаса. Әнисе Кәримне, яшертен генә, Казанга озата. Кәрим атасының фатихасын алмыйча киткән кеше. Шуның аркасында каенанам белән каенатам арасында гомерлеккә ризасызлык кала. Бәлки, шуңа күрәдер дә Кәрим кунакка кайткач та, атасы белән утырып сөйләшмәде. Ата-

сы да гомер буе эшне минем аша йөртте. Турыдан-туры ул Кәримгә дәшми иде. Кәрим дә минем аша гына әйттерә иде кирәк сүзен. Тел яшерәләр иде алар. Каенатам белән без бик дус идек. Ул һәрвакыт миңа:

– Зәйдә! – дип эндәшә иде.

Кәрим әнисен үлеп ярата иде. Әнисе дә:

– Мәхәммәткәримем! – дип кенә сөйләшә иде.

Каенанам безгә, Казанга, гел килә торган иде. Бер тапкыр безгә Кәримнең әнисен театрда эшләүче бер кеше китереп куйды. Шаккаттым.

– Әнкәй, шулкадәр араны ничек килеп җиттең? – дим.

– Качтым авылдан, туйдым, гарык булдым! – дип, ул ничек килгәнен сөйләп бирде.

Ләкин ул ни өчен качканын сөйләми. Каенатам һәрвакыт хатынын:

– Әнә Кәримең кәмитче булып китте, син аннан үзең кәмитче ясадың! – дип битәрли икән.

Каенанам кырык чакрым араны җәяү узып, поездга утырып, Казанга китә. Поездда аннан урыслар сорый:

– Куда едешь, мамаша? – диләр икән.



*Кәрим Тинчурин. 1934*



*Воскресенская (хәзерге Кремль) урамы. XIX гасыр ахыры*



*М.Горький урамы*

– Казан! – ди карчык.
– Кому едешь, мамаша?
– Сын!

Шушы ике сүз белән ул Казан тикле Казанга килеп төшә. Кулында безнең адрес та юк. Кая барырга белми бу, ничек итеп безне эзләп табарга баш вата. Качып чыгып китүе, күрәсең, бик ашыгыч булган. Үзе урысча да белми. Шулай аптырап йөргәндә, татарлар очрап, сорыйлар моннан:

– Әби, кая барасың? – диләр.
– Улым Мөхәмматкәримнәргә! – ди әби.
– Адресы бармы?
– Әдрисен белмим шул.

Шуннан «барабыз»га утырталар моны. Ул вакытта атлы кучерлар кеше ташый торган иде. «Барабызмы?» – дип сорый барырга теләүче. «Барабыз», – ди кучер. Шуңа күрә ул «таксиларны» «барабыз» дип йөртәләр иде. «Барабыз» сорый:

– Кая илтим, апа?
– Мөхәмматкәримнәргә! – ди ана.
– Кайсы Мөхәмматкәрим ул, әби? Кайда эшли ул Мөхәмматкәрим? – ди «барабыз».
– Театрда! – ди ана.
– Һәй, алайса, ул Кәрим Тинчурин инде.
– Ие, ие, Мөхәмматкәрим Тинчурин минем улым!
– Яхшылап утыр, апа, киттек! Мин сине улыңа тапшырам! – дип, «барабыз» каенанамны театрга илтеп куя.

Анасын күреп, Кәрим аптырап кала һәм шундук аңлый да: карчыкның авылда яшәргә сабырлыгы калмаган икән. Шул килүдән каенанам бездә ике ай торды.

Киткәндә әйтте:

– Ике ай сездә торып, бер кыцкырышканыгызны ишетмәдем, бер яман сүз колагыма кермәде, рәхмәт, балалар. Мин сездән бәхил, – диде.

1926 елда ул җан тартты, мәрхүмәкәем. Бик хөрмәтләп җирләдек.

Утызынчы елны Кәримнең атасын раскулачивать иттеләр. Улы белән Себергә сөрделәр. Кызы белән киявен дә сөрделәр. Улы Себердә үлеп калды, мәрхүм. Сөргеннән атай ялгызы гына безгә кайтып төште. Көр тормышлы Галидән бөкшәйгән карт кына калган иде. Бездә тора башлады инде, кая барсын? Озак кына торды ул. Ләкин Кәрим һаман атасы белән сөйләшмәде. Сүз гел минем аша гына йөрде.

Ата белән улның тату булмаганына бик көенә идем. Икесенә дә читен, миңа да читен.

– Кәрим, атаң бит, нигә сөйләшмисең, нигә дуслашмыйсыз? –дип ялынам.

– Юк, Заһидә! – диде Кәрим. – Үземне җиңә алмыймын. Кыстама!

Ләкин Кәрим атасына киемнәр алды, өс-башын карады. Себердән атакай ябыгып, бик сәләмә кайткан иде.

– Ипи ашап туя алмыйм, – ди иде, бичара.

Җәй җитүгә, ул авылына кайтып китте.

Утыз җиденче елда Кәрим кулга алынгач, мин бу турыда атасына авылга яздым. «Зәйдә, яз, зинһар! Мөхәммәткәримне ни өчен утырттылар? Акча туздырганмы? Нигә язмыйсың?» – дип, әллә ничә тапкыр хат язды. Ләкин мин аңа җавап яза алмадым. Ярамый иде. Атакаебыз Али авылда вафат булды.

– Урынын җәннәттән әйләсен!

– Амин, шулай булсын! – дип җөпләп куйды Заһидә ханым.

*Югары Ослан кибетчесендә кунакта. 1915*





*Әстерхан. Ак мәчет*

*Печән базары мәчете*



*29.09.1984.*

– Егерме алтынчы елларда кайбер артистларның һәм язучыларның Кәрим өстеннән язганнары да бар иде: «Тинчурин үзе яза, үзе куя, үзе уйный. Театрны ул үз монополиясенә әверелдерде», – дип яза тордылар. Шул язудан соң Кәримне театрдан чыгардылар. Өйгә кайтты. Аптыраган, ишектән мескенләнеп кенә кайтып керде бу. «Заһидә, мине театрдан чыгардылар бит», – диде. «Бик яхшы булган, – дидем. – Язарга вакытың күп булыр. Рәхәтләнеп өйдә генә язарсың. Ә болай төне буе пьеса язасың, йокламыйча театрга китәсең. Эшмени ул?»

Эшсез калды Тинчуриныгыз, иҗат итә алмыйча йөдәде. Ул, көндез театрда эшләп, төнлә язу тәртибенә күнеккән иде. Эшсез калгач, бер җөмлә дә яза алмады. Эш эзләп йөри торгач, аны Политпросветка урнаштырдылар. Анда штатта өч кеше икән. Берсе – Вафа Бурнаш, икенчесе – Каменевныңмы, Зиновьевныңмы секретаре, өченчесе – Тинчурин.

– Туктале, Кәрим, – дим. – Син анда нинди эш майтарасың соң?

– Кем ни тели, шуны эшли. Һәркем үз эшендә. Мин «Ил» пьесасын язып утырам, – диде Тинчурин.

Тинчурин киткәч, театрның эшләре ал да гөл булыр, дип уйлаганнар бик нык ялгышты. Театрның репертуары да, актерлары да, режиссурасы да каушауда иде. Шулай да Тинчуринны театрга кайтармадылар. Тинчуринны күпсенүчеләр күп иде театрда. Аны Әстерханга сөргенгә җибәрделәр. 1927 елның язында* ул китте. Тинчурин белән Арапова, Әсгать Мәҗит, Галия Булатова, Галия Нигъмәтуллина-

---

* Бу урында шунысын искәртеп үтәргә кирәк: кайбер язмаларда К.Тинчурин театрда 1927 елның ноябренә чаклы кала диелгән. – *Мөх.*

*Әстерхан татар театры бинасы*



лар, Мәрьям Чанышевалар, тагын берничә артистка да китте. Казан театры тагын да зәгыйфьләнеп калды. Мин аның белән бара алмадым.

Таныш хатыннар, артисткалар каныма тиделәр:

– Нигә Тинчуринның үзен генә анда җибәрдең? Сине ташлар дип курыкмыйсыңмы? Әстерхан тулы япь-яшь кызлар, – диләр.

– Нишләп үзе генә китсен? Аның белән театрның иң гүзәл хатыннары китте бит, – дип көләм.

Алар аптырый, ә мин көнләшми идем.



*Кәрим Тинчурин (уртада) Әстерхан театры артистлары белән. 1929*

* * *

Шулай бервакыт ачлык бик интектерә башлагач, Кәримнең әйберләрен базарга чыгарып сата башладым. Иң соңыннан аның бер пинжәге генә калды. «Кәрим, – дим, – бар инде, монысын үзең сатып кайт», – дип, Кәримне базарга чыгарып җибәрдем. Көтәм – юк, көтәм – юк. Бик озак көтә торгач, чыгып киттем Кәримне эзләргә. Барсам, күрәм, мескенем, аптырап, кыюсыз гына, үзенә генә ишетелерлек итеп: «Харуший пиджак, харуший пиджак», – дип басып тора. Кыяфәте чиста, Кәрим үзе мәһабәт кеше иде, янына килүче юк. Бөтен спекулянт аны читләтеп уза тора. Барысы да Кәримне «подставной» дип уйлый. Озак басып торды ул пинжәген селкетер-селкетмәс. Кызгандым бичараны. Мине күреп алгач, Кәрим, бата башлаган кеше ничек итеп бүрәнәгә тотынса, миңа шулай омтылды: «Мә, мә, зинһар, үзең сат! Миннән сәүдәгәр чыкмый!» – дип, пинжәген миңа бирде.

*10.10.1984.*

– Мәхшәр вакытында Кәримнең кулъязмаларын сакларга тырыштым. Кешеләр әйттеләр: «Тинчуриннан нинди кәгазь калды, барысын да яндыр, үзең белән тотма», – диделәр.

Яндырмадым. Сакладым. Әнә «Мәрҗәннәр» романы, шөкер, барыбер дөньяга чыкты бит. Яндырган булсам, нинди үкенеч була иде. Уйлый идем: кайчан да булса, йөз елдан соң булса да, мин үлгәч булса да, Кәримнең әсәрләре барыбер басылачак. Беркайчан да чыкмый икән, димәк, Кәрим Тинчурин чүп булган, язганы да чүп-чар булган! Аның исеме калыкса, мин күргән җәфалар, димәк, бушка китмәгән!..



*Кәрим Тинчурин Әстерхан театры гүзәлләре арасында. 1929*

Чәйнек кайнаган тавышка Заһидә апа сискәнеп китте дә кухнәгә таба йөгерде. Күңеле ашыга, аяклары тыңламый, артта кала. Егыла дип, котым очты. Егылмады. Газны сүндерде. Шаулап торган чәйнекне алып килеп, өстәл уртасына утыртты. Чәй пешерергә куйды.

– Без Кәрим белән бик сабыр яшәдек. Бер-беребезгә көнләшү ямьсезлекләре күрсәтмәдек. Әүвәл безнең мәҗлесләрдә ир белән хатын парлашып утыру юк иде. Ир-хатын парлашып кунакка килә. Бергә кайтып китә. Ә мәҗлестә аерым утыралар иде. Хәзер күрәм, кунакта ир-хатын янәшә утыра. Өйдә бергә, кунакта бергә. Ичмасам, кунакта башкалар белән аралашырга кирәк. Кәрим һәрвакыт дамалар арасында утыра иде. Мин дә ир-җегетләр уртасында була идем. Мине бик ухаживать итәләр иде. Чибәр булмасам да, һәрвакыт комплиментлар, ухаживание, игъ-



*Заһидә Әхмәрова (икенче рәттә сулдан беренче) курсташ кызлар белән*

тибар уртасында идем. Кунактан Кәрим белән бергә кайтып китә идек. Безнең шулай иркенләп йөргәнебезгә күпләрнең эче поша иде. Мин музыка яратам, җырчылар, скрипкачылар, Италия, Югославия, Мәскәү, Петербург артистларының концертларына йөрим. Нежданова, Игумнов, Гольденвейзерларны тыңлыйм. Күп чакта Кәримнең вакыты булмый. Җә ул репетициядә, җә спектакльдә. Шулай да ике-өч тапкыр Кәримне дә алып бардым. Ойстрахка, Обуховага бергә бардык... Мин дә Кәрим артыннан күзәтеп йөрмим. Кәрим сигез ай* Әстерханда ялгызы булды. Килеп, минем күңелгә вәсвәсә салырга тырышучылар күп булды. Мин Кәримгә ышана идем. Ул ир кеше. Әгәр дә ул башкаларны коча икән, кочсын. Моны мин хыянәт дип атамыйм да. Ишетсәм, белсәм дә, белмәмешкә салышыр идем. Ул барыбер мине ярата, ул барыбер минем янга кайта. Ни әйтсәң дә, ир кешегә сигез ай хатынсыз тору шактый катлаулы эш. Әгәр дә мин аның өчен чит-ят бер хатынга әйләнгәнемне сизенсәм, менә бу хәлне мин кичерә алмас идем. Концертлардан соң мине кавалерлар өйгә озата иде. Кем озатканын мин Кәримгә әйтә идем. Сүз куерту юк. Миңа әйтәләр иде: «Какой у вас муж красивый». Янәсе, мин матур түгел. Мин үземнең матур түгеллегемне бала чактан ук белеп үстем. Әмма Кәрим мине бик якын-үз күрде. Без яратышып яшәдек.

---

* Документларга караганда, К.Тинчурин Әстерхан театрының 1927–1928, 1928–1929 сезоннарын җитәкли. Заһидә ханым, сигез ай дип, Тинчуринның беренче кайтып китүен күздә тоткандыр. – *Мөх.*

*17.09.1984.*

– Тукайны исән чагында күрә алмасам да, зиратка кадәр озата бардым. Без урыс гимназиясендә дүрт татар кызы укый идек. Реверанс ясап, сыйныф җитәкчесеннән үтендек:

– Лидия Петровна, скончался Тукай – наш татарский Пушкин, разрешите уйти с уроков, – дидек.

Һичсүзсез җибәрделәр. Йөгердек Клячкин хастаханәсенә. Саф-саф булып озата бардык. Зиратка кермәдек. Ул чакта гореф-гадәт бик нык иде. Озата баручылар арасында курсисткалар, гимназистлар, «Высшие женские курсы»ларда укучылар, реальное училищеларда укучылар, эшчесе, крәстияне – барысы да бар иде.

* * *

– Мин театрда алты ел артистка булып эшләдем. Мутин белән күп спектакльләрдә уйнадым. Әбер-чәбер рольләрдән тыш, зур гына рольләр дә эләгә иде. Бер тапкыр Мутин, урыстан тәрҗемә итеп, спектакль куйды. Күренешләр алмашынганда декорацияләрне Мутин үзе бутаган да, сәхнәгә чыксам, миңа кирәк булмаган җиһазлар куелган. Керү, чыгу ишекләре буталып беткән. Шулай итеп, көлкегә калдык. Шуннан соң Мутин миңа Сәлимә ролен бирде. Ләкин мин бу эшкә алынмадым. Мутин әйтә:

– Син, Тинчуриннан куркып, минем спектакльдән баш тартасың, – ди.

Без ул чакны Тинчурин белән йөри башлаган идек инде. Ләкин барыбер уйнамадым.

*Габдулла Кариев театр гүзәлләре белән. Сулдан уңга: Заһидә Тинчурина, Нәфыйга Арапова, Гөлсем Болгарская, Әшрәф Синяева. 1917*





*Язылышу турындагы таныклыкның күчермәсе*

*1.07.1986.*

Сәгать уннарда Заһидә апа янына киттем. Ни хикмәттер, бик тиз ачты. Кәефе дә әйбәт. Бик озак сөйләшеп утырдык. Бераз буталып ала, ләкин төп нәрсәләрне төгәл әйтә. Зарланмый. Бер сөйләгәнне кат-кат сөйли, мин барыбер язып барам. Чөнки һәр сөйләгән саен, ул берәр яңалык өсти.

– Кәрим белән анасы бер-берләреннән башка тора алмый иде. Табын янында да гашыйклар кебек бер-берсенә карашып утыра иде алар. Анабыз авырып киткәч, Кәрим бик карады анасын. Савыктырырга бик күп көч куйды. Врачларның иң яхшыларын гына чакырта иде. Интекте, мәрхүмә. Әнисе җан биргәч, Кәрим «аһ» итеп бер кычкырды да, күз яшьләрен йотып, җыламаска тырышты. Без Кәрим белән анаң каберенә бик еш барып йөрдек. Кәрим таш куйдырырга йөри башлады. Өлгермәде. Башта биш айлык гастрольләргә чыгып китте. Йөреп кайткач, илле яшьлегенә багышланган бәйрәмен әзерләп йөрде. Аннан алып киттеләр...

* * *

– Никяхлашканнан соң дүрт ел яшәгәч кенә, без загска киттек. Кәрим әйтә, никях никях инде ул, язылышырга кирәк, ди. Ике татар кызы һәм ике марҗа утыра. Без килеп кергәч, марҗасы сорый:

– Сез кызыгызга документ эшләргә килдегезме? – ди.

Татар кызлары көлә. Кәримне таныйлар бит инде.

– Юк, – диде Кәрим. – Без никях рәсмиләштерергә килдек!

Мин Кәримнән ун яшькә кече идем. Ул олырак күренгәндер инде. Марҗа тагын сорый:

– Бу сезнең ничәнче өйләнүегез? – ди.

Татар кызлары тагын көлә.

– Беренче, беренче! – дип кычкыра татар кызлары. – Кәрим абыйның өйләнгәне юк.

Кәрим:

– Беренчесе һәм соңгысы! – диде.

*6.12.1986.*

Заһидә апаның бүген кәефе әйбәт. Көлә, шаяра.

– Таныш хатыннар мине котырта иде, Кәрим үзенең әнисен синнән артык сөя, диләр. Ә мин аптырап тормыйм: «Кәрим әнисен ана буларак, мине хатыны буларак сөя», – дип, авызларын каплый идем. Дөресе дә шулай булды. Кәримнең әнисе мине бик ярата иде. «Безнең Зәйдә» дип кенә тора иде.

Кәримдә ялгызлык хисе һәрвакыт була торган иде. Ул үзенең бу гарип җәмгыять өчен чит-ят икәнен гел тоеп яшәде. Шушы гарип җәмгыятьнең кайчан да булса аңа китереп сугасын да ул сизенә иде кебек.



*Шабһазгәрәй Әхмәровлар гаиләсе. Уртада – Заһидә туташ. 1910 (?)*

*31.12.1986.*

– Кәрим – йокы чүлмәге, дигән кушамат театрда бик актив кулланыла иде. Ничә барсаң да, Кәрим абзый йоклап ята. Ул нинди туймас йокы, диләр иде.

Кәрим төнлә яза иде. Көндез театрда була. Төне буе язып утыра да иртән берике сәгать йоклап ала. Йомыш белән килгән кешегә ул һәрвакыт йоклый кебек күренгәндер инде. Бер танышым әйтә: «Заһидә ханым, нигә сез өегезгә килгән кешеләрне куып җибәрмисез? Мин иремне сорап килгәннәргә ишекне дә ачмыйм», – ди. Юк, Кәрим Тинчурин да, мин дә алай эшли алмадык. Кәрим андый түгел иде. Килүче булса, сикереп тора, якты чырай белән каршы ала иде.

Заһидә ханым тагын хатирәләргә чумды:


– «Шәрык клубын»да спектакльләрдән соң танцылар була торган иде. Тинчурин, минем янга килеп:

– Сезне озатырга мөмкинме? – диде.

– Юк! – дидем. – Мин Җиһангир белән кайтам.

Анакаем мине туганыбыз Җиһангир Алкинга ияртеп җибәрә иде, Җиһангир мине түкми-чәчми алып кайтып анакаема тапшыра да, үзе кайтып китә. Икенчесендә Тинчурин миңа айнырга да ирек бирмичә:

– Бирегез номерыгызны! – дип, мин җавап бирергә әзерләнеп өлгергәнче, кулымнан номерны алып, киемнәрне күтәреп читкә алып китте. Миңа киенергә булышты. Мин аңа үземне озата кайтырга рөхсәт иттем. Юл буе берни сөйләмәде. Мин дә сораштырмадым. Капкага җиткәч, тыныч йокы теләп, Тинчурин кай-



*Ялтада. 1915*
*Кәрим Тинчурин белән янәшәдә кем басып торган – билгесез. Ул сурәтне кемдер кырып юкка чыгарган. Бәлки, 1937 ел фаҗигасе шулай кушкандыр...*

тып китте. Шул озатудан соң без озак көрешмәдек. Бераз вакытлар үткәч, ул мине гел озата кайтырга өйрәнеп китте. Мин дә инде күнегеп беттем аның озатуларына. Кәрим мәктәптән чыкканымны да көтеп ала башлады. Соңгы озатуында, мин әйттем:

– Кәрим әфәнде, безнең өйгә дә кереп утырыр идегез, – дидем.

– Башка вакытта, – дип, Тинчурин кайтып китте.

Бервакыт Тинчурин мин өйдә юкта безнең өйгә килгән. Мин кайттым. Тинчурин анакаем белән чәй эчеп, сөйләшеп утыралар иде. Мин бүлмәмә уздым. Аларның ни турында сөйләшкәннәрен ишетмәдем. Тинчурин чыгып киткәч, әни әйтә:

– Бик ипле икән Тинчуриның, – ди. – Татарчасы да бик яхшы, укыган кеше.

Мин бик капризный идем, шулай да юк-бар шаяруларга, әнинең «Тинчури-

ның» дигәненә ни өчендер ачуым килмәде. Анам бик укымышлы кеше иде минем. Толстойны яттан белә, хәтта Толстойның берничә әсәрен татарчага да тәрҗемә итеп бастырды, Ырынбурда басылды ул әсәрләре. «Камско-Волжская речь»не хәрефен калдырмый укып бара иде. Коръәнне дә анакаем яхшы белә иде. Кәрим белән аларның сөйләшергә сүзләре күп булгандыр. Анакаем бик ошатып калды Тинчуринны. Тинчурин инде үземә дә ошый башлаган иде. Шулай беркөнне анакаем әйтә:

– Кызым, сине Тинчуринга кияүгә чыга дип сөйлиләр, хакмы ул? – ди.

– Анакаем, мин сиңа әйтмичә кияүгә чыгаммыни инде? Син фатиха бирсәң, мин Тинчуринга чыгар идем, – дидем.

– Ул сине кадерләп яшәрме соң? – диде анам.

– Ни булса да, мин Кәримне яратам, – дидем.

– Алайса, фатиха! – диде анакаем.



*Тинчуриннар гаиләсе дуслары белән дачада. 30 нчы еллар*

* * *

Кәримнең бавыры, бөерләре авырта иде, ул ел саен курортка бара. Мине дә үзе белән барырга кыстый. Мин бармыйм. Дачага китәм.

– Зәйдә, нигә син минем белән ялга бармыйсың? – ди.

Мин:

– Син озын буйлы, чибәр ир, курортта гүзәл хатыннар күп була. Мишәйтләп йөрмим әле. Ату әйтерләр: «Кара, бу татар үзе чибәр генә, хатыны ямьсез икән», – диярләр. Бар, үзең генә ял ит, – дип әйтә идем.

Андый чакта Кәрим:

– Һи, җүләр дә инде син, Зәйдә! – ди иде.

* * *

– Кәрим иртә пеләшләнде. Шуңа эче поша иде аның. Хәрирә – Гомәр Галинең хатыны – бик шаян кыз иде. Кәрим язып утырганда, Хәрирә сиздерми генә килә дә, Кәримнең пеләшен сыпырып: «И-и, Кәрим абыкаем, яратам бит мин сине, бигрәк тә такыр башыңны!» – дип көлә иде. Килгән саен шулай итә, Кәримнең шуңа ачуы чыга иде.

Кәрим мунча ярата иде, чабына, ух-вах килә. Озаклап, әлсерәп беткәнче керә иде ул.

Революция вакытында Аскәр җизнәм аклар гаскәрендә хезмәт итте. Колчакта. Ул аклар ягында йөргәндә, Суфия тәтәм Кариев труппасында уйный башлады. Шуның өчен Тинчуринны обкомга чакыртып бик каты пешерделәр:

– Үзеңнең дворян кызына өйләнүең җитмәгән, монда буржуйларны гаиләләре белән җыеп ятасың! – дигәннәр.

Тинчурин әйткән:



*Театр артистлары. Уртада – Галия Кайбицкая*

– Минем эшем сезгә ошамаса, чыгарыгыз мине эшемнән, үзегезгә ошаган кешене куегыз театрга! – дигән.

...Унсигез ел буена арабызда «яратам, сөям, гашыйк, мәхәббәт» кебек сүз булмады. Безнең ул сүзләр табу* иде. Башка сүзләр аша әйтелә иде ул мәгънәләр. Ул гастрольдәнме, репетицияләрдәнме арып кайта да, ишекне кергәч тә борыска сөяләп, миңа карап:

– Өй рәхәт! – ди иде.

Бу аның «Заһидә, мин сине яратам» дигән сүзе иде. Шулай да гастрольдән бер хат язды бу: *«Сөеклем Заһидә!»* – дип башлана иде ул хат. Шуннан соң мин «сөеклем» сүзен тикшерә башладым. «Сөекле» – ул сөйгән кеше. Ә «м» китереп кушсаң, «минем сөйгән кешем» килеп чыга. Димәк, Кәрим мине сөя, дидем. Ә мин аны сөяммме соң? Сөям, ләкин үземчә, башкача. Кәрим бик яхшы ир, дус иде. Бәхәсләрдә бик сабыр булды. Ул мине иркәли иде. Миңа бик миһербанлы булды. Кәримгә уңай булсын дип тырыша идем. Аның үз дөньясы барын да аңлый идем. Шуңа күрә мин иремә комачауламаска тырыштым.

– Кәрим сиңа утыз ике яшендә генә өйләнде, сиңа кадәр аның кемнәре генә булмагандыр, нигә син аның узганнары турында сораштырмыйсың? – дип теңкәмә тиеп бетәләр иде танышларым.

Юк, сораштырмадым, кызыксынмадым, иремнең миңа кадәр булганнары мине һич тә кызыксындырмый иде.

---

* Табу – ярамаган, хәрам.

*24.06.1987.*

– Заһидә апа, Кәрим абыйның үтерелгән вакыты кырык җиденче ел түгел, дисез. Дөресен белер өчен, юбилее алдыннан гариза язый КГБга. «В правление Союза писателей ТАССР, в комиссию по проведению столетия К. Тенчурина от вдовы его Захиды Тенчуриной заявление. Есть все основания сомневаться о неверности даты смерти К.Тенчурина в 1947 году. Нет никакой логики в том, что за десять лет мой муж не смог и не хотел дать весточку о том, что жив. Живой свидетель Нугуманов Лукман Нугуманович, воочию увидевший список растрелянных в 1938 году, передал мне, что в списке стояло имя К.Тенчурина. В связи с вышизложенным и столетием К.Тенчурина, прошу провести исследование по установлению точной даты смерти мужа и места захоронения. Подпись – З.Тенчурина. 24. 06. 1987».



*Кәрим Тинчуринның соңгы фотосы. 1937*

*Кәрим Тинчуринның вафаты турында КГБ биргән ялган таныклык. 1956*



РСФСР

ҮЛҮ ТУРЫНДА ТАНЫКЛЫК
СВИДЕТЕЛЬСТВО О СМЕРТИ

І-НШ № 000742

* * *

Озакламый КГБдан Кәрим Тинчуринның 1938 елда атып үтерелгәнлеге турында белешмә килде.

* * *

*Кәрим Тинчуринның 25 еллык иҗатына багышланган тантаналы кичәдә сөйләгән сүзенең кульязмасы, ул татарча латин хәрефләре белән язылган.*

Кешелек дөньясының иң акыллы, иң алдынгы кешеләре гасырлар буенча йөрәкләрендә асраган, безнең илебездә тормышка ашырылган, Ленин-Сталин партиясе җитәкчелек иткән социалистик төзелешнең, социалистик системаның хезмәт иярәренә чын бәһа биреп, кадер күрсәткәнен без һәр көн, һәр сәгать тормыш практикасында күреп торабыз.

Менә шуның өчен дә бездә яшь пионерлардан башлап, ак сакаллы



*«Хикмәтле доклад» спектакленең беренче күрсәтелешеннән соң (режиссеры – Рабит Батулла). Уртада – Заһидә Тинчурина. 1986*

картларга хәтле социалистик Ватаныбыз өчен нинди генә булса да берәр файда күрсәтергә омтылыш көннән-көн үсә, көннән-көн көчәя бара.

Партия, хөкүмәт, совет җәмәгатьчелеге тарафыннан кечкенә генә хезмәтләргә дә игътибар бирелеп, аларны зурлап тәкъдир итүләр фәкать безнең социалистик илебездә генә мөмкин булган хәлләр.

Хезмәт ияләренең кадерләрен иң югары дәрәҗәләргә күтәргән Сталин эпохасының зурлыгы да шушында.

Мисаллар өчен ерак барасы юк.

Мәсәлән, минем төсле гади бер язучыга партия, хөкүмәт, совет җәмәгатьчелеге тарафыннан күрсәтелгән хөрмәтне, кадерне үткән заманнарда һәм хәзерге капиталистик илләрнең кайсысында булуы мөмкин? Капиталистик шартларда мин егерме биш ел түгел, йөз егерме биш ел эшләсәм дә, бу кадернең йөздән бер өлеше хәтлесен дә күрә алмас идем.

Минем бу сүзләремнең дөреслеген исемнәре бөтен дөньяга билгеле булган, капиталистик илләрдә яшәүче язучыларның бу көнге кызганыч хәлләре ачык күрсәтәләр.

Бу көнге бәйрәм, бу көнге тантана гәрчә миңа багышланган булса да, ул бөтен татар совет язучыларының, бөтен татар матур сәнгать эшчеләренең бәйрәме. Ул – Ленин-Сталин милли политикасының җиңүен күрсәткән бик күп фактларның берсе.

Ул – совет культурасының үзенчәлеген тормышта күрсәткән хәлләрнең берсе.

Ул уңышларга ирешүдә без Коммунистлар партиясенә, Советлар хөкүмәтенә,

Советлар иленең революцион хезмәт ияләренә һәм сөекле җитәкчебез бөек Сталинга бурычлыбыз.

Минем төсле октябрьгә милли демократчылык сукмаклары белән килүче вак буржуа интеллигенциясенә карата Ленин Өченче Советлар съездында болай дигән иде: «Раньше весь человеческий ум, весь его гений творил только для того, чтобы дать одним все блага техники и культуры, а другим лишь самого необходимого просвещения и развития.

Теперь же все чудеса техники, все завоевания культуры станут общенародным достоянием. И отныне никогда человеческий ум и гений не будут обращены в средства эксплуатации. Мы это знаем. И разве во имя этой величайшей исторической задачи не стоит работать, не стоит отдать всех сил?

И трудящиеся совершат эту титаническую историческую работу, ибо в них заложены дремлющие великие силы революции, возрождения и обновления».

Моннан унсигез ел элек әйтелгән бу гениаль фикерләрнең нәтиҗәләрен без хәзер тормышта күреп торабыз.

Мин үземне Ленин-Сталин партиясенең партиясез шәкерте дип саныйм. Дөресен әйткәндә, аның ярдәме аркылы гына мин чын иҗат юлына якынлаштым.

Мин, Советлар власте урнашканнан башлап, татар совет әдәбияты, татар совет матур сәнгате өлкәләрендә өзлексез эшләп килдем. Шул үткән ел эчендә чын иҗат юлымны таптым. Партия тарафыннан миңа һәрвакыт ярдәм, самими булышлык булып торды. ЦКның 23 апрель, 1932 ел карарыннан соң иҗатым өчен юллар тагын да киңәеп киттеләр.

Алда сөйләнгәннәрдән нәтиҗә ясап, шуны әйтмәкче булам: безгә матур, күңелле тормыш биргән, безнең иҗатларыбыз өчен иң яхшы шартлар тудырган безнең социалистик Ватаныбыз бар. Шул кадерле Ватаныбыз алдында торган бөек идеяләр өчен көрәшү һәрбер намуслы хезмәт иясе, һәрбер совет язучысы алдында мактаулы зур бурыч булып тора.

Бөтен дөнья хезмәт ияләре бәхете өчен көрәшүче, безне сыйныфсыз җәмгыяткә алып баручы Ленин-Сталин партиясенең юлы — безнең дә бердәнбер ышанган юлыбыз. Кешелек дөньясына хезмәт итәр өчен дә, чын художество әсәрләре тудыру өчен дә башка юллар, башка сукмаклар, башка күперләр юк!

Минем кечкенә хезмәтләремне зур итеп тәкъдир итүче Татарстан өлкә партия комитетына һәм аның секретаре, совет матур әдәбиятының дусты, җитәкчебез иптәш Лепага рәхмәт!



*Төрмә ишегалды*

Татарстан хөкүмәтенә, аның башлыгы һәм бүгенге тантананың башлыгы иптәш Байчуринга рәхмәт!

Татарстан совет язучылары союзына, бу тантанага катнашкан барлык учреждениеләргә һәм мондагы бөтен иптәшләргә рәхмәт!

Безгә матур, күңелле тормыш китерүче, безне капитализм богауларыннан коткаручы, моңарчы җир йөзендә күренмәгән яңа социалистик культура тудыручы сөекле остазыбыз, даһи Сталинга рәхмәт!..

* * *

Кичәне олылап, бик бай итеп уздыралар, шул кичәдән соң (октябрь, 1937) Кәрим Тинчуринны кулга алалар. Аннан соң өлкә комитеты секретарьлары Лепаны да, Байчуринны да кулга алалар. Аларның барысы да зинданда һәлак була.





# ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАН

**Кәрим Тинчурин истәлегенә**

Бәллүр кыңгырау күк чылтырап тора
Шушы исем – Кәрим Тинчурин...
Хәтерләтеп милли сәхнәбезнең
Көмеш көзгеләргә тиң чорын.

Борылып карап узган гомерләргә,
Эх җегетләр, димен, әй кызлар...
Без түгелме гасыр чатларында –
Җилкәнсезләр, сүнгән йолдызлар?..

Юк, без исән әле... Сүнмәбез дә
Каләм белән сәхнә барында.
Кара урман саклар халык җанын,
Күчен-моңын саклар – барын да...

Тере җилләр ул җыр-хәбәрләрне
Һәр ягына сибәр дөньяның.
Безнең күңелләрдә гомер бакый
Ул җилләрнең юк та тынганы...

Шул җилләрдә җилфер-җилфер килә
Зәңгәр шәле, Казан сөлгесе...
Тәгәрмәч күк хәрәкәттә сәхнә –
Милләтемнең яшәү билгесе.

...Исемеңне сәхнә пәрдәсенә
Чигеп куям, Кәрим Тинчурин! –
Хәтерләтеп торсын Театрның
Шомлы чынбарлыкка тиң чорын...

*Май. 2002*





# ГҮЯ БЕРЧАК
# СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАРЫН
# СҮНМӘС ИТЕП КАБАТ КАБЫЗГАН...



# СӘЕТ ШӘКҮРОВ

**Үз йортына кайтарасы иде**

Заманында Тинчуринның үзен йорт-җиреннән, иленнән-халкыннан аерганнар иде. Кайтты бит! «Зәңгәр шәл»ләрен, «Казан сөлгесе»н җилкән итеп иленә, халкына әйләнеп кайтты. Хәзер Казанның бер урамы Тинчурин исемен йөртә. Республика драма һәм комедия театрына Кәрим Тинчурин исеме бирелде. Бу олы исемне йөрткән театрның җисеме дә шуңа лаек булыр дип ышанырга кирәк. Аның ярты гасырдан артып киткән катлаулы иҗат юлы бар.

Театр 1933 елны, әлбәттә, Тинчуринның фатихасы белән, Татар дәүләт академия театрының колхоз филиалы булып оешкан иде. Ул аның канаты астында рухланып, аннан даими ярдәм алып, аның белән шул бер үк «изге» бинада 1938 елга кадәр яшәде.



*Театр ишеге янында. Алгы рәттә уңнан беренче – артист Каюм Бариев, икенче – Кәрим Тинчурин. К.Тинчурин эшләгән рәсем*

*Театр бинасы. 30 нчы еллар*



Филиалның башлангыч чорын Гөлсем Камская, Мәҗит Илдар, Бәкер Юсупов, Габдулла Уральский I кебек татар театр сәнгатенең сүнмәс җәүһәрләре бизәде. Алар үзләренең гүзәл иҗатлары белән шул чор авыл халкын – тәүге колхозчыларны таң калдыралар иде. Филиал коллективы шул еллар дәвамында татар театр техникумын тәмамлап чыккан яшь кадрлар белән дә даими тулыландырыла торды. Без дә (хәзер РСФСРның халык артисткасы Вера Минкина, Галиәсгар Камалның уртанчы улы Фаикъ Камал һәм мин), театр техникумын тәмамлап, киләчәккә зур өметләр баглап, нәкъ менә шушы коллективка килеп кергән идек. Ләкин бу «изге» бинада эшләү бәхетебез кыска гомерле булды.

1937–1938 еллар шаукымы татар театр сәнгатенә дә зур күсәк белән китереп сукты. Беренче нәүбәттә Кәрим Тинчурин, Мохтар Мутин кебек титаннарга, режиссер Гали Ильясов һәм башка сәнгать әһелләренә «халык дошманы» дигән ялган бәла тагып репрессия-



*Кәрим Тинчурин сәхнә эшчеләре белән. 30 нчы еллар*

ләделәр. Академия театрының шул чордагы баш режиссерын, талантлы педагог Гомәр Исмәгыйлевне дә Казаннан кудылар. Татар театр сәнгатенә Хәким Сәлимҗанов, Галия Булатова, Габдулла Сәгыйтов кебек олы талантларны биргән бердәнбер татар театр техникумын да яптылар. Казан эшче театрын һәм аннан соң филиалны да бетерделәр. Барыннан да бигрәк шунысы гаҗәп, имеш, боларны «халык дошманнары» эшләгәннәр. Имеш, алар әле моның белән генә тукталып калмыйча, академия театрын фәкать 16 кешелек труппага гына калдыру максатын куйганнар. Менә бит ничек: Тинчуриннар үзләре төзегән театрны, имеш, үзләре үк «җимерергә» керешкәннәр. «Ак эт бәласен кара эткә тагып», заманында безне шул коточкыч ялганга ышандырырга тырыштылар. Ләкин моңа берәү дә ышанмады. Филиал коллективы да бетмәде. Аның белән җитәкчелекне талантлы режиссер Әсгать Мәҗитов үз өстенә алып, аны 6 нчы номерлы колхоз-совхоз театры исеме астында Казаннан республиканың бер читенә – Балтачка күчереп куйды. Шулай итеп, коллектив академия театрының җылы куенынан, үзе туган изге бинадан аерылып китәргә мәҗбүр булды. Ләкин аның иҗат дәрте сүнмәде. Эш шартларының авыр булуына карамастан, ул шул чорда М.Әблиевнең «Шәмсекамәр», Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Билль-Белоцерковскийның «Чик сакчылары» кебек зур күләмле әсәрләрен әзерләп, ат-арба, хәтта үгез чаналарына төялеп, шул төбәк колхозларына культура хезмәте күрсәтеп йөрүен дәвам итте. Авыр иде, ләкин күңелле иде, кызык иде ул чорда эшләү. Җәйләрен ат сарайларында, улаклар өстенә такталар тезеп, сәхнә ясый идек. Кыш көннәрендә керосин лампалары белән яктыртылган мәктәп коридорлары, мәчет мөнбәрләре була иде безнең сәхнәбез.

Шулай итеп, бу «романтик» чор да бик тиз узып китте. Без – яшьләрне берәмберәм армиягә алдылар. Аннан сугыш башланды. Ир заты бөтенләе белән дип әйтерлек сугышка китеп бетте. Ләкин театр таралмады. Хатын-кызларга сакал-

мыеклар ябыштырып, Әсгать Мәҗитов театрны саклап кала. Сугышның буеннан-буена театр, авылдан авылга йөреп, авыл халкының рухын күтәрү, җиңү көнен якынайту өчен бар көчен биреп эшли һәм, ниһаять, сугыш бетәр алдыннан гына коллектив, Республика Күчмә театры дигән исем алып, Казанга кайта. Әсгать Мәҗитов үзе вафат була, театр җитәкчелеге сугыштан яраланып кайткан режиссер Габдулла Юсуповка тапшырыла. Бу вакытта театр дигән күптармаклы катлаулы организм элеккеге «Болгар» номерларының уч төбе кадәр генә булган бер бүлмәсенә урнашкан иде. Шул чордан алып бүгенге көнгә кадәр театрның адәм рәтле бер урыны – бинасы булмады.

Ниһаять, быел гына Республика аптекалар идарәсенең склад-базасын ремонтлап, берникадәр театрга яраштырып бирделәр. Ләкин бу бина Кәрим Тинчурин исемен йөрткән театрны канәгатьләндерә алмый. Аның югарыда күгәрчен оясы кебек кенә 95 урынлык бер кечкенә залы һәм уч төбе кадәр генә сәхнәсе бар. Бу бина театр училищесының «учебный театры», йә булмаса мәскәүлеләр үрнәгендә барлыкка килгән кооператив арт-клублар өчен менә дигән бина булыр иде. Казанда хәзер берничә арт-клуб оешты һәм ул тармакны җанландырып җибәрү – заман таләбе. Ә Тинчурин театрын үзенең туган йортына кайтарырга кирәк.

Ярты гасырдан артык тәгәрмәч өстендә җәфа чигеп яшәгән коллектив, бер иркен сулап, стационар шартларда эшләү хокукын яулады шикелле. Аның менә дигән талантлы актерлар труппасы бар. Тинчуринның гаҗәеп бай архивы сакланып калган. Кәрим Тинчурин исемендәге театр бинасында Тинчурин музеен ачып җибәрергә дә мөмкин булыр иде.


Татарстан башкаласында ике татар театрының параллель эшләве халкыбызның горурлыгы, милли культурабызның илкүләм дәрәҗәсен билгеләүче фактор булып торачак. Инде килеп, татар театрына рус тамашачысының йөрүен дә онытмаска кирәк. Шәһәребездә татар телен өйрәнергә теләүче руслар өчен курслар ачыла башлады. Татар телен үзләштерүне театр икеләтә җиңеләйтәчәк бит. Килер бер көн, күрше күршесеннән сорар:

– Сез бүген кич кая барасыз? – дияр.

– Галиәсгар Камал театрына.

– Ә без Кәрим Тинчурин театрына барабыз, – дияр күршесе. Дөрес, бу әлегә хыял гына. Ләкин бит без хыял тормышка аша торган, үзгәртеп кору чорында яшибез.

*«Социалистик Татарстан».*
*18 октябрь, 1988*



*К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы*



# МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВ

*(Журналист Гүзәл Камал белән әңгәмә)*

**«Зәңгәр шәл» сере**

– Марсель Хәкимович, Сезнеңчә «Зәңгәр шәл»нең сере нидә?

– Халык мәхәббәтен казанган бу үлемсез әсәр хакында бәхәсләр күп булды инде.

Кәрим Тинчурин аны 1926 елда яза һәм шул ук елның көзендә сәхнәләштерә дә. Төп рольләрне беренче башкаручылар Зәйни Солтанов (Ишан), Рокыя Кушловская (Мәйсәрә) һәм Кәрим Тинчурин (Булат) үзе була. Спектакль шундый зур уңыш казана ки, аның даны бүтән төбәкләргә дә таралып, Троицк, Оренбург, Әстерхан һәм башка театрлардан килеп караучылар актерларның репликаларын язып алып, үз сәхнәләренә күчерәләр. Пьеса шаулап-гөрләп, тамашачыны сокландырып, милли җирлеге белән күңелләргә хуш килеп, татарлар яшәгән бөтен якларда уйнала. Ә Салих Сәйдәшевнең нечкә лирик вә нәзакәтле музыкасы ямь өстенә ямь биреп, спектакльне тагын да тулыландыра, зур уңыштан канатланган композитор яңа көйләр, арияләр яза. Татар җанының иң нечкә кылларын тибрәткән асыл пьеса – «Зәңгәр шәл» сәхнәләрдән төшми һаман уйналыр иде дә бит – аның авторын сәер рәвештә кулга алалар. Зур талант иясе иҗат иткән рольләр, әсәрләр, спектакльләр хакында 19 ел буе беркем бер сүз дәшәргә кыймый. Тик шулай да аның исеме халык хәтерендә җуелмаслык булып калган икән. 1956 елда, Кәрим Тинчурин акланганнан соң, аның «Зәңгәр шәл»е яңадан сәхнәгә менә. (Режиссеры Ш.Сарымсаков.) Театр өчен күңелсез еллар иде бу. Тамашачы спектакльләргә йөрми торган чак. Спек-




*«Зәңгәр шәл» спектакленең афишасы. 1926*



*Г.Камал исемендәге театр.*
*«Зәңгәр шәл» спектакленнән күренеш: Ишан – Шәүкәт Биктимеров, Мәйсәрә – Флера Хәмитова*

такль элеккеге декорацияләр, иске, әзер костюмнар белән унбиш көн эчендә генә әзерләнә.

Һәм менә театр тормышында гадәттән тыш хәл – тамашачы «Зәңгәр шәл»гә агылып йөри башлый. Югыйсә халыкта июнь аенда театр кайгысы булырга тиеш түгел бит?! Моңа мин үзем шаһит – спектакль ай буе алкышлар белән барды, зал шыгрым тулы иде. Шунысы гына аяныч, Салих Сәйдәшев бу әсәрнең терелүен, шундый уңышка ирешүен күрә алмыйча, ике ел алдан вафат булды.

Театр 1957 елда Мәскәүдә үтәчәк Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерләнә. Декадага алып барырга уйламаган да спектакльне, ягъни «Зәңгәр шәл»не, очраклы рәвештә генә Мәскәү тәнкыйтьчеләре күреп ала. Яратып кабул итәләр. Спектакль өчен яңа декорацияләр ясала. Киемнәр тегелә, «Зәңгәр шәл» Мәскәүгә бара һәм башкаланы яулап кайта. Бу бик табигый. Гәрчә без әле «Зәңгәр шәл»нең серенә төшенеп җитмәсәк тә.

– Моны ничек аңларга?

– Бу пьесаның серен, тылсымын театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр дә аңлый алмыйлар. Әсәр бернинди сәхнә кысаларына сыймый, классик кануннарга буйсынмый. Ул төп-төгәл эшләнгән, үзара нык бәйләнмәгән өлеш-күренешләрдән тора. Кайсы күренешне уйнасаң да – үзенә күрә бер пьеса. Элек артистлар аны шулай – берәр-берәр күренеш уйнаганнар да. Ә «Кара урман» күренешен, актер Шакир Шамильский уенына таң калып, автор соңыннан яза. Ә шулай да бу әсәр гаҗәеп тылсымга ия.

– Аның тылсымы Сезне дә гел үзенә тартып торадыр?

– 1970 елда Ш.Сарымсаков тарафыннан К.Тинчурин постановкасы буенча куелган спектакльнең искерүен сизеп, мин аны яңартырга, яңа сулыш өрергә, җанландырырга уйладым. Яңа башкаручылар керттем. Мәйсәрәне Флера Хәмитова, Булатны башта Азат Аббасов, Мәсгут Имашев, соңыннан Наил Әюпов башкардылар. Ишанны, гадәттә, карт кеше итеп күрсәтәләр иде. Ә мин янып торган Шәүкәт Биктимеровны керттем, югыйсә ни өчен соң аңа бишенче хатын кирәк булыр иде?! Спектакль бизәлеше эшләгән М.Сутюшев алдына да яңа бу-



*Г.Камал исемендәге театр.*
*«Зәңгәр шәл» спектакленнән күренеш: Ишан — Шәүкәт Биктимеров, Галәви — Һидаят Солтанов*

рычлар куйдым. Декорацияләр җыйнак һәм җәһәт үзгәртелә торган булсын, дидем. Тамашачы бу спектакльне 12 ел буе карап хозурланды. Ләкин һәрбер спектакль кеше кебек үк туа, җитлегә, картая. Берзаман спектакльнең формасы кала, ә «кан тибрәлеше» югала. «Зәңгәр шәл»не яңа бинабызга күчкәч, шәрык миниатюралары рәвешендә яңадан куйдым. Тагын ун ел уйналды. Үзебезнең яшәешебез турындагы бай, тирән эчтәлекле иң милли әсәр ул. Юкка гына без күп гастрольләребезне шул спектакль белән ачмыйбыз бит. Чит мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребез аның милли аһәңенә бигрәк тә сизгер. С.Сәйдәшев музыкасы күңелне җилкендерә торган дәртле дә, гаҗәеп моңлы да. Авыл Сабан туе барыбызга да газиз, ә көйләр ирексездән сагышландыра, туган туфрагыбызга, кавемебезгә тартылуны көчәйтә, үзең дә сизмәстән татар дулкынына көйләнәсең, милли хәтеребезне, татарлыгыбызны уята ул безнең. Баш бирмәү — буйсынмау, ирекккә омтылу безнең каныбызга сеңгән. Җор теллелек, сүзгә тапкырлык, җырбиюгә һәвәслек тә бабаларыбыздан килә. «Зәңгәр шәл» безнең яшәү рәвешебезне күрсәтә, яшеренеп, тирәндә яткан хис-тойгыларыбызны уята. Татар рухын калкытып чыгара — монда ирекккә омтылу да Сабан туе лейтмотивы белән бирелә. Фаҗигале-көенечле, кызыклы-сөенечле мизгелләр нәкъ тормыштагыча гел алмашынып тора. Шуңа күрә дә бик якындыр ул безгә — безнең ничәмә-ничә буын тамашачы яратып карый торган «Зәңгәр шәл»! Халык үзе хаким бит! Әгәр дә гасыр буена аны тамашачы карап туймый икән — спектакльгә иң югары бәя шул бит инде! 1980 елда, Мәскәүдә гастрольдә чакта, «Зәңгәр шәл»не Колумбия илчесе карап шаккатты. «Минем халкым хакында икән бит бу спектакль!» — диде. Минемчә, чын милли әсәр генә башка милләтләр өчен дә якын, үз була ала!

— Кайбер күренешләрне, әйтик, Ишанның халыктан садака җыюын төшереп калдыргансыз. Динне мыскыллау дип, спектакльгә йодрык селкүчеләр дә аз булмады бугай.

— Дин җанны, рухны чистарта, мин дингә каршы түгел. Әмма «Зәңгәр шәл»дәге Ишан кебек дин әһелләре дә булган.

– Марсель Хәкимович, Сез «Зәңгәр шәл»не өченче тапкыр сәхнәләштердегез. Бу юлы куелган спектакльнең тамашачыга әйтергә теләгән фикере нинди?

– Вакытлар узу белән кешеләрнең зәвыгы, дөньяны күзаллавы, эстетикасы да үзгәрә. Ярты гасыр элек уйналган, дан-шөһрәт казанган спектакльләр, әлбәттә, яхшы булган. Әмма шул заман өчен яхшы! Бүгенге тамашачы, бигрәк тә яшьләр, шоу-мюзикл жанрын яратып өлгерде. Бу спектакльдә дә шуның алымнары нык сизелә. Шартлы бизәлеш, заманча пластика теленә күчү, ирония, урмандагы манзаралар уйландырырга тиеш. Татар рухын күтәрүче әсәр – «Зәңгәр шәл»не мин мелодрама итеп түгел, музыкаль, фаҗигале, халык драмасы итеп куйдым. Заманалар үзгәрсә дә, ирекка омтылу, гади халыкны кысу-изүгә нәфрәт һаман да актуаль. Безнең халык сабыр, түзә. Әмма азатлыкка, ирекка омтылу да җанында аның. «Кара урман шаулый, ирек даулый», – дип, юкка җырламый бит Булат. «Зәңгәр шәл» татарны яшәтүче көч бит ул.


*«Сөембикә». Апрель, 2000*

*Кәрим Тинчуринның язу әсбаплары һәм китаплары*



# МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ

## Ул кабызган утлар



Тинчуриныбыз бар иде...

Кадерен белеп искә алу, мирасын хөрмәт итү, таланты алдында баш ию гадәт булып китсен иде. Тинчуриныбыз – мәдрәсәдән революциягә, аннан сәхнәгә аяк басып кулына каләм алган культура эшлеклебез, эрудицияле артистыбыз, драматургыбыз иде...

Тинчуринның мирасы һәм намуслы иseme безгә әйләнеп кайтты. Аның барлыгын, Татар академия театрында бөтен бер Тинчурин чоры, Тинчурин мәктәбе булганлыгын без, яшьләр, интуиция буенча сизә идек. Безнең буын авыл сәхнәләрендә «Зәңгәр шәл» һәм «Кандыр буе»н куйган кешеләр арасында тәрбияләнеп үсте. «Кандыр буе»ның көен:

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә... –

дип җырлыйлар иде. Әле кырыгынчы елларда гына, мәктәп коридорында шыңшып узган укытучылардан ишеткән бар иде:

Дусларым, сагынып кайттым...
Дусларым, ерак илләрдән...

Моның нәрсә икәнен белми идек, ләкин ниндидер сихри-лирик интонация безне әсир итә иде.

– Ни өчен «Зәңгәр шәл»не куймыйбыз?

Скрипкада уйнаучы ак чәчле укытучы елмаеп:

– Килер вакыт, куярлар, – диде. Аннан көрсенеп: – Их, Булатны уйнаган заманнар бар иде, – дип, скрипкасын сызып җибәрде.

Шулай, Кәрим Тинчурин дәшми генә безнең күңелләрдә яшәп килде. Безнең хыялларда Тинчурин күләгәсе яшәп килде. Шагыйрьнең күңеле күбәләк кебек (мин бу урында Тинчуринны шагыйрь дип атыйм – пьесаларындагы барлык җырларны аерым туплап китап итеп чыгарсаң, «шагыйрь Тинчурин» дигән исемне алырга ул, һичшиксез, лаек булыр иде).

Еллар узды, Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен күрү бәхетенә ирештек. Закир Һади, Габдулла Тукай башлаган эш – татар тормышындагы феодализм калдыгы – ишанчылыкны тәнкыйть итү мәсьәләсе К.Тинчурин тарафыннан сәхнәгә китерелде. Хезмәт халкының җор күңеле, крестьян яшьләренең саф әхлакый сыйфатлары Тинчурин тарафыннан сәхнәдә сурәтләнде. Бер талант яхшы, ике талант бергә эшләсә, алар инде шедевр тудыра. Тинчуринның танылган композитор С.Сәйдәшев белән бергә эшләве һич тә очраклы түгел иде. Әнә шулай бер-бер артлы татар совет әдәбиятының классик әсәрләре дөньяга килде.



*«Кандыр буе» спектакленнән күренеш. Кәрим Тинчурин төшергән рәсем*

«Кандыр буе»ның ничек язылуын Арча районы Казанбаш авылы халкы әле дә искә алып сөйли. «Кызыл Казанбаш» Татарстанда иң беренче колхозларның берсе булган, анда башта коммуна да төзеп караганнар. Тинчурин белән Сәйдәшев бергә әнә шул авылда җәй уздырганнар һәм, Казанбаш халкының ышанып сөйләвенчә, «Кандыр буе» пьесасындагы күп персонажлар Казанбашта әле дә яшиләр икән...

Тинчуринның халыкчан иҗаты Советлар Союзында шулкадәр киң таралган – һәр драматургның әсәре шулай Казаннан алып Байкалгача тарала алса иде... Казан университеты студентлары белән фәнни экспедициядә йөргәндә, Себер татарлары безне күп мәртәбәләр адаштырдылар. Без алардан халык иҗаты әсәрләре өмет итәбез, ә алар безгә Тинчурин җырларын яздыралар икән. Шулай, Томск өлкәсе Кызылкаш авылында бер карттан тырышып-тырышып җыр язабыз. Кулда дәфтәр-карандаш, картның янында шыпырт кына портатив магнитофон әйләнә. Җырның сүзләренә, аһәңенә гаҗәпкә калабыз.

Тамбур инәләре көмеш саплы,
Немец илләреннән алынган...

Казанга кайткач тикшереп карасак – бу җыр Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ыннан икән. Хәер, бу җыр Горький, Рязань якларында йөрүче фольклорчыларны да шактый күп мәртәбә адаштырган һәм халык иҗаты китапларына кабат кергән...

Татар мәдрәсәләрендәге шәкертләр хәрәкәтен бары тик Г.Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы буенча гына белә идек. Тинчуринның «Мәрҗәннәр»ендә бу хәрәкәт шәкертләрнең урам сугышларында катнашуы, полициягә, патшаның кораллы көчләренә каршы сугышулары искиткеч җанлы картиналар аша бирелгән. Әйе, бишенче ел революциясе меңләгән татар шәкертләрен үз дулкыннары эченә алды, аларның күзләрен ачты. К.Тинчурин әнә шул меңләгән шәкертләрнең берсе иде һәм бишенче ел революциясе белән күзе ачылган егет шул юл белән халыкка хезмәт итүгә килде. «Мәрҗәннәр»дәге төп герой Сөләйман, кат-

лаулы, каршылыклы юлларны узып, революция ягына чыга. Ихтимал, Сөләйман язучы Тинчуринның үз прототибыдыр. К.Тинчуринның хикәяләрендә революциягә кадәрге татар шәкерте үткән авыр юл төп сызык булып бара.

«Мәрҗәннәр» – К.Тинчуринның язылып бетмәгән әсәреннән бер өзек. Тинчурин дөньядан иртә китте, аның язасы хикәяләре, повестьлары, драма, комедияләре әле күп иде. Ә калдырган мирасы белән ул татар культурасы тарихында иң мактаулы кеше булырга лаек. Татар совет әдәбиятында, татар театрында Тинчурин кабызган утлар беркайчан да сүнмәс...

...Тинчуриныбыз бар иде.

Кадерен белеп искә алу, мирасын хөрмәт итү, таланты алдында баш ию гадәт булып китсен иде...

*«Социалистик Татарстан».*
*3 сентябрь, 1967*



*Артист Үзбәк – Кәрим Тинчурин. 1914*

*«Кандыр буе» әсәрен язарга мәгълүмат туплау җәе. Сулдан уңга: Кәрим Тинчурин, Сәлих Сәйдәшев, төбәк мәркәзе (?) башлыгы. 1931*



# ТУФАН МИҢНУЛЛИН



## Остаз

1887 елда беренче татар пьесасы язылып, Казанда нәшер ителә. Шул ук елны Пенза ягындагы Таракан дигән авылда (хәзерге исеме – Белоозерка) татар драматургиясенең классигы, күренекле артист һәм режиссер Кәрим Гали улы Тинчурин дөньяга килә. Бу, әлбәттә, очраклы тәңгәллек. Әмма ул елларда туганнарның татар мәдәни тормышын тергезеп җибәреп, аны өр-яңа биеклеккә күтәргәннәрен искә алсак, монда инде очраклылык юк.

1905 ел революциясе изелгән, кимсетелгән халыкларга иркенрәк сулыш алып, иелгән башларын күтәребрәк, тирә-як мохиткә күз салырга, уйланырга һәм үз хакларын дауларга ирек бирде. Менә шунда инде татар халкының ничәмә-ничә йөз еллар буе томаланып торган иҗат чишмәсе җир өстенә бәреп чыкты. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Габдулла Кариев, Җамал Вәлиди... Бу затлы исемнәр арасында, һичшиксез, Кәрим Тинчуринның да үз урыны бар.

1910 елда язмышын татар театры белән бәйләп, гомеренең соңгы көненә каклы ул шуңа тугрылыклы хезмәт итте. Бай әдәби мирас: егермедән артык драма әсәре, күпсанлы хикәяләр калдырды.



100 ел эчендә татар драматургиясенең хәзинә сандыгына йөзәрләп санарлык әсәрләр өстәлде. Аларның инде байтагы заман сынавын үтә алмыйча онытылган. Кәрим Тинчуринның драма, комедияләре исә, берничә дистә ел элек иҗат ителүләренә карамастан, һаман да сәхнәләребезнең түрендә.

Хикмәт нәрсәдә?

Әдәби тәнкыйть телендә «халыкчанлык» дигән термин бар. Без аны кирәкмәгән чакларда урынсызрак кулланып, бераз таушалттык шикелле, мәгънәсен тарайта төштек, халыкчанлыкны теге яки бу әсәрнең теленә генә кайтарып калдырдык.

Кәрим Тинчурин исә халыкчан булам дип көчәнми, халыкка хезмәт итәм дигән булып, аңа акыл өйрәтергә алынмый, халык алдында ясанмый. Елый икән, чын күңеленнән елый, елмайганда – эчкерсез елмая, көлә икән, әрнүеннән әче итеп көлә. Кешеләр

*Нәкый Исәнбәт*

аны шуңа күрә аңлыйлар: кушылып елыйлар, көләләр, әче итеп көлгәненә үпкәләмиләр.

Карагыз инде ул «Зәңгәр шәл»гә. Кемнәребез генә юк анда безнең. Барысы да үзебезнекеләр. Мәйсәрә, Булат, Заһирә, Шәйхи бабайны әйтмим дә инде, рус Мишка белән чуаш Пәтрәй дә үзебезнеке. Без алар белән бергә гомер кичердек һәм кичерәчәкбез. Хәтта ат карагы Миңлегали белән ялган акча ясаучы Тимуш та безнеке. Булган бит. Ярата да белгәнбез һәм беләбез, кулга корал алып хаклык даулаганда да бүтәннәр белән рәттән торабыз, бәхет эзләп дөньясын гизеп йөрдек һәм йөрибез. Әлбәттә, без ат урлаучылар белән горурланмыйбыз, алар өчен борчылабыз, әмма булгач – нишләтәсең? Халык үзенең ир-егетләрен дә, сукбайларын да бик яхшы таный һәм дөрес бәяли. Шуңа күрә «Зәңгәр шәл»не халык үзенеке итеп саный. Үзенеке итеп санаганны беркайчан да онытмый.

Берара «Казан сөлгесе» тирәсендә бәхәс булып алды. Әсәрнең үзенә дә тел тидереп алгаладылар. Янәсе, Тинчурин безнең муллаларыбыздан көлеп, тарихи дөреслекне ялгыш итеп күрсәткән. Әйе, көлә драматург. Муллалар, ишаннар, аларның хатыннарыннан да көлә. «Американ» комедиясендә зыялыларыбыздан көлә. Әлбәттә, безгә бу авыр тоела, барысын да ал да гөл итеп күрәсебез килә. Һәм тарихыбызга күз салсак, муллалар арасында халыкка мәгърифәт нуры чәчкән, аны укытырга, белемле итәргә тырышып җан фида кылганнары да аз түгел. Әмма ләкин шул алдынгы карашлы муллаларыбызны типкәләгән, һәртөрле прогресска теш-тырнаклары белән каршы торганнары азмы? Бәлеш төбе кимереп, тел астына әфьюн кыстырып, халыкның язмышына төкереп караганнары булмаганмы? Мәрҗани, Каюм Насыйри, Тукай, Әмирхан кебек бөек зыялыларыбыз янында

*Язучылар төркеме. Беренче рәттә сулдан уңга: Кави Нәҗми, дүртенче – Шәриф Камал; икенче рәттә: беренче – Гомәр Гали, өченче – Гомәр Толымбай, дүртенче – Кәрим Тинчурин*



*«Сәйяр» труппасы җитәкчесе*
*Габдулла Кариев*



сафсата сатып, чәйнәшеп йөргән, Тукайларның теңкәсенә тиеп, аларны үлем түшәгенә салган «зыялылар» юкмы? Нигә алардан көлмәскә? Үз җитешсезлекләреннән үзе көлә белгән милләт – зур милләт инде ул.

Кәрим Тинчурин әсәрләренең гомерен озын иткән икенче нәрсә – аларның зур эрудицияле, талантлы оста тарафыннан язылган булулары.

Тинчуринга чаклы драматургиябезгә олы хөрмәт белән карасак та, анда чын әдәбият өчен җитешсезлек булып саналган вәгазьчелек элементлары күбрәк иде. Характерлар бәрелешендә туарга тиешле фикер аерым бер персонаж тарафыннан декларатив рәвештә әйтелә иде. (Ул чир белән чирләгән әсәрләр бүгенге язучыларда да очрый әле.) Тинчурин, драматургия теорияләрен тирәннән белгән язучы буларак, алардан арынды диярлек. Аның геройлары сәхнәдә һәрберсе аерым характер булып, үз тормышлары белән яшәп, үз сүзләрен сөйли. Кайвакытта алар авторның ихтыярына буйсынмый да сыман. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Чынында исә драматург, үз балаларының холкын бик яхшы белгән ана кебек, барысын да күреп, нишләгәннәрен һәм нишләячәкләрен сизеп тора. Ялгыш юлга

керә башласалар гына төзәтеп куя. Мондый сизгерлек, интуиция зур осталарда гына була.

Теманың зарурлыгы турында сөйләнеп, тема мәсьәләсен әдәбиятта беренче планга чыгарып, без, кызганычка каршы, әдәби осталыкны онытып җибәрдек.

Тинчурин комедияләре буенча куелган спектакльләрдә йокы килүдән интегеп утырмыйсың инде. Драматург карап торышка сәхнәгә күтәреп сөйләргә лаек булмаслык вакыйганы да мавыктыргыч итеп сөйләп бирә, исләрең китеп тыңлыйсың һәм карыйсың.

Ә Кәрим Тинчурин әсәрләренең теле!.. Хәер, әсәрләрнең теле дигәндә, мин аны әдәби осталыкка кертмим. Осталыкка өйрәнү нәтиҗәсендә ирешәсең. Телне тою, аңа сизгерлек – табигый талант.

Кәрим Тинчуринны еллар сынавын узарлык художник иткән сыйфатларның берсе – драматургның шәхес буларак бөтенлеге. Ил, халык мәнфәгате өчен көрәш барганда, үз өстенә җаваплылык алырга курыкмаган Тукайлар замандашы буларак, аларның фикердәше дә иде ул. Бүген без театрыбызның уңышлары белән горурланганда, Кариев, Тинчуриннарның хезмәтен ачык күрәбез. Милли культураның үсеш юлларын билгеләгәндә, ныклы позициясе булган шәхесләр һәрвакыт кирәк. Тинчурин – шәхес культы корбаны. Шәхес культының куркынычлылыгы, явызлыгы чын шәхесләрне юлдан алып ташлап, сафларны шәрәләндерүдә булды. Олы шәхесләрнең җитешмәвен, аларга мохтаҗлыкны озак еллар тоеп, сызланып яшәдек без. Менә аларның мирасы кайтты. Һәм алар шундук үз урыннарын алды...

*Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы*





# РАЗИЛ ВӘЛИЕВ

## Чират

Җиңү көне. Мин урамда йөрим,
Уйлап йөрим шигырь язарга.
Рифма эзләп шактый изалангач,
Кагыласы иттем базарга.


Кайный базар, гүя рейхстаг.
Түбәсендә – Җиңү байрагы.
...Ит чабучы, сабыр палач кебек,
Озак итеп балта кайрады.

Чапкан саен башлар оча тора,
Ит чабучы ярсып кизәнә.
Бу базарда сатып булыр кебек
Намусны да салып бизмәнгә.

Һәрнәрсәгә аның үз бәясе,
Исе китми шигырь-мазарга.
Ите – кыйммәт, ә баш – очсызрак...
Баш бәясе арзан базарда.

Кем чираты?
Базар палачының
Күтәрелә канлы балтасы...
Стенадан көлеп карап тора
Халыкларның үги атасы.

*Казан. Иске бистә манзарасы*



Аны күргәч, кинәт ирексездән
Әрнегәндәй булды муеным.
Ит чабучы. Чират. Тәгәри баш.
Ул елмаеп сыйпый мыегын.

Кем чираты?
Дәште салкын аваз,
Авыр аваз, гүя кургашын.
Күрдем кебек базар чиратында
Горур башын Фәтхи Бурнашның.

Кем чираты?
Мыек асларыннан
Саркып чыга зәһәр усаллык.
Диварларны җимермәкче булып,
Башын бәрә Шамил Усманов.

Кем чираты?
Дөньяларның бүген
Сугым базарына тиң чоры.

«Исән булса башлар, кайтырбыз!» – дип
Саубуллаша Кәрим Тинчурин.

Кем чираты?
Бар кешеләр өнсез:
Юк шаярган, көлгән, уфтанган.
Аваз килә: «Мә, партия, мине!» –
Соңгы бүләк аңа Туфаннан.

Кем чираты?
Оча миллион башлар...
Ил атасы гүя котырган...
Кем чираты?
...Күзләремне ачсам,
Базар чиратында мин торам.

Тирә-юньдә кабер салкынлыгы.
Мин ашыгып чыгам базардан.
Урамда – яз. Илдә – Җиңү язы!
Аермасын язмыш язлардан.

*Казан. Зәңгәр мәчет капкасы*



# РАУЗА ХӘЙРЕТДИНОВА

**Күңелем түрендә**

Фаҗигале еллар үткәч, 1956 елны безнең театрда иң беренче Кәрим ага Тинчуринның данлыклы музыкаль мелодрамасы «Зәңгәр шәл» һәм шул елны музыкаль сатирик комедия «Казан сөлгесе» куелды. Миңа һәр икесендә дә төп рольләрне уйнау бәхете тиде. Бу спектакльләр элекке елларда да куелганга күрә, тамашачы аларны шулкадәр түземсезлек белән көтеп алды, театрга халык дулкыны шундый көч белән килеп керде – көн дә аншлаг, тамаша залы туп-тулы, кассада билетлар сатылып бетә, хәтта театрның ишекләр ватылган көннәре дә була иде. Мин әле хәзер дә, ул көннәрне искә алганда, дулкынланмыйча кала алмыйм. Миңа – әле ул чагымда яшь артисткага, Кәрим Тинчурин үзенең «Зәңгәр шәл»ендәге Мәйсәрәне, «Казан сөлгесе»ндә мөәзиннең кече кызы Мөршидәне бүләк итте. Мин Мәйсәрәнең шатлыгы, моңы, кайгылары, йөрәк тибешләре белән 15 ел сәхнәдә яшәдем. Шул 15 ел эчендә мин дүрт Булат – Азат Абба-



*Мәйсәрә – Рауза Хәйретдинова, Булат – Айрат Арсланов*

*Г.Камал исемендәге театр.*
*«Зәңгәр шәл» спектакленнән күренешләр: Мәйсәрә – Рауза Хәйретдинова, Булат – Наил Әюпов*





*Мәйсәрә — Рауза Хәйретдинова, Булат — Мәсгут Имашев*

сов, Айрат Арсланов, Мәсгут Имашев, Наил Әюпов белән уйнадым. Мин бу елларны һич тә оныта алмыйм һәм бернәрсәгә дә алмаштырмас идем.

1957 ел Мәскәүдә үткән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәре күңелләрдә бигрәк тә тирән эз калдырган. Декаданың беренче пәрдәсен Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектакле белән ачып җибәргән идек. 40 ел вакыт узуга карамастан, әле дә хәтеремдә: залда ут сүнә, Салих Сәйдәшевнең спектаклыгә кереш музыкасы яңгырый, Мәйсәрәнең җыры белән пәрдә ачыла. Егетләр-кызлар, сөлгеләр күтәреп, Сабан туена җыеналар. Шулвакыт залдагы тамашачы аягүрә басып алкышлый башлый. Шул аклышлар сәхнәдәге Сабан туена кушылып, тоташ бер бәйрәмгә әйләнә. Бу бәйрәм декаданың соңгы көненә кадәр дәвам итә. Алып барган башка спектакльләр дә зур уңыш казанды. Ул елны безнең театр олы бүләк — Ленин ордены белән бүләкләнде. Бу көннәр минем йөрәгемдә мәңге онытылмас хатирәләр булып саклананалар.

Без К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектакле белән бик күп шәһәрләрдә гастрольләрдә булдык, зур театрларның пәрдәләрен «Зәңгәр шәл» белән ачып җибәрдек. Кайда гына булсак та, «Зәңгәр шәл» чын мәгънәсендә сәнгать бәйрәменә әйләнә иде.

*«Шәһри Казан». 21 ноябрь, 1997*



*Мәйсәрә — Рауза Хәйретдинова, Булат — Азат Аббасов*



# МАНСУР ШИҺАПОВ

## Мин шуңа сөенәм


Без, сугыш алдыннан туган балалар, бик күп нәрсәдән мәхрүм булып үстек. Ачлыкны да, ялангачлыкны да татыдык. Бик яшьли «тәртә арасына» кереп, зурлар белән тиң эшләп үсәргә дә туры килде безгә. Шул ук вакытта безгә бик гыйбрәтле, сугыштан соңгы рухи бер күтәрелеш чоры да туры килгән икән ләбаса. Зурлар да, кечеләр дә олы бер дәрт белән яшәргә омтылган чак иде ул. Өметләр зурдан, хыяллар чиксез... Әйе, әкренләп сугыш дәвере авырлыклары артта калган, тормыш көннән-көн яхшыра барган чак. Шәһәр тормышын бик үк белмим, әмма авылда ниндидер бер күтәренке рухи халәт тоемлана иде. Авыл клублары гөрләп тора. Халык эштән

*Г.Камал исемендәге театр.*
*«Беренче чәчәкләр» спектакленнән күренеш: Хәмит – Шәүкәт Биктимеров, Сара – Люция Фарсина*



соң шунда җыела, рухланып төрле уеннар уйный, җырлый торганнар иде. Казаннан концерт бригадалары килә, театр коллективлары да күренгәләп китә иде. Шул арада авыл яшьләре үзләре дә театр уеннары уйнап, тамаша ясап алалар.

...Илленче еллар урталарында драматург Кәрим Тинчурин исеме халкына кире кайтарылды. Театрларда аның пьесалары кабат уйнала башлады. Академия театрында бер-бер артлы аның «Зәңгәр шәл», «Американ», «Казан сөлгесе», «Җилкәнсезләр», «Сүнгән йолдызлар» кебек халкыбызның тормыш-көнкүрешен төрле яклап чагылдырган үлмәс әсәрләре куелды. Безнең Күчмә театрда аның «Сакла, шартламасын» исемле кызыклы пьесасы 1956 елда куелган иде. Кәрим Тинчурин исеме шул вакыттан бирле безгә якын. Академия театрының һәр яңа сезонны күренекле авторның мәшһүр «Зәңгәр шәл»е белән ачу традициясе дә ул якынлык хисен көчәйтә генә иде...



*К.Тинчурин исемендәге театр. «Сүнгән йолдызлар» спектакленнән күренеш: Сәрвәр – Зөлфия Вәлиева, Надир Мәхдүм – Шамил Фәрхетдинов*



# МӘГЪСҮМ ХӘБИБУЛЛИН

## Әдип туганякларда

Күренекле немец шагыйре Гете: «Язучыны аңлыйсың килсә, аның туып-үскән җиренә бар», – дигән.

Кәрим Тинчурин кебек күренекле драматургның, җәмәгать эшлеклесенең иҗат чыганаклары, тамырлары кайда соң? Шуларны ачыклау теләге белән мин К.Тинчуринның туган ягына юл тоттым.

Менә мин аның туган авылында – Пенза өлкәсенең Беднодемьяновск районы Белоозерка авылында. Биредә иң элек мин К.Тинчуринның җырлап торган туган ягы моңын ишеткәндәй булдым. Бу якларның матурлыгы, ак каенлы урманнарның яме әйтеп бетергесез.

Эзләнәм, сорашам, уйланам, язам. Төрле кешеләрдән сораша торгач, вакыйгалар ачыклана төшә.

*Кәрим Тинчурин (икенче рәттә уңнан беренче) – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте. 1904 (?)*



К.Тинчуринның әтисе Гали тырыш, урта хәлле крестьян булган. Әнисе Мәхмүдә – шактый зур укымышлы мулла кызы. Казанга укырга да Кәримне әнисе җибәргән.

Халыкның бу якта уен-көлке, җыр яратуын, Тукай әйтмешли, чын иҗатчы булуын әйтергә кирәк. Тинчуриннар гаиләсе турында да биредә бәет чыгарганнар. Ул «Мәмекләр бәете» дип атала. Анда турыдан-туры Тинчурин гаиләсе кешеләренең исемнәре дә әйтелә.

Тирә-яктагы авылларның манзарасына карап торам. Үткәннәрнең җанлы вакыйгалары күз алдыма килеп баскан кебек була. Ничектер күңелне чеметеп алгандай итә... Үз гомеренең иң матур вакытларын – унөч яшенә кадәрге бала чагын К.Тинчурин биредә үткәргән.

Тинчуриннар гаиләсен картлар бик яхшы хәтерлиләр икән әле. Мин алардан шактый гына истәлекләр язып алдым. Авыл халкы шулай ук биредә Кәрим Тинчуринның якын туганнарының калмавын, аларны Ростов-Дон һәм Ленинград шәһәрләреннән эзләргә кирәклеген әйтте.

Мин К.Тинчуринның туган авылында булган чакта, яңа салынган башлангыч мәктәп бинасына мемориаль такта куелды. Китапханәдә язучының иҗатына багышланган күргәзмә оештырылды. Райком вәкилләре дә, совхоз җитәкчеләре дә К.Тинчуринга бәйләнешле истәлекле урыннарны мәңгеләштерү, материалларны туплау турында уйлануларын белдерделәр. К.Тинчурин туган йорт турында да миңа тәфсилләп сөйләделәр, аны утызынчы елларда башка авылга күчереп салганнар, ул сакланмаган. Хәзерге вакытта әдип туган йортның нигезе буш, анда сакланып калган иске мәчеттән ерак түгел зур гына бер тал агачы үсә. Аны К.Тинчурин утырткан тал дип сөйлиләр.

Аның туган авылыннан ике километр ераклыкта Татар Шалдавычы дигән зуррак авыл бар. Анда Кәримнең әнисе Мәхмүдә апа туган йортның бер өлеше әле хәзер дә сакланып калган. Шушы Татар Шалдавычында К.Тинчурин мәдрәсәдә укыган. Хәзер бу авылдагы сигезьеллык мәктәп К.Тинчурин исемен йөртә...

*«Социалистик Татарстан». 17 ноябрь, 1987*



# РАВИЛ ШӘРӘФИЕВ



**Һаман уйныйсы иде…**

Кәрим Тинчуринның нинди генә әсәрен алсаң да, зур талант иясе икәнлеге ярылып ята. Аның геройлары чын мәгънәсендә образлар булуы белән аерылып тора. Һәрберсенең үз характеры, үзенең фикер йөреше, үз теле, хәтта үзенең хәрәкәте, пластикасы күз алдына килә. Мин бигрәк тә аның тел-сөйләм характерына басым ясап әйтергә телим. Хәзер дә оста гына язылган драма әсәрләре бар, характерлары да күренә сыман, ләкин персонажлар барысы да диярлек бер тел белән сөйләшәләр. (Мин, әлбәттә, тере классигыбыз Нәкый ага Исәнбәтне искә алмыйм.) Телебез бертөрле, шактый корыга әйләнгән. Өстәвенә телнең нечкәлекләрен бөтенләй диярлек белмәгән артистлар, бигрәк тә артисткалар күбәйгән чорда, драматургның тел характеристикасы бигрәк тә, заманча әйтсәк, дефицит булып бара.

Мин К.Тинчурин иҗаты белән беренче тапкыр Мәскәү театр училищесында укыган чорда, театрыбызның башкалабызда үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында күрсәткән «Зәңгәр шәл» спектаклен карап таныштым. (Безгә анда массовкада да катнашырга туры килде.) Шундый тантаналы көннәрдә күрсәтелгәнгәдер дә инде, спектакль нindидер зур бәйрәм булып кабул ителде. Икенче елны, ягъни 1958 елда, театрыбыз Мәскәүгә «Казан сөлгесе»н китерде. Ул спектакльдә дә катнашырга туры килде. Спектакль үзенең нindидер самимилеге, сафлыгы белән хәтергә сеңеп калган.

*Хәлим Әбҗәлилов*



Ниһаять, аның «Американ» сатирик комедиясендә уйнау миңа бер яктан зур иҗат шатлыгы бирсә, икенче яктан артист өчен бик зарур булган беренче популярлык китерде дисәм дә, ялгыш булмас. Мине «Американ» дип йөри, хәтта эндәшә башладылар. Аннан соң мин аның «Назлы кияү»ендә, «Зәңгәр шәл»дә Шәйхи бабай белән Галәвиен, «Казан сөлгесе»ндә Хәзрәтен уйнадым.

Заманында К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» әсәре буенча режиссер Ширияздан ага Сарымсаков куйган спектакль дә

хәтердә бик нык уелып калган. Анда уйнаган Х.Әбҗәлилов, Х.Сәлимҗанов, Г.Шамуков, А.Хәйруллина, Ф.Колбарисов, Ш.Әсфәндиярова, И.Гафуров һ.б. артистларның көчле ансамбле бик нык тәэсир иткән иде. Әгәр дә ул пьеса яңадан сәхнәгә куелып, анда уйнарга насыйп булса, мин тагын да бәхетле булыр идем, чөнки Гражданнар сугышын, нэп чорын чагылдырган зур полотнолы бик камил әсәр дип саныйм мин аны.

Безгә автор яңа пьеса укып, аны тикшергәндә, әсәрнең кыйммәтен бәяләгәндә, минем бер критерием бар – (хәер, ул күп артистлар өчен шулайдыр) уйныйсым киләме, юкмы минем бу әсәрдә. Килсә – ул минем өчен әйбәт, килмәсә – начар пьеса.

Ә К.Тинчурин әсәрләрендә минем уйныйсым килә! Мәсәлән, шул ук «Американ» комедиясендә генә дә мин барлык ир рольләрен уйнап чыгар идем. Чөнки аларның һәркайсы бик тә үзенчәлекле, бик тә кызыклы, колоритлы типлар.




*Габдулла Шамуков*

*Кәрим Тинчурин театр хезмәткәрләре арасында*



## РОБЕРТ ӘХМӘТҖАН



**Эзе дә юк…**

*Сталин репрессиясе корбаннарына*

Хаклык өчен диеп, дөрләп җаны,
Яшәде ул тугры, гомергә...
«Сталинчыл бөек еллар» Аны
алып китеп... атты Себердә!..

Ату тавышы анда яңгырый тонык,
Сискәнгәндер бүре, сискәнсә...
Себер кары калын, гүя толып –
Тавышың тонык, тынып беткәнче!..

...Эзе дә юк, соңгы сүзе дә юк –
Шулай сүнде «халык дошманы»!
Трибунадан, иблис күзенә кереп,
сатты җанын халык куштаны...

Ятим өйдә – ятим балалары –
Ирен көтә хатыны моңаеп...
Стенада Сталин бабалары –
трубкасын капкан елмаеп!..



«Үсегез генә, сезгә чират җитәр», –
дигән кебек күзгә карый ул.
«Хаклык өчен җирдән ир-ат китәр, –
даһи өчен китү ярый ул!» –

дияр иде аңа шул сабыйлар,
аңласалар икән хәлләрне!..
«Ватан өчен үлде дәү абыйлар!..
Бөек Ата... (аткач җәлләрме?..)»

Үсеп җиткәч, дөньясын актарып,
үчне алды алар дошманнан...
«Дошман ни ул?! – дия ачы Тарих, –
саклан, кешем, берүк куштаннан!..»

Партиянең әмере белән бит гел
Үтәде ул хаклык кушканны,
нахак яла корбаны бит, бәгырь! –
ничек булсын «халык дошманы»?!

Каберегез кайда, фида җаннар?
Күпме эзли сезне Ил-Ватан!..
Кемнәр вөҗданында сезнең каннар?..
Офыклардан эзләп
килә Таң!..

## ИЛЬТАНИ ИЛЯЛОВА



**Счастливая страница**

Я смотрю на старые, пожелтевшие от времени снимки, на которых запечатлен летящий почерк Мастера, и сердце полнится радостью с горечью пополам. Конечно, радостно, что 100-летие со дня рождения выдающегося деятеля национальной культуры Карима Тинчурина отмечается нынче как большой всенародный праздник. Но нельзя не горевать о том, что на долгие годы он был отторгнут от живого процесса развития татарской литературы и театра, для которых так многое успел сделать и сколько еще сделал бы...

Рукопись «Голубой шали» завершена в 1926 году. Звездный час татарского театра, которому в тот год было присвоено звание академического. Звездный час и в судьбе Карима Тинчурина, именно тогда удостоенного (в числе первых деятелей национальной сцены) звания заслуженного артиста Татарской республики.

Только что законченную пьесу Тинчурин поставил сам, он же сыграл и роль Булата, главного героя.

Едва ли мог он тогда предположить, что этой его пьесе суждена в будущем поистине фантастическая популярность. Она практически не исчезала из репертуара театра все шестьдесят лет.

*«Зәңгәр шәл» спектакленнән күренеш:*
*Галия Кайбицкая, Мәрьям Сульва, Маһинур Шәрипова*



Было множество различных постановок, по которым можно проследить основные вехи развития татарской драмы. Были эксцентрические спектакли, в которых актеры выходили одетыми в зеленые одежды, с нарисованными на лицах тракторами, символизирующими новую жизнь... Были, наоборот, версии добросовестно подробные, с попыткой логического объяснения весьма условного сюжета пьесы, на что сам автор едва ли рассчитывал. Помнятся и всевозможные рецензии на «Голубую шаль» – восторженные и беспардонно-ругательные. Словом, менялось многое – неизменной оставалась только зрительская любовь к тинчуринской пьесе, ее неувядаемая популярность.



*Кәрим Тинчурин. 20 нче еллар*

Удивительно, как много успевал сделать этот разносторонне одаренный человек! В том же 1926 году, когда была закончена и поставлена «Голубая шаль», Тинчурин работает над пьесой «Без ветрил», одной из лучших в его драматургическом наследии. Одновременно пишет множество статей для местных изданий, в которых отстаивает реалистический путь развития национального театра, борется с формализмом, левацкими течениями в искусстве. И все это он умудряется совмещать с педагогической работой в театральном техникуме, бурной общественной и организаторской деятельностью.

Счастливый год, счастливая страница яркой, талантливой жизни, трагически оборвавшейся десять с небольшим лет спустя.

*«Вечерняя Казань». 15 сент. 1987*



# НӘҖИБӘ ИХСАНОВА


**Менә бу Кәрим Тинчурин «мунчасы»!**

Мәктәп елларында безнең буынга Кәрим Тинчурин иҗаты белән танышырга туры килмәде. Үзебез театрда уйнап йөрдек, ләкин Тинчурин исеме белән очрашмадык.

Мәскәүдә театр мәктәбендә укыган вакытта, безне Казанга чакыртып алдылар. Театрыбыз декадага әзерләнә иде, безне «Зәңгәр шәл» спектакленә күмәк сәхнәгә кертергә булганнар. Без үзебезне чын артистлар итеп хис иттек. «Театр» дигән сихри дөньяга Кәрим Тинчурин белән «җитәкләшеп» кердек, чирканчык алдык. Мәскәүдә үткән бу декада бик зур уңыш белән узды. Укытучыбыз «Зәңгәр шәл»не карагач, шаккатып сөйләгәне истә калган. Тамашачы белән сәхнәдә уйнаган артистларны бөтереп алган бу могҗизаның сихри көчен аңларга теләде, гаҗәпләнде.

Инде театрга кайтып эшли башлагач, тагы шушы сихри «Зәңгәр шәл»дән башладык, мәш килә идек. Күп тә үтми миңа Заһирә ролен бирделәр. Бу могҗиза-спектакльдә адашып калырмын кебек тоелды, беренче пәрдәнең күмәк сәхнәләрендә мыжлап торган массаны тотып торырга кирәк иде. Мунча кергән кебек була идем. Менә бу Кәрим Тинчурин «мунчасы»!

# ХӘЛИМ ҖӘЛӘЛОВ



**Бүген дә сагынам…**


Без, артистлар, театрда «Зәңгәр шәл» уйнаган көнне бәйрәм каршылаган кебек сагынып көтеп алабыз. Төп рольдәме ул, эпизодик рольдәме, масса күренешләрендә катнашамы – барыбер, һәммәбезнең күңел күтәренке, бәйрәмчә. Нәкъ менә Сабан туендагы кебек. Сәхнәдә җыр, бию, җор сүзләр...

Инде сәхнәдә җитмеш елдан артык булуына карамастан, тамашачы «Зәңгәр шәл»не һәрвакыт яратып карый, ничә буын артистлар яратып уйный. Мондый зур уңышның сәбәбе нәрсәдә, чишмә башы кайда? Моны бер-ике сүз белән генә аңлатып бирү җиңел булмастыр. Шулай да...

Минемчә, драматург татар халкының тормышын, гореф-гадәтләрен, фольклорын, халык авыз иҗатын ифрат шәп белгән, һәм шуны үзенең әсәрләрендә бик оста файдаланып, аларны тагын да бизәп, баетып халкына кире кайтарып биргән.


Мин бу спектакльдә инде кырык елга якын катнашып киләм. 1963 елдан халык күренешләрендә (егетләр, картлар), 1970 елгы куелышында (режиссер М.Сәлимҗанов) беренче пәрдәдә авыл егете Нури, урман пәрдәсендә ялган акча ясаучы Тимуш, ә 1987, 2000 елгы куелышында (режиссер М.Сәлимҗанов) чуаш Пәтрәй рольләрен башкардым. Әле тагын качкыннар күренешендә «Иске кара урман» җырын да башлап җырларга насыйп булды.

К.Тинчурин пьесалары буенча куелган тагын берничә спектакльдә уйнау бәхетенә ирештем. «Сүнгән йолдызлар»да (1971) авыл егете Ибраһим, «Назлы кияү»дә (1975) Рәшит, «Казан сөлгесе»ндә (1982) шәкерт Салих образлары. Берсенә-берсе һич тә охшамаган бу рольләрне мин бик яратып уйнадым. Һәм ул чакларымны мин бүген дә сагынып искә алам.



*Ш.Мәрҗани мәчете*

# РӘДИФ ГАТАШ



**Сүнмәс йолдызлар**

Гасырларның караңгысын ерткан
Йолдыз булып туган театр,
Тукай васыятьләрен истә тотып,
Бик күпләрне әле уятыр.
Мәңге аны чорлар
Раушан көзге –
Бөек рух көзгесе санарлар.
Һаман исән –
Халык йөрәгеннән
Юлын алган бөек «Сәйяр» бар.
Гүя чатыр,
Түбәсенә – йолдыз
Айлы күкнең үзе ябылган,
Гүя
Берчак сүнгән йолдызларын
Сүнмәс итеп кабат кабызган
Театрда бәйрәм:
Гүя алар –
Волжская, Камал, Карилар,
Тинчуриннар –
Ерак йолдызлардан
Изге йортка сөенеп карыйлар.

...Еллар үткән саен яктың арта,
Раушан көзгең тарта, театр.
Халык рухын киләчәккә илтер,
Бик күпләрне әле уятыр
Йолдызларың синең,
Театр,
Сүнмәс йолдызларың...



*Г.Камал исемендәге театр. «Сүнгән йолдызлар» спектакленнән күренеш: Мәйсәрә – Люция Хәмитова, Надир Мәхдүм – Ринат Таҗетдинов*



# ВЕНЕРА ГАНИЕВА

## Мәйсәрә белән кабат очрашыр идем

Тормыш көтелмәгән борылышлар белән тулы. Әйтик, мине – М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасын көннәрдән бер көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына атаклы «Зәңгәр шәл»дә катнашырга чакырырлар дип кем уйлаган?!

Кәрим Тинчурин һәм Салих Сәйдәшевләрнең уртак иҗат җимеше буларак барлыкка килгән гүзәл Мәйсәрә образын башкару һәр артисткага да буй җитмәслек хыял булып тоелганын яхшы беләидем мин. Өстәвенә миңа бу катлаулы рольне 80 еллык бай традицияләре булган театрның тәҗрибәле артистлары белән берлектә тудыру сорала. Шулай булгач, Мәйсәрәне уйнау турындагы уйның булуы да мөмкин түгел... Әмма чынбарлык хыялга караганда кыюрак булып чыкты.

Мин үзем Казанда туып-үскән кыз. Театр җанлы әти-әниләремә һәм дә мине укыткан Г.Ибраһимов исемендәге 89 нчы татар мәктәбе укытучыларына рәхмәт – алар мине кечкенәдән татар театры спектакльләренә йөрткәннәр. Туган телебезгә, туган халкыбызның саф һәм самими гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә мин шул спектакльләр аша килеп кергәнмен. Шунда халкыбызның бөек тарихына мәхәббәт бөреләнгән. Без караган күптөрле спектакльләрдән «Зәңгәр шәл» мелодрамасы минем сабый йөрәгемә аеруча нык урнашып калган. Гаҗәп, әмма чын дөресе шу-

*Рокыя Кушловская*



*Галия Кайбицкая*





*Флера Хәмитова*




*Рауза Хәйретдинова*

лай, театрда «Зәңгәр шәл»гә репетицияләр барган чакта, шул бала чакта каралган «Зәңгәр шәл» миңа үзенчә ярдәм итте. Хәтеремдә сакланган җанлы тамаша залы, сәхнәдәге зур артистларның уены гел күз алдымда булып, иҗат фантазиямне дулкынландырды. Әлбәттә, мин Мәйсәрә образы белән саташып йөргән көннәремдә әсәрне сәхнәгә куючы Марсель Сәлимҗанов ярдәмендә бу рольне беренче булып башкарган артисткалар Галия Кайбицкая һәм Рокыя Кушловскаялар тәҗрибәсен дә өйрәндем. Шулай итеп, Роза Хәйретдинова һәм Флера Хәмитоваларның мин күреп белгән, мине гашыйк иткән Мәйсәрәләре элегрәк табылган ачышлар белән дә тулыландырылды. Һәр яңа куелыш матур традицияләрне үзләштерү белән берлектә, шул традиция эченнән шытып чыккан яңа куелышның яңа бизәкләр белән баетылган булуын да таләп итә.

Кыскасы, мин драма театрында искиткеч мәктәп үттем. Бу минем иҗат тормышымда, әлбәттә, зур этәргеч булачак. Инде хәзердән үк опера сәхнәсенә җырларга чыккач, драма сәхнәсендә файдаланган алымнарны да истә тотып эш итәм. Нәтиҗәдә, мин башкарган партияләр үзенчәлекле төсмерләр белән тулылана бара. Әйе, Кәрим Тинчуринның иҗат традицияләренә тугры артистлар белән очрашу, Мәйсәрәне уйнау минем тормышымда гаять зур вакыйгага әверелде. «Инде язмыштан тагын ни теләр идең?» – дисәләр: «Кабат шундый очрашуны», – дип җавап бирер идем.

# ГАЛИ АРСЛАНОВ



## Күпкырлы талант

XIX йөзнең соңгы берничә дистә елында татар халкы, үзенең алдагы гасыр башындагы яңарту, күтәрелү чорына әзерләнгәндәй, дөньяга бер-бер артлы мәдәниятнең төрле өлкәләрендә әйдәп барырдай олуг шәхесләр бүләк итә. Шигъриятттә андый шәхес – Г.Тукай, прозада – Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, драматургиядә – Г.Камал, театр өлкәсендә – Г.Кариев, М.Мутин, сынлы сәнгатьтә – Б.Урманче, музыка дөньясында – С.Габәши, С.Сәйдәшев.

Татар театр сәнгатенең күренекле эшлеклесе, классик драматург, талантлы актер, акыллы эзләнүчән режиссер, педагог, публицист-теоретик Кәрим Гали улы Тинчурин әнә шул бөек шәхесләр арасында лаек-

*Режиссер Кәрим Тинчурин (уртада) театр артистлары белән. 1924*





*«Ак чәчәкләр» спектакленнән күренеш. Сулдан уңга: Камал III, Касыйм Шамил, Хөсәен Уразиков. Кәрим Тинчурин төшергән рәсем*

лы урын алып тора. Аңа Ходай илле генә яшь гомер биргән, иҗат чоры, 1910 елдан алып исәпләгәндә, бары тик 27 елга гына җыела. Әмма шул кыска гына чорда да ул татар халкының мәдәнияте, сәнгате өлкәсендә җуелмас эз салып өлгерде. Аның иҗат мирасы әле бүген дә безнең белән. Ул яши, халкыбызны тәрбияләүдә армый-талмый хезмәт итә, кайгыда – юата, шатлыкта – уйната-көлдерә.

XX йөз башы... Илдә инкыйлаби көчләр күбәйгәннән-күбәя бара. Алда – ко-точкыч үзгәрешләр, катаклизмнар. Җәмгыятьне үзгәртеп кору тарафдары Кәрим укыган мәдрәсәдә дә җитди эш алып баралар. Нәтиҗә озак көттерми: яшәп килгән тәртипләргә ризасызлык йөзеннән шәкертләрнең 82 кешедән торган зур төркеме мәдрәсәне ташлап чыга. 1906 елның февраль аенда булган бу вакыйга К.Тинчу-ринның тормышын кискен борып җибәрә. Урман хуҗалыгында эшләү, авыл мәдрәсәләрендә мөгаллимлек итү, кызыклы кешеләр, төрледән-төрле характерлар белән очрашу-аралашу алда торган эшләр өчен мәктәп тә, тормыш материалы да булып тора. Ниһаять, 1910 ел, «Сәйяр» труппасы...

«Татар театрының атасы» Г.Кариев җитәкчелегендәге беренче профессиональ татар театр труппасы К.Тинчурин актер итеп кабул ителгән чорда инде шак-тый тәҗрибә, көч туплаган иҗат оешмасы буларак төсмерләнә. Аның даими артистлары, режиссерлары, милли, рус һәм чит ил драматургиясенә таянган бай гына репертуары бар. К.Тинчурин – Үзбәкнең (сәхнә псевдонимы) театр тәнкыйтьчеләр игътибарын җәлеп иткән беренче эше – Г.Камалның «Банкрот» комедиясендәге Җамали роле. Яшь артист рольне үзенә генә хас юмор белән башкарып чыга. Аның тәү тапкыр сәхнәдә күренүен күренекле театр тәнкыйть-чесе Г.Кәрам үзенең спектакльгә багышланган рецензиясендә: «Бу әфәндедә та-бигый бер талант барлыгы һәрбер хәрәкәтеннән сизелмештер», – дип билгеләп үтә...

Шушы ук чорда К.Тинчурин талантының башка яклары белән дә ачыла бара: «Шомлы адым», «Соңгы сәлам», «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү» пьесаларын яза, аларны үзе үк режиссер буларак сәхнәгә куя, төп рольләрдә чыгыш ясый...

20 нче елларда К.Тинчуринның актерлык эшчәнлеге арткарак күчә, оештыру сәләте, педагогик осталыгы, теоретик фикерләү мөмкинлекләре, режиссура сәнгате алга чыга.

20 нче ел башлары К.Тинчурин иҗатында яңа театр төзү өчен көрәш еллары буларак та характерлы. 1922 елда татар театры тарихында беренче тапкыр буларак үз бинасы булдырылгач: «Милли театр сәнгате кайсы юлдан китәргә тиеш?» – дигән сорау көн тәртибенә килеп баса. Реалистик сәхнәсен шартлы сәнгать тарафдары К.Тинчурин үзенең күпсанлы газета-журнал мәкаләләре, төрле җыелыш-киңәшмәләрдә, диспут-дискуссияләрдә ясаган чыгышлары аша милли театрыбыз нигезендә «татар театрының атасы» Г.Кариев салган реалистик традицияләрне саклап кала ала...



*Кәрим Тинчурин иҗатташ дусты Габдулла Кариев белән. 1919*

Режиссура сәнгате өлкәсендә 20 нче елларда К.Тинчурин сизелерлек зур уңышларга ирешә. Унъеллык башында уздырган теоретик эзләнүләр аның бу өлкәдәге иҗатына төпле нигез булып тора. Ул куйган спектакльләр хәзер инде реалистик сәнгатьнең ныклы җирлегендә булсалар да, аларга чор белән бәйле рәвештә яңа эчтәлек, яңа форма төсмерләре өстәлә.


30 нчы елларда К.Тинчурин практик режиссура белән аз шөгыльләнә. Чөнки Мәскәү, Ленинградтагы зур-зур югары уку йортларын уңышлы тәмамлап, татар театр сәнгатендә Р.Ишморат, С.Булатов, Г.Ильясов, Г.Исмәгыйлев, Ш.Сарымсаков, К.Тумашева кебек яшь режиссерлар килеп кушыла. К.Тинчурин исә көчен күбрәк драма әсәрләре язуга юнәлтә. Р.Ишморат белән берлектә «Тургай», К.Нәҗми белән бергә «Булат бабай семьясы», үзе генә «Кандыр буе», «Алар өчәү иде», «Юкә чәчәк атканда» әсәрләрен яза...

## ЛӘБИБ ЛЕРОН

**Шигыремә керде Тинчурин…**

Бар йокымны үзе белән алып,
Вакыт узып бара төн чиген...
Театрдан кайтып килешеме?!–
Шигыремә керде Тинчурин!

Шигыремә керде, сәлам бирде.
– Аншлаг, – диде ул, – бүген дә!
«Зәңгәр шәл»дән халык айный алмый, –
Белсәң иде, шатлык күңелдә.
Үз-үземнән көнләшәм мин бүген:
Сәер, ләкин рәхәт көнләшү!
Шул көндәшем белән, төнне айкап,
Кайтып килеш әле, сөйләшеп.
«Зәңгәр шәл»нең төсе уңмас төсле,
Кунмас төсле аңа тузаннар...
Урамнарда: «Әнә Булат!» – диеп,





«Сәлам, Булат!» – диеп узалар.
Булат роле яшьләр өчен дә бит,
Тик нигәдер үзем уйнасам,
Халык аны ныграк аңлар сыман...
Каным кайный, шулай уйласам.
– Без кабызган утлар сүнмәс алар! –
Дип җырладым бүген көндәшкә...
Ярый, сау булып тор, минем әле

Кереп чыгасым бар Сәйдәшкә...
Саубуллашып чыгып китте шулай,
Таңга каршы китте Тинчурин.
Уйламагандыр да... Көнгә кадәр
Озак узачагын төн чорын...

Һәр заманның яман чире була:
Туберкулезлары, тифлары...
Саф җаннарны кырган шәхес культы,
Йоткан нәфес культы типлары.

Җинаятьне мөмкин яшерергә,
Мөмкин, әйе, ярлык тагарга:
Саф күзләргә карап, мөмкин лә ул
«Халык дошманы» дип атарга!

*Артист Кәрим Тинчурин*



*«Зәңгәр шәл» спектакленнән күренеш:*
*Булат – Кәрим Тинчурин*

Үлгән көнен мөмкин яшерергә,
Вакытлыча ләкин ансы да...
Бәгырьләрне телем-телем телеп,
Йөрәк сыкрый, әрни, җан сыза...

Сәхнәгә ул уйнар өчен түгел,
Яшәр өчен менгән – яшәгән!
«Озак тормас, сүнәр», – дигәннәрнең
Бәбәгенә карап яшәргән!

...Яңа сортлар ачкан Мичуриндай,
Сәхнә серен ачкан Тинчурин...
Төннәр аша килгән шул серләрне
Хәтер йомгагына мин чорныйм.

*1987*



*Зәңгәр шәл*



# РАУФ ИГЛАМОВ

## Драматургия 20-х годов

Формирование национальных театров Поволжья, Средней Азии, Северного Кавказа и других регионов страны невозможно представить без музыкально-драматических пьес. Использование бытового, этнографического материала, в частности музыкального фольклора, имеющего богатейшие традиции в устном народном творчестве, создавало живую преемственность самодеятельного и профессионального искусства. Для масс трудящихся путь к овладению мировой культурой не мог миновать форм, приближенных к народному сознанию.

Особое место в панораме музыкальных драм 20-х годов, выражавших симпатии массового зрителя, занимают

*Туберкулез белән авыручыларга ярдәм итүче артистлар. Икенче рәттә сулдан беренче – Кәрим Тинчурин. 20 нче еллар*





*«Сәйяр» труппасының мәшһүр ирләре: Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, Зәйни Солтанов, Габдрахман Мангушев. 1916*



*Салих Сәйдәшев*

пьесы Тинчурина. Долговременный интерес к ним зрителя подтверждает значение их в становлении советского татарского театра. На основе музыкальных спектаклей популяризировалось творчество начинающих композиторов, в первую очередь замечательного татарского композитора С.Сайдашева, совершенствовались пластическое и вокальное мастерство актеров – актеров синтетического плана. Путь к профессиональной татарской опере был открыт благодаря музыкально-драматическим спектаклям драматического театра, ряд исполнителей спектаклей 20-х, позднее 30-х годов составили костяк оперной труппы Театра оперы и балета. Но главное – музыкально-драматические пьесы Тинчурина помогли установить контакт театра с демократическим зрителем, что в первые годы Советской власти значило многое, если не сказать все. Пьесы Тинчурина представляют собой произведения поэтического театра, включающего в себя как обязательное начало социалистическую агитационную направленность. Благодаря многослойной структуре они обладают способностью чутко реагировать на смену сценических форм, и поэтому составляют существенную часть репертуара современного театра, пользуясь, по выражению А.Н.Анастасьева, «беспримерным» успехом.

Не ставя задачи дать исчерпывающее хронологическое описание всего творчества Тинчурина – им написано двадцать шесть пьес, некоторые из них носят следы торопливости, неизбежной в условиях театра 20-х годов, когда число премьер доходило до сорока и более названий, – автор книги уделяет основное внимание узловым произведениям драматурга – тем, в которых с наибольшей силой проявляется художественный метод Тинчурина, его новаторский вклад в сокровищницу татарской литературы, а также внутренняя связь драматургии автора с наиболее перспективными явлениями русской советской драматургии и театра в одну из самых театральных эпох советского театра – 20-е годы.

*К.Тинчурин исемендәге театр.*
*«Сүнгән йолдызлар» спектакленнән күмәк музыкаль күренеш*



# АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН



## Кәрим Тинчурин стиле

Заһидә ханым Тинчуринаның истәлекләрендә шундый бер урын бар. Ул ире К.Тинчуринның борчылган, нәрсәгә дә булса рәнҗегән вакытларында дәшми генә ишекле-түрле йөрү гадәте бар иде, дип сөйли. «Озак йөри, — ди ул, — аннары миңа дәшә: әйдә, бергәләп йөрик әле! Һәм без икәүләп тын гына йөри башлыйбыз...»

Менә шул нәни генә истәлектән гаять үзенчәлекле, көтмәгән-уйламаган карар кабул итәргә сәләтле кеше күз алдына килеп баса. Француз галиме Бюффонның «стиль — кеше ул» дигән мәгълүм афоризмы искә төшә. Чыннан да, К.Тинчурин әсәрләрен укыганда яки сәхнәдә караганда, көтелмәгән, беренче карашка гаҗәеп тоелган, ләкин кешенең характер үзенчәлеге белән, вакыйгаларның табигый агышы белән нигезләнгән эш-хәрәкәтләрне, настроениеләр алмашуын күрәсең.

*Хәким Сәлимҗанов «Кандыр буе» спектаклендә*



К.Тинчуринның стиль үзенчәлекләре ачык булып сатира һәм комедия өлкәсендә формалашты. Ул, беренче чиратта, комедиограф, капиталистик җәмгыять шартларының кеше шәхесенә тәэсирен үзе күргән, шул шартлар авырлыгын үз җилкәсендә татыган художник. Шуңа күрә дә аның талант көче иң башта сыйнфый җәмгыятьне фаш итүгә юнәлтелгән. Бу хәл ул калдырган әдәби мирасның үзенчәлеген дә, стиль төрен дә билгели. Аның пьесаларының 12 се комедия жанрына карый, 5 се — драма, 4 се — музыкаль драма һәм 1 се — трагедия. Дүрт пьесасын ул соавторлыкта язган. Драмага һәм мелодрамага караганнары арасында да көлү һәм кире типларны мыскыллау шактый урын тота. Әйтик, «Зәңгәр шәл»дә тулы бер пәрдә һәм аерым күренешләр сатира һәм комедия рухында бара. «Ил», «Булат ба-

бай семьясы», «Кандыр буе» кебек пьесалар турында да шуны әйтергә мөмкин. Драматург иске җәмгыятьтә рухлары гарипләнгән, начар белем алган, ялгыш тәрбияләнгән кешеләрдән үткен көлә, димәк, буржуаз җәмгыятьнең нигезләрен фаш итә, дистәләрчә сатирик һәм комик образлар тудыра...



*К.Тинчурин исемендәге театр. «Хәйләсез – дөнья файдасыз» спектакленнән күренеш: Сәфәргали – Ренат Әкбәров, Фаизбикә – Роза Хәбибрахманова*



*«Кандыр буе» спектакленнән күренеш: Минһаҗ – Мохтар Мутин*

# ГАЗИНУР МОРАТ



**Черек күл**

Черек күлгә кармак салдым,
Еллар аша үрелеп.
Айкалды күл, чайкалды күл, –
Сере китте түгелеп.

Айкалды күл, чайкалды күл,
Чайпалды күңелләрем.
Татарның күпме затлысы
Чүплеккә түгелгәнен

Уйладым да уем качты.
Текәлдем калкавычка...
Котылсын заман –
        сәяси
Капкыннан, алдавычтан.

Кешенең кадере булсын,
Кабере булсын җирдә.
Саклансын заман –
        капмасын
Кабаттан сыйнфый җимгә.



*Кәрим Тинчурин*

«Шагыйрьләрнең каберләрен
Эзлим», – дип язган дустым,
Киләчәккә зират аша
Синме карарга куштың?!


Күпме табут кайтты илгә,
Күпмесе – безгә кордаш...
Кай зиратта ята, димсең,
Якташың Фәтхи Бурнаш?

Кай зиратта ята, димсең,
Хөр уйлы, гали җаннар –
Мирсәет Солтангалиев,
Тинчурин, Галимҗаннар?..


Шигырьгә күчәдер,
        Җанга
Сыймаган борчу, кайгың...
Ярый әле, яд итәргә
Кабере бар Тукайның.



*Мирсәет Солтангалиев*



*Галимҗан Ибраһимов*




Кадере бар...
Шөкер әйтеп,
Коенабыз данында.
Кабере бар...
Яшәсә дә
Халыклар зинданында.

Ә бит кемнәрдер синең дә
Шәхесеңә тукына.
...Черек күлдә дога кылдым
Шәһитләр рухына.



*Репрессия корбаннары: уңнан сулга (утырганнар) – Татарстан өлкә комитетының икенче секретаре Бари Абдуллин, язучы Шәриф Камал, Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Альфред Лепа; басканнар – драматург Кәрим Тинчурин, ТатЦик секретаре Гомәр Байчурин*

*Сталин. Б.Чукомин рәсеме*




*Кәрим Тинчурин мәктәптә чыгыш ясый. 1936*






*Кави Нәҗми (уңнан беренче) һәм Кәрим Тинчурин (сулдан беренче) Мәскәү кунаклары белән*

*Кәрим Тинчуринның баш режиссер булып эшләгәндәге эш кәгазьләре*




ДИРЕКТОР
Государственного Татарского
ТЕАТРА

Служебная записка.





*Спектакльдән соң. Уртада – Ширияздан Сарымсаков*



*«Гаепсездән гаепле» (А.Островский) спектакленнән күренеш: сулда – Кәрим Тинчурин, уңда – Газиз Сәйфелмөлеков*



*«Саран» (Мольер) спектакленнән күренеш: Маккәррәм – Кәрим Тинчурин, Алмас ханым – Гөлсем Болгарская*





*Кәрим Тинчуринның Заһидә ханымга бүләк иткән әйберләре*





*Сәнгать әһелләре. 20 нче еллар*

*Ял итәргә дә вакыт бар иде. Сулдан уңга: Кави Нәҗми, Сәрвәр Әдһәмова, Заһидә Тинчурина, Кәрим Тинчурин. 1929*





*Кәрим Тинчурин исемендәге театр.*
*«Хәйләсез – дөнья файдасыз» спектакленнән күренеш: Сәфәргали – Фәһим Ситдыйков, Фәизбикә – Роза Хәбибрахманова*

*К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективы. Беренче рәттә уртада – театрның баш режиссеры Рәшит Заһидуллин. 2002*





Товарищество

Гутманъ

کوتهان شرکتنده

Телефонъ № 1-89

محمد صادق هم علی موسین لر

*Кәрим Тинчурин алдырган гәзит битләре*













*Кәрим Тинчуринның шәхси таныклыгы*







*Гариза*



*Кәрим Тинчурин спектакль алдыннан*



*Кәрим Тинчуринның фотоальбомы*







*Кәрим Тинчуринның антиквар әйберләре*





ВЫПИСКА

Из приказа № 22 по Управлению по делам Искусств при СНК АТС

от 28 Мая 1936 г.

§ 1


Отмечая двадцатипятилетний юбилей заслуженного артиста Республики и драматурга тов. ТЕНЧУРИНА Карима Алиевича и оценивая его огромные заслуги в области театрального искусства, приказываю отделу театров за счет средств Управления по делам Искусств при СНК ТР оборудовать домашний рабочий кабинет юбиляра гарнитуром мебели.

Подлин. подписал – Начальник Управления по делам Искусств — АЛЬМИ

С подлин. верно: Секретарь — КОЖЕВНИКОВ

Спасс манарасы





ПРИКАЗ №54а.

по Татгосиздату при СНК АТСР "Татгосиздат" от 28/V-36 г.

28-го с/г. исполнилось 25 лет, выдающейся творческой деятельности драматурга и заслуженного артиста Татарии КАРИМА АЛИЕВИЧА ТИНЧУРИНА.

Тов. ТИНЧУРИН за эти годы написал ряд блестящих произведений на татарском языке вышедших в издание Татгосиздата.

Литературная связь тов. ТИНЧУРИНА с Татгосиздатом и сейчас очень крепка. Маститый татарский драматург продолжает работать над новыми произведениями, национальными по форме и социалистическими по содержанию.

Управление Татгосиздата постановило отпустить 3500 р. на постройку тов. ТИНЧУРИНУ летней дачи вблизи КАЗАНИ, дав таким образом возможность Кариму Алиевичу Тинчурину более успешно продолжать свою творческую деятельность на пользу рабочего класса и всех трудящихся.

П.п. Управляющего Татгосиздатом: Цуксимов.

Верно: Секретарь Управления: / Семенов/

*Татарстан дәүләт нәшрияты боерыгы. 1936*

*Матбугат йорты*





№

„26.“ декабря 1936 г.

Qajа Куда, Kemga—Кому Тов. ТЕНЧУРИНУ К.А.

Tatarstan Sotsial Sovetlar Respublikasь Eşçe-Krestian həm Qьzьl Armia Deputatlarьnьŋ Yzak Başqarma Komitetь

utьşьnьŋ nce nomerlь aerketmasennan

СЬҠARMA

**ВЫПИСКА**

из протокола № 30/II заседания президиума Центрального Исполнительного Комитета Советов Рабочих, Крестьян. и Красноарм. депут. Тат. С. С. Республики

от „15“ мая 1936 г. года.

| Tьŋladьlar—Слушали: | Qərar birdelər—Постановили: |
| --- | --- |
| О 25 летнем юбилее драматурга и заслуженного артиста республики тов. К.А.Тенчурина | В ознаменование 25 летней работы К.А.Тенчурина в области литературы и театра наградить юбиляра пишущей машинкой системы „Ундервуд.“ |

Пред. ... ЦИК АТССР— (Гарипов)

Совнарутчет аб № 282962

Казань, Татполиграф

Башкарма комитет бинасы



24. ТИНЧУРИН КАРИМ – родился в 1887 году, в крестьянской семье. Беспартийный. Тов. ТИНЧУРИН является одним из наиболее крупных татарских драматургов. За период революции ТИНЧУРИНЫМ написано около двадцати пьес, которые сыграли очень большую роль в развитии татарского советского театра. Среди этих драматических произведений некоторые – например "Без ветрил", "На кандре", "Их было трое", имеют особо важное идейно-художественное значение. Разоблачение контрреволюционной татарской буржуазии / "Без ветрил"/ показ новой колхозной жизни в татарской деревне. /На кандре /, показ громадного культурного роста в нашей стране, показ формирования культуры для новых научных кадров из рабоче-колхозной молодежи /"Их было трое"/ вот какие крупные вопросы ставятся в этих произведениях Тинчурина. Своими драматическими произведениями, особенно новыми пьесами в годы первой и второй пятилетки Тинчурин зарекомендовал себя, как одного из лучших представителей татарской беспартийной интеллигенции, стремящихся честно и преданно работать под руководством коммунистической партии. Тинчурин один из лучших мастеров татарской советской драматургии.

НАГРАДИТЬ юбилейным значком.

25. КАВИ-НАДЖМИ – родился в семье крестьянина-бедняка. Член ВКП/б/ с 1919 года. Служил в рядах Красной армии около 15 лет за что был награжден почетными грамотами правительства и ценными подарками. Творческая и общественно-политическая работа тов. Наджми на тему гражданской войны рекомендует себя, как мастера художественного слова, привлекая внимание советских писателей и читателей, как показом героических побед Красной армии, так и богатством своего языка, смелостью своих художественных приемов и т. д.

В годы первой и второй пятилетки т. Наджми дал ряд рассказов и повестей на тему классовой борьбы в татарской деревне и колхозного строя. За последнее время т. Наджми закончил большой роман "ГАРНИЗОН", который показывает его дальнейший рост, как крупного татарского советского писателя.

Необходимо отметить, еще то, что т. Наджми на всех этапах татарской советской литературы вел самую активную литературно-общественную работу, активную борьбу против буржуазного национализма, против контрреволюционной султангалиевщины и сагидуллинщины смело разоблачая буржуазно-националистические вылазки в области художественной литературы.

Начиная с 1924 года т. [illegible]

[illegible]

НАГРАДИТЬ юбилейным значком.

[illegible]

Юбилей значогы белән бүләкләү турында боерык

*Буклет*




TAT. SOVET DRAMATURGЬ KƏRIM IPTƏŞ TENCURINNЬŊ ƏDƏBI IÇAD EŞÇƏNLEGENEŊ JEGERME BIŞ JЬLLЬQ JUBILEJE

XXV

ЮБИЛЕЙ ЛИТЕРАТУРНО - ТВОРЧЕСКОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ТАТАРСКОГО СОВЕТСКОГО ДРАМАТУРГА тов. КАРИМА ТЕНЧУРИНА

1911 - 1936





BIOGRAFIƏ BELEŞMƏSE

Kərim Ƣəli ulь Tencurin 1887 jьl. 15 nce sentəbrdə Urta Volga əlkəsendə (elekke Penza guberniasь) Taraqan avьlьndaqь krestian semjasendə tuqan. 1900 jьlnьŋ jazьnda ul Qazanqa eş ezləp kilə. Vokzal jaqьndaqь [illegible] savьt-saba juarqa jallanьp, qьş naşьnda „Mədrəsəi Məxəmmədiə" gə uqьrqa kerə. 1905-6 ncь jьllardaqь şəkertlər xərəkətenə qatnaşqan ecen anь mədrəsədən quvalar. Şunnan son [illegible] ul [illegible] [illegible] jallanьp eşli başlьj həm 1910 jьlnь „Sajjar" truppasьna kerep, [illegible], professional artist bulьp tanьla.

Fevral' revolytsiəsennən son Məselman Sosialistlar komitetьnda, Oktabr revolytsiəse bulqaç bol'şeviklar partiəsenen Qazan gubkomь organь — „Eş" gazetasьna jaqьnnan qatnaşa. Şul uq vaqьtta Qьzьl Armia politik idarəse qaramaqьndaqь 13 nce truppanьŋ [illegible] həm [illegible] bulьp eşli.

1920 jьlnь [illegible] [illegible] [illegible] [illegible] politik idarəse qarşьnda [illegible] [illegible] tatar [illegible]

sәhnәsendә [illegible] 1921 nce jьlnь Ģ. Kәrief isemendәge proletariat truppasьn çitәklәdi.

1922 nce jьlnь Taşkәnttә Oģьlmi Sovettьņ teatr bylegen alьp bara. Şul uķ jьlnь Tatarstanga qajtьp 1935 nce jьlga qadәr Tatar Akademia teatrьnda artist, režissor, xudožestvo çitәkçese bulьp eşli. 1926 ncь jьlnь Tatarstan xөkymәte iptaş Tencuringә at qazanqan artist isemen birә.

Kәrim ip. Tencurin berence sәxnә әsәren 1906 ncь jьlnь uķ jazqan bulsa da, anьņ adәbiat elkәsendә ciddi rәvеştә eşli başlavь 1910—11 nce jьllarga turь kilә. Şuşь 26 jьl eçendә ul [illegible] 27 original sәxnә әsәre һәm [illegible] tәrçemә әsәrlәr jazdь.

---

KӘRIM TENCURIN QALӘMENNӘN JAZЬLQAN SӘXNӘ ӘSӘRLӘRE

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | „MONATAZA" | komedia | 1908 ј. |
| 2. | „KALЬK KOŞEP" | „ | 1910 ј. |
| 3. | „SӨNGЬ ADЬM" | drama | 1910—11 ј. |
| 4. | „BERENCE CINCELӘR" | „ | 1913 ј. |
| 5. | „NAZLЬ KIJӘY" | komedia | 1915 „ |
| 6. | „AC ĶASЬĶ" | „ | 1915 „ |
| 7. | „SӨNGЬ SӘLAM" | drama | 1916 „ |
| 8. | „CIL QUABLAR" | komedia | 1916 „ |
| 9. | „JOSЬF ZӘLIXA" | „ | 1917 „ |
| 10. | „SAQЬ A, ŞAŞЬ AMAKSЬN" | „ | 1918 „ |
| 11. | „ZAR" | trago-komedia | 1923 „ |
| 12. | „QAZAN SӨLGESE" | komedia | 1923 „ |
| 13. | „SYNGӘN JOLDЬZLAR" | drama | 1923 „ |
| 14. | „TUTЬM QOŞ" | komedia | 1923 „ |
| 15. | „AMERIKAN" | „ | 1924 „ |
| 16. | „NӘNI ABЬJ" | „ | 1925 „ |
| 17. | „ÇILKӘNSEZ" | „ | 1925 „ |
| 18. | „ZӘNGӘR ŞӘL" | muzdrama | 1926 „ |
| 19. | „IL" | drama | 1927 „ |
| 20. | „XIKMӘTLE DӨNЬJA" | komedia | 1928 „ |
| 21. | „EVROPA QORЬLDAĶLARЬ" | [illegible] | 1928 „ |
| 22. | „QANDЬR BAUЬ" | pjesa | 1929 „ |
| 23. | „UDARNIKLAR BOLЬŞЬ" | komedia | 1933 „ |
| 24. | „ALAR ӨCӨN TIŞ" | „ | 1935 „ |
| 25. | „QOBЬC OSCЬQ" | [illegible] | |
| | | | 1930 „ |
| 26. | „TURƏAJ" | „ | 1932 „ |
| 27. | „BULAT BATЬR SӘJӘXӘTE" | „ | 1935 „ |

AFTORLAŞTЬRЬLQAN TӘRÇEMӘLӘR:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28. | „XAN QЬZЬ" | tragikomedia | 1917 „ |
| 29. | „ZӘNGӘR PALAS" | drama | 1924 „ |
| 30. | „CIT ĶLӘVЬ" | komedia | 1925 „ |

---

БИОГРАФИЧЕСКАЯ СПРАВКА

Карим Алиевич Тенчурин родился 15 сентября 1887 года в семье крестьянина деревни Тарханово Средневолжского края (бывш. Пензенская губерния).

Весною 1900 года, в поисках работы Тенчурин приезжает в Казань и работает в приволжской харчевне кухонным рабочим. В ноябре того же года поступает в медресе „Мухаммедия". За участие в волнениях шакирдов в 1906 году его исключают из медресе, после чего он работает в различных местах конторщиком, учителем и в 1910 году вступает в труппу „Сайяр", где скоро становится профессиональным актером.

В период февральской революции К. Тенчурин работает в мусульманском социалистическом комитете, а после Октябрьской революции активно сотрудничает в газете „Еш"—орган Казанского губкома Коммунистической партии. Одновременно он руководит труппой при Политуправлении Красной Армии.

В 1920 году К. Тенчурин назначается преподавателем и главрежиссером первой татарской театральной студии при Политуправлении Заволжского военного округа.

В 1921 году он руководит пролетарской труппой имени Г. Карiева. В 1922 году возглавляет театральный отдел Научного Союза в Ташкенте.

С конца 1922 года по 1935 год Карим Тенчурин работает в качестве актера, режиссера и художественного руководителя Татарского Государственного Академического театра.

В 1926 году правительство Татарии присваивает Кариму Тенчурину звание заслуженного артиста республики.

Тов. Тенчурин написал свою первую пьесу еще 1906 году, но серьезная и постоянная его работа в литературе начинается в 1910—11 годах. За эти 25 лет им написано 27 сценических произведений и кроме того им сделаны авторизированные переводы трех пьес.

## СПИСОК
## СЦЕНИЧЕСКИХ ПРОИЗВЕДЕНИЙ
## К. А. ТЕНЧУРИНА

1. „[illegible]" комедия [illegible]
2. „[illegible]" [illegible]
3. „[illegible]" драма [illegible]
4. „[illegible]" [illegible]
5. „[illegible]" комедия [illegible]
6. „[illegible]" [illegible]
7. „[illegible]" драма [illegible]
8. „[illegible]" комедия [illegible]
9. „[illegible]" [illegible]
10. „[illegible]" [illegible]
11. „[illegible]" [illegible]
12. „[illegible]" комедия [illegible]
13. „[illegible]" драма [illegible]
14. „[illegible]" комедия [illegible]
15. „[illegible]" комедия [illegible]
16. „[illegible]" [illegible]
17. „Без ветрил" [illegible]
18. „Голубая шаль" мелодрама [illegible]
19. „[illegible]" драма [illegible]
20. „[illegible]" комедия [illegible]
21. „[illegible]" [illegible]
22. „[illegible]" [illegible]
23. „[illegible]" комедия [illegible]
24. „[illegible]" комедия [illegible]
25. „[illegible]" [illegible]
[illegible]. „[illegible]" [illegible]
[illegible]. „[illegible]" [illegible]

[illegible]

[illegible]. „[illegible]" [illegible] [illegible]
[illegible]. „[illegible]" драма [illegible]
[illegible]. „[illegible]" комедия [illegible]



„ÇILKƏNSEZLƏR". Dilbər rolendə [illegible] artistka FATIMA [illegible]SKAJA.

„Без ветрил". В роли Дильбер—[illegible] артистка республики Ф. Ильская.



„ÇILKƏNSEZLƏR". Mirsaf xaçi rolendə [illegible] artist ZƏINI SOLTANOF.

„Без ветрил". В роли Мирсаф хаджи—заслуженный артист республики З. Султанов.



„ÇILKƏNSEZLƏR". Xəzrət rolendə [illegible] artist QASЫM ŞAMIL.

„Без ветрил". В роли Хазрат—[illegible], артист республики К. Шамиль.



„ZƏNGƏR ŞƏL". Marfuqə rolendə xalq artistkasь [illegible] BOLQARSKAJA.

„Голубая шаль". В роли Марфуги—народная артистка Г. Болгарская.



„ZƏNGƏR ŞƏL". Şəjx qart rolendə [illegible] artist QASЫM ŞAMIL.

„Голубая шаль". В роли старика Шайха—заслуженный артист республики К. Шамиль.



„ZƏNGƏR ŞƏL". [illegible] rolendə artistka NƏFIQƏ ARAPOVA.

„Голубая шаль". В роли первой жены Ишана—артистка Н. Арапова.



*Кәрим Тинчуринга Самара театры артистларыннан истәлек-рәсем. 1920*






XXV

1911 1936

PROGRAMMASЬ

ПРОГРАММА


*Кәрим Тинчуринның 25 еллык иҗат юбилеена багышланган кичә программасы*



KONSERT




*Гөлсем Болгарская*




*Гөлсем Болгарскаяның котлавы*

*«Сәйяр» труппасы чыгыш ясаган бина — «Шәрык» клубы. Татарстан урамы*








*Котлау*







*Котлау*



*Бәхетле чаклар...*



ПРОКУРАТУРА СССР

ПРОКУРАТУРА
Татарской АССР
"18" окт. 1955 г.
№ 12-94ш
г. Казань,
ул. Чернышевского д. 12/20

[illegible]
г. Казань
ул. [illegible]

Сообщаю, что постановление тройки НКВД от [illegible] 1938 года, по которому [illegible] осужден, постановлением Президиума Верховного Суда ТАССР от "14" октября 1955 г. отменено и дело прекращено, о чем может получить соответствующий документ в Верховном Суде ТАССР.

ЗАМ. ПРОКУРОРА ТАТ. АССР
по спецделам
СОВЕТНИК ЮСТИЦИИ

/ВАСИЛЬЕВ/

*Прокуратура белешмәсе*



*Төрмә*


Татарская АССР

ВЕРХОВНЫЙ СУД

26 января 1961 г.

№ 44у-1207

Адрес: Казань, Ленина, 13/20.

СПРАВКА

Дело по обвинению ТЕНЧУРИНА Карима Алеевича, 1887г. рождения, уроженца д. Таракановка, Бедно-Демьянского района Куйбышевской области, пересмотрено Президиумом Верховного Суда ТАССР 14 октября 1956 года.

Постановление Тройки при НКВД ТАССР от 14/XI-1938г. в отношении Тенчурина Карима Алеевича отменено и дело прекращено за отсутствием состава преступления.

Председатель Верховного Суда ТАССР /М. ХАБИБУЛЛИН/

*Югары суд белешмәсе*


Уважаемый тов. Тинчуриной

ТАТАРСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ АКАДЕМИЧЕСКИЙ ТЕАТР
имени Г. Камала.

Приглашает Вас принять участие в просмотре спектакля «Зәңгәр шәл»

1 июня 1956 г.


в 7³⁰ часов. В помещении театра (ул. М. Горького, дом № 13, тел. № 78-34).

Дирекция.

В/места ряд 4 — 11-12 места.

ПФ 15461. Тип. им. Н. Александрова, тир. 5000, зак. № 04297.


*Кәрим Тинчуринга бирелгән характеристика*



КРАТКАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА

/ЗАСЛУЖЕННОГО АРТИСТА Т И Н Ч У Р И Н А КАРИМ/

[illegible]



[illegible]

ДИРЕКТОР ТГАТ: [illegible]



« 11 » Апреля 1956 г.

№ 0/К

СОЮЗ СОВЕТСКИХ ПИСАТЕЛЕЙ СССР

Москва, ул. Воровского, 52

Тел. [illegible]

В ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАССР

Копия: Гр-не ТИНЧУРИНОЙ


Направляем выписку из постановления Секретариата Союза писателей СССР о посмертном восстановлении в правах члена Союза писателей Тинчурина К.Г.

О созданной Вами комиссии по литературному наследству Тинчурина просим сообщить.

Зав. Отделом Кадров
СП СССР /К. Горбань/

ОГ.

*Язучылар берлегеннән алынган белешмә*



*Гоголь урамы. ВЧК бинасы. 20 нче еллар*





«Зәңгәр шәл» спектакленең программасы






«Казан сөлгесе» спектакленең программасы

*Язучыларның I Бөтенсоюз съезды. Беренче рәт сулдан уңга: К.Нәҗми, А.Толстой, М.Горький, К.Тинчурин; икенче рәт: К.Төхфәтуллин, Л.Гыйльми, Х.Туфан, Г.Толымбайский, Г.Нигъмәти, Г.Ризван. 1934*







*Заһидә Тинчуринаның Кәрим Тинчурин һәм Сәлих Сәйдәшев турындагы истәлекләре*









*Заһидә ханым Тинчуринаның кабере.*
*«Кәримнең үз гүре юк, шуңа күрә минем кабер ташыма аның исемен дә яздырырсыз. Минем гүрем Кәримнең гүре булыр. Чәчәкләрегезне шунда китерерсез». (Заһидә Тинчуринаның Рабит Батуллага васыяте. 1988)*

# АВТОРЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

*Минтимер Шәймиев* – Татарстан Республикасы Президенты.

*Равил Фәйзуллин* – Татарстанның халык шагыйре, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

*Риза Ишморат* – драматург, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Шәрәф Байчура* – Кәрим Тинчуринның замандашы.

*Фатыйма Ильская* – Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы.

*Галия Кайбицкая* – Татарстанның халык артисткасы.

*Рәшидә Җиһаншина* – Россиянең халык артисткасы.

*Баян Гыйззәт* – әдәбият белгече, әдәби тәнкыйтьче, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Вәли Хаҗиев* – укытучы, дәреслекләр авторы.

*М.Сәләхетдинов* – укытучы.

*Зөлфәт* – шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

*Лена Шагыйрьҗан* – шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Рабит Батулла* – язучы, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге бүләк лауреаты.

*Заһидә Тинчурина* – актриса, педагог.

*Сәет Шәкуров* – драматург, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

*Марсель Сәлимҗанов* – режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССРның халык артисты, Россиянең К.Станиславский исемендәге, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, Россиянең театр өлкәсендәге «Алтын битлек» бүләге лауреаты.

*Мөхәммәт Мәһдиев* – Татарстанның халык язучысы, әдәбият белгече.

*Туфан Миңнуллин* – язучы, драматург, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең К.Станиславский исемендәге, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, Татарстанның халык депутаты.

*Рауза Хәйретдинова* – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы.

*Разил Вәлиев* – шагыйрь, Татарстанның М.Җәлил исемендәге бүләге лауреаты, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның халык депутаты.

*Мансур Шиһапов* – шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Мәгъсум Хәбибуллин* – журналист.

*Равил Шәрәфиев* – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Татарстанның М.Җәлил һәм Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты.

*Роберт Әхмәтҗан* – шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Ильтани Илялова* – театр белгече, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор.

***Нәҗибә Ихсанова*** – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Хәлим Җәләлов*** – Татарстанның халык артисты.

***Рәдиф Гаташ*** – шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Венера Ганиева*** – җырчы, Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Гали Арсланов*** – театр белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Ләбиб Лерон*** – язучы, шагыйрь.

***Рәүф Игъламов*** – театр белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Азат Әхмәдуллин*** – әдәбият белгече, әдәби тәнкыйтьче, ТРФА әгъза-корреспонденты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Газинур Морат*** – шагыйрь.

# ЭЧТӘЛЕК

*М.Шәймиев.* «Кәрим Тинчурин күпкырлы талант иясе...» . . . 5
*Р.Фәйзуллин.* Әйләнә сәхнә, әйләнә... . . . 6

## УЙНАКЛАШЫП КҮТӘРЕЛӘ ҖЫРЛАР БЕЗ ЯШӘГӘН ЯКТЫ БУ ЧОРДАН...

*Р.Ишморат.* Соңгы очрашулар . . . 10
*Ш.Байчура.* Әдип турында кайбер хатирәләр . . . 13
*Ф.Ильская.* Сокландыргыч Кәрим ага . . . 17
*Г.Кайбицкая.* Кәрим Тинчуринга карата истәлекләрем . . . 20
*Р.Җиһаншина.* Тинчуринның соңгы омтылышлары . . . 26
*Б.Гыйззәт.* Таләпчәнлек үрнәге . . . 28
*В.Хаҗиев.* Бердәнбер рәсем . . . 29
*М.Сәләхетдинов.* Истәлекле хат . . . 30
*Зөлфәт.* Теге чак . . . 32

## БЕР-БЕРСЕН ЭЗЛӘҮЧЕ ИКЕ ЙОЛДЫЗ...

*Р.Батулла.* Җимерелгән бәхет . . . 36
*Л.Шагыйрьҗан.* Кәрим Тинчурин истәлегенә . . . 79

## ГҮЯ БЕРЧАК СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАРЫН СҮНМӘС ИТЕП КАБАТ КАБЫЗГАН...

*С.Шәкуров.* Үз йортына кайтарасы иде . . . 82
*М.Сәлимҗанов.* «Зәңгәр шәл» сере . . . 85
*М.Мәһдиев.* Ул кабызган утлар . . . 89
*Т.Миңнуллин.* Остаз . . . 92
*Р.Вәлиев.* Чират . . . 96
*Р.Хәйретдинова.* Күңелем түрендә . . . 98
*М.Шиһапов.* Мин шуңа сөенәм . . . 100
*М.Хәбибуллин.* Әдип туган якларда . . . 102
*Р.Шәрәфиев.* Һаман уйныйсы иде... . . . 104
*Р.Әхмәтҗан.* Эзе дә юк... . . . 106
*И.Илялова.* Счастливая страница . . . 107
*Н.Ихсанова.* Менә бу Кәрим Тинчурин «мунчасы»! . . . 109
*Х.Җәләлов.* Бүген дә сагынам... . . . 110
*Р.Гаташ.* Сүнмәс йолдызлар . . . 111
*В.Ганиева.* Мәйсәрә белән кабат очрашыр идем . . . 112
*Г.Арсланов.* Күпкырлы талант . . . 114
*Л.Лерон.* Шигыремә керде Тинчурин... . . . 117
*Р.Игламов.* Драматургия 20-х годов . . . 119
*А.Әхмәдуллин.* Кәрим Тинчурин стиле . . . 122
*Г.Морат.* Черек күл . . . 124
Авторлар турында белешмәләр . . . 157

Китапта Кәрим Тинчурин, Илдус Әҗемов, Йосыф Вәлиәхмәтов, Фоат Гарифуллин, Фәрит Гобәев, Владимир Зотов, Фердинанд Кадыйров, Владимир Смирнов, Рушан Шәмсетдинов, Риф Якупов фотолары, шулай ук Заһидә Тинчурина һ.б. архивыннан алынган фоторәсемнәр файдаланылды.


Литературно-художественное издание

Коллектив

**КАРИМ ТИНЧУРИН**

(на татарском и русском языках)

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, С.Н.Мифтахова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 4.07.2003. Форматы 70×100 1/16.
Офсет кәгазе. «Nimbus Cyr» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 13,0+форз.0,33. Шартлы буяу-оттиск 53,95.
Нәшер-хисап табагы 12,83+форз.0,47.
Тиражы 3000. Заказ Я-405.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.